ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

А.И. Кравченко,
Е.А. Певцова



7

А.И. Кравченко,
Е.А. Певцова
ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ
7

А. И. Кравченко, Е. А. Певцова

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 7 нче сыйныфы өчен дәреслек

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

Казан «Мәгариф» нәшрияты
Москва «Русское слово»
2007

УДК 373.167.1:30*07
ББК 60я721
К69

Кравченко А. И., Певцова Е. А.
Обществознание: Учебник для 7 класса общеобразовательных учреждений.— 9-е изд., испр. и доп.— М.: ООО «ТИД «Русское слово — РС», 2007.— 223 с.: ил.

Методик аппарат авторлары — *И. С. Хромова, И. В. Козленко*
Сәнгати бизәлеше һәм макеты *И. В. Тырданов*

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Переводное издание учебника выпущено в свет по Лицензионному договору № ЛД-03 от 14 июня 2007 г. Экземпляры переводного издания подлежат распространению исключительно в Республике Татарстан, а также среди татарской диаспоры на территориях других субъектов Российской Федерации.

Кравченко А. И.

К69 Җәмгыять белеме: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 7 нче с-фы өчен д-лек /А. И. Кравченко, Е. А. Певцова; Русчадан Ә. М. Камалов тәрҗ.— Казан: Мәгариф, 2007.— 223 б. рәс. б-н.
ISBN 978-5-7761-1735-0

Дәреслектә кешеләр мөнәсәбәтләре дөньясы, яшүсмер шәхесе турында сөйләнә. Үз-үзеңне тоту нигезләре, яшүсмергә очрашырга туры килгән проблемалар турында бәян ителә.

ISBN 978-5-7761-1735-0

© ООО «ТИД «Русское слово — РС», 2002, 2007
© Художественное оформление. ООО «ТИД «Русское слово — РС», 2007
Все права защищены
© Татарчага тәрҗемә, «Мәгариф» нәшрияты, 2007

Эчтәлек

I бүлек. Яшүсмер шәхесе
§ 1. Күчү яше 7
§ 2. Яшүсмер чакның бурычлары һәм кыенлыклары . . 14
§ 3. Зурлар булу 22
§ 4. Яшүсмерләрдәге физик үзгәрешләр 27
§ 5. Шәхеснең психологик портреты:
темперамент һәм характер 36
§ 6. Шәхеснең психологик портреты:
интеллект, эмоцияләр һәм хисләр 41
§ 7. Яшүсмернең үз-үзен бәяләве 49
§ 8. Күренекле шәхес 55
§ 9. Лидер һәм аның сыйфатлары 64

II бүлек. Яшүсмер социаль даирәдә
§ 10. Яшүсмернең социаль даирәсе 73
§ 11. Яшүсмер төркемдә 79
§ 12. Шәхесара мөнәсәбәтләр 85
§ 13. «Без» һәм «алар» 91
§ 14. Таныш һәм таныш булмаган кешеләр дөньясы . . . 96
§ 15. Яшьләрнең социаль портреты 104

III бүлек. Яшүсмер һәм закон
§ 16. Яшүсмер чакның юридик чикләре 111
§ 17. Гражданин буларак яшүсмер 120
§ 18. Яшүсмер һәм аның хокуклары 127
§ 19. Җинаятьчел тормышның куркыныч юлы 133

IV бүлек. Яшүсмерләрнең яшәү рәвеше
§ 20. Яшүсмер хәвефле җәмгыятьтә 141
§ 21. Ялгызлык проблемасы 148
§ 22. Яшүсмерләр культурасы 155
§ 23. Яшәү рәвеше 162
§ 24. Буш вакыт һәм ял 172
§ 25. Спорт 182

V бүлек. Яшүсмер һәм аның яшәү тирәлеге
§ 26—27. Шәһәр һәм авыл 191
§ 28—29. Минем йортым, минем торагым 207

Кадерле җиденче сыйныф укучылары!

Сез быел 6 нчы сыйныфта ук таныша башлаган «Җәмгыять белеме» фәнен өйрәнүне дәвам итәсез. Исегезгә төшерәбез: былтыр әлеге фәнне өйрәнгәндә, сез кеше һәм җәмгыять, кешенең иҗтимагый тормышында икътисади, социаль, сәяси һәм рухи өлкәләр кебек темаларны үзләштердегез.

Яшүсмер чак (бу нәкъ менә сезнең хәзерге чорыгыз инде) — бик катлаулы, ләкин кеше шәхесе формалашуда гаять мөһим чор. Шуңа күрә без сезгә бу гади булмаган вакыт аралыгын иң әз югалтулар белән һәм бик тә файдалы итеп үтәргә ярдәм итәргә телибез.

Яшүсмер чак нәрсә ул, анда кешене нинди куркынычлар сагалый, ул нинди мөмкинлекләргә ия, ничек итеп бу куркынычларны мөмкин кадәр киметергә, ә мөмкинлекләрне тулысынча гамәлгә ашырырга, үзеңне яшьтәшләрең арасында, өлкәннәр, укытучылар белән ничек тотарга? Дәреслектә без бу һәм башка бик күп сорауларга ачыклык кертергә тырышырбыз.

Дәреслек бүлекләр һәм параграфлардан тора. Һәр параграф уку материалының төп эчтәлеге бәян ителгән текстны үз эченә ала.

Параграф тексты бүлекчә исемнәре белән мәгънәви өлешләргә бүленә. Бу өйрәнелүче теманың төп сорауларын, аларның эзлеклелеген аерып карарга, зарурлык туганда кирәкле материалны табарга ярдәм итәр.

Текстта аның эчтәлеген үзләштерү өчен мөһим булган рубрикалар урын ала. Мәсәлән, «Истә калдырырга киңәш итәбез» рубрикасы «Җәмгыять белеме» курсының төп төшенчәләре белән эшләү өчен файдалы булыр. Бу — үзенчәлекле сүзлек. Аңа таянып, параграфка биремнәрне үтәргә мөмкин.

«Законга мөрәҗәгать итик» рубрикасы законнардан өзекләрне үз эченә ала һәм хокукый материалны өйрәнгәндә файдаланыла. Ул кешегә, гражданинга, яшүсмергә кагылышлы законнарны укырга һәм аларның мәгънәсен аңларга өйрәтә, өлкәннәр тормышының нигезен тәшкил иткән хокукый нормаларны үзләштерергә дә ярдәм итә.

Моннан тыш, сез параграфның төп текстын аңлатучы һәм аны тарихи, хәзерге заман фактлары белән баетучы «Кызыклы фактлар» һәм «Өстәмә уку» рубрикалары белән очрашырсыз. Алардан дәрестә дискуссияләрдә катнашу, шулай ук хәбәрләр әзерләү өчен файдаланырга була. «Психологлар фикере...» рубрикасы сезне галим-психологларның тикшеренүләре белән таныштыра. «Йомгак ясыйбыз» рубрикасы тема буенча нәтиҗәләрне үз эченә ала.

Өй эше биремнәрендә үз-үзеңне тикшерү өчен сораулар бар («Белемегезне тикшерегез» рубрикасы). Алар параграфта каралган мәсьәләләрне төшенүне таләп итә. Үз-үзеңне тикшерү өчен, биремнәрдән соң «Практикум» рубрикасында биремнәрнең гамәли характердагы икенче өлеше тәкъдим ителә. Алар булган белемнәрне эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә һәм тормыш хәлләрендә (хокукый бурычларны хәл итү һәм вазгыятьне анализлау, актуаль мәсьәлә буенча инша-уйлану, ата-аналардан, яшьтәшләрегездән сорашып-белешү рәвешендә кешеләрнең җәмгыятьтәге тәртибенә зур булмаган тикшерү уздыру, мини-проектлар әзерләү һ. б.) файдалануга, куллануга юнәлтелгән.

Кайбер биремнәрне үтәгәндә, тарих, география, хокук буенча дәреслекләрдән, шулай ук белешмә материал сыйфатында сүзлекләрдән, матбугат, радио, телевидение материалларыннан файдаланырга тәкъдим ителә.

Практикум биремнәрен аерым-аерым яисә төркемнәргә берләшеп үтәргә мөмкин.

Дәреслек авторлары әзер рецептлар бирә алмый, без әлеге китап материаллары сезгә уйлану өчен җирлек, мөстәкыйль гамәлләр өчен нигез булыр дип саныйбыз.

I бүлек

Яшүсмер шәхесе

§ 1. Күчү яше

Яшүсмер дип кемне санарга?

Кешенең яше — гаиләдә туган көннәр даими рәвештә билгеләп үтелгән, яшәлгән еллар саны гына түгел, ә аның җәмгыятьтә биләгән мәгълүм бер урыны да. Ул яңа хокуклар, вазифалар, җаваплылык белән бәйле.

Психологиядә һәм педагогикада *11(12) дән алып 15 яшькә кадәрге* чорны **яшүсмер чак** дип атау кабул ителгән, бу 5—8 сыйныфларда укучыларның уртача мәктәп яшенә туры килә. Бу дәверне балалыктан балигълыкка (яшьлеккә) күчү чоры дип атыйлар. Яшүсмерләрдән җитдирәк эш-гамәлләр көтәләр, аларга зуррак өметләр баглыйлар, алар белән ешрак киңәшәләр, аларга ышаналар,

алардан күбрәк таләп итәләр. Бала вакытта аларның тәртибен ата-ана контрольдә тота, ә өлкәннәр тормышы үзең карар кабул итүне таләп итә. Дөньяга карашыңны үзгәртергә, яхшы белән яманны аерырга, идеаллар эзләргә һәм аларны мөстәкыйль рәвештә табарга туры килә.

Яшүсмер сүзе белән беррәттән чагыштырмача яңа *тинейджер* сүзе дә кулланыла. Ул ике инглиз сүзеннән: teens —13 тән 19 яшькәчә чор, age — яшь сүзләреннән килеп чыккан. АКШ һәм Англиядә яшүсмерләрне еш кына «тиннар» дип атыйлар.

Бу яшьтә мөһим физиологик үзгәрешләр бара (шуларның берсе — җенси яктан өлгерү), алар мәгълүм бер психологик үзгәрешләргә китерә: икенче җенескә тартылу, еш кына бер сәбәпсез агрессивлык барлыкка килә, уйлап бетермичә тәвәккәлләү һәм аның куркынычлылык дәрәҗәсен бәяли алмау, алны-артны карамый бәйсезлеккә һәм мөстәкыйльлеккә омтылыш күзәтелә.

Яшүсмер чак үзенчәлекләре

Галимнәр баланың олылар кушканны төгәл үтәгән «дөрес» яше 10—11 яшькәчә дәвам итә дип саныйлар. 7—10 яшендә әле нәни кеше бар нәрсәдә өлкәннәргә охшарга тырыша. Ә 13 тән 15 яшькәчә чорга җиткән зуррак яшүсмерләр үзләрен бөтенләй башкача тоталар.

Өлкән яшүсмер чакны тагын «авыр яшьтәгеләр» яисә «борылыш чоры» дип тә атыйлар. Нәкъ менә шул вакытта «дөрес» тәртип «дөрес түгел»е белән алышына. Җитлегә баручы кеше кагыйдәләр кушканча яки өлкәннәр тәкъдим иткәнчә түгел, киресенчә эшләргә тырыша. Тыңламау, буйсынмау — бу үзенә бер сыналу чоры. Үсмер мөһим эш белән мәшгуль — ул үзендә мөстәкыйльлек, бәйсезлек тәрбияли. Табигый ки, мондый эш каршылыкларсыз һәм хаталарсыз булмый.

Бу этапта ата-ана үз баласын танымый: ул шулкадәр нык үзгәрә. Нәни балаларга хас тулысынча буйсынудан ул башта өлешчә тыңламауга күчә, ә тора-бара яшерен генә әти-әнисенә бөтенләй буйсынмый башлый. Бала чагында ул дөньяга әти-әнисе күзлегеннән караса, хәзер яшүсмердә кыйммәтләр һәм дөньяга карашның параллель системасы

барлыкка килә. Бу караш өлешчә ата-ана позициясе белән кисешсә, өлешчә яшьтәшләренекенә туры килә.

Кече яшүсмер чакта ук баланың үз-үзен табарга омтылышы сизелә. 12—13 яшьтә ул аеруча интенсив төс ала. Тинейджер укуда, физик һәм психик камиллектә алдынгылыкка омтыла, теләсә нинди эшчәнлектә уңышка ирешергә тырыша.

Үсмерләрне тагын бер сүз белән — *яшьләр* дип атарга мөмкин, ә бит яшьлек яшүсмерлек чорыннан соң килә. Ләкин яшүсмер чакның озаюы белән бәйле рәвештә, белгечләр яшүсмерләр һәм яшьләр сүзләрен синоним буларак та кулланa. Белгечләр генә дә түгел. Әйтик, өлкән яшьтәге хатын-кыз сезгә: «Яшь кеше (башка вариант — егет, кыз), миңа булышыгызчы!» — дип эндәшсә, күңелле булып китәдер. Егет, кыз булу, ягъни яшегезгә карата олырак булып күренү рәхәт кенә түгел, бик җаваплы да. Сездән чын, өлкәннәрчә гамәлләр көтәләр бит.

Балигъ булу (җитлегү) — кеше тормышында ул инде физик, социаль һәм рухи яктан да өлгергән яңа чор.

Өлкәннәр тормышы — бу яшькә бәйле чор гына түгел, ә хезмәттә катнашу да, гаиләдә вазифалар башкару да. Тик менә зурлар, шул исәптән гаилә тормышына тиешенчә әзерләнми керү аркасында яшьлек чоры кулдан ычкынган мөмкинлекләр вакытына әверелергә мөмкин.

Кешеләрнең яшь буенча катгый бүленеше күптән түгел генә барлыкка килгән. Яшькә бәйле чор буларак, балачак 150 ел элек кенә пәйда була. 10—12 яшендә крестьян баласы кырда менә дигән ярдәмче санала, ул хәзерге шәһәр кешеләре бөтенләй белмәгән бик күп хуҗалык эшләрен башкара. Россиядә Гражданнар сугышы барганда, яшүсмерләр полк командиры булган очраклар да билгеле (мәсәлән, 16 яшьлек Аркадий Гайдар). Бөек Ватан сугышы елларында 15 яшьлек үсмерләр еш кына качып фронтка китәләр, дошманга каршы партизаннар сафында торып сугышалар. Байтак дәүләтләр тарихында корольләр нәселеннән булган бала өлкәннәр ролен үти — король була. Дөрес, еш кына аңарга күп санлы киңәшчеләр аеруча зур игътибар бирә.

Галимнәр түбәндәге закончалыкка игътибар иттеләр: гомер озынлыгы кыскарак һәм җәмгыять үсеше түбәнрәк

Кызыклы фактлар

Кешенең ничә яше бар?

Гаҗәп, кешенең ничә яше бар дигән сорауга беркем дә төгәл генә җавап бирә алмый. Төрле илләрдән, төрле континентлардан җыелган мәгълүматны гомумиләштергән галим-этнографлар сабыйлык, балалык, яшүсмер чак һәм яшьлекнең яшь ягыннан чикләре бердәй түгел дигән нәтиҗәгә килделәр. Һәр җәмгыятьтә һәм һәр эпохада яшь саны беркайчан да даими зурлык булмый. Кениядәге нанди халкының яшь ягыннан 28 төркеме бар, ә Нигериядәге нупе халкыныкы — нибары өч. АКШта бүген сабый, бала, яшүсмерләр, яшьләр, урта яшьтәгеләр, картлар төркемнәрен аерып карыйлар.

булган саен, балалар өлкәннәр сафына тизрәк күчәләр. Көтелгән гомер озынлыгы (кеше үзе яшәргә өметләнгән уртача яшь) кыска булган җәмгыятьтә кеше 40—45 яшендә үк инде картлык чорына керә. Бүген кешеләр 75—80 ел яшиләр. Мондый запас дәвамлы балачакка, тулы кыйммәтле яшьлеккә дә җитә, кызыклы картлыкка да кала.

Урта гасырларда «балачак» төшенчәсе яшьне генә түгел, күпчелек очракта социаль бәйлелекне дә чагылдырган. Кеше гомере буена бәйле булып кала алганга, балачак та озакка сузылган. Түбән социаль баскычтагы кешеләр балага тиңләп кабул ителгән һәм, ничә яшьтә булуларына карамастан, бала дип саналган да. Рус алпавыты өчен барлык крестьяннар «чадо» булган һәм ул үзен аларга мөнәсәбәттә ата буларак тоткан. Крестьяннар алпавытка «безнең атакай» дип эндәшкәннәр. Рус телендә «чадо» (бала) сүзеннән һәркемгә мәгълүм «домочадцы» («өй балалары») сүзе килеп чыккан. «Олы яшьтәге (великовозрастное) чадо» дигәндә, үз яшьтәшләреннән олы бала күздә тотыла. В. Даль төзегән рус теленең аңлатмалы сүзлегендә борынгы «чадо» сүзенең челядь, дружина, ополчение, сугышчыларның җыелма атамасы булуы күрсәтелә.

Бүген дә «балачак» төшенчәсе буйсыну һәм бәйлелек идеясен үз эченә ала, ләкин ул кешеләрнең сыйнфый хәле белән берничек тә бәйләнмәгән. «Яшүсмер» төшенчәсе

Истә калдырырга киңәш итәбез

Яшь — 1) хронологик планда — туу вакытыннан алып хәзерге яисә башка билгеле бер вакытка кадәрге чор; 2) физик һәм психологик планда — кеше үсешендәге аерым бер этап: балачак, яшүсмер чак, яшьлек...; 3) социаль планда — социаль статус үзгәрү: мәктәпкәчә яшьтәге бала, укучы, эшче, пенсионер.

Яшүсмер чак — балаларның 11—12 яшьтән алып 15 яшькәчә үсеш чоры, бу урта мәктәп яшенә туры килә. Яшүсмер чакны башкача күчү яше дип тә атыйлар, чөнки ул балалык чорыннан яшьлеккә, өлгермәгәнлектән өлгергәнлеккә күчеш белән характерлы.

Яшь ягыннан чорларга бүлү — кеше тормышының анатомик-физиологик һәм социаль-психологик билгеләр буенча чорларга бүленеше. Түбәндәге чорларны аерып карыйлар: сабыйлык — туган көннән 1 яшькә кадәр, мәктәпкәчә яшь алдындагы чор — 1 яшьтән 3 кә кадәр; мәктәпкәчә яшьтәгеләр — 3 яшьтән 6 га кадәр, кече яшьтәге мәктәп балалары — 6 яшьтән 10 га кадәр; яшүсмер чак — 11 яшьтән 15 яшькәчә; яшьлек —15 яшьтән 21 гә кадәр; өлгергәнлек — 21 яшьтән 60 ка кадәр; өлкән яшьтәгеләр — 60 яшьтән 75 кәчә; картлык — 75 яшьтән 90 га кадәр; озак яшәүчеләр — 90 яшьтән узучылар.

кинәт кенә барлыкка килмәгән. XVII—XIX гасырларда Россиядә үсмерлек чоры бала 14—16 яшьтә вакытта җиткән, ә аңа кадәр аны «дитята» дип атаганнар.

Яшүсмер чак һәм яшьлек төшенчәләре беренче тапкыр XVIII гасырда Мәгърифәт дәвере педагоглары тарафыннан формалаштырыла. Монда бөек француз язучысы һәм мәгърифәтчесе философ *Ж. Ж. Руссо* (1712—1778) карашлары мөһим роль уйный. Ул балачак һәм яшьлекне идеальләштерә, аларны кеше тормышында якты уй-фикерле һәм романтик омтылышлы гөнаһсыз вакыт дип саный. Руссо фикеренчә, җәмгыять кешене боза, шуңа да балачак һәм яшьлекне аның начар йогынтысыннан сакларга кирәк.

Шулай итеп, яшүсмер чак — тормышның балалык һәм өлгергәнлек арасындагы бер кисәге. Антиклык чорында һәм Урта гасырларда ул шактый кыска булган, ә хәзерге җәмгыятьтә фән-техника прогрессы йогынтысында һәм уку вакытларының озаюы (мәктәптән соң ук — югары уку йортына) аркасында һаман сузыла бара. Яшүсмер чакны тормышның бер чорыннан икенчесенә сузылган күпер рәвешендә күзалларга мөмкин: анда озак тоткарланырга да ярамый, ничек кенә теләсәң дә йөгереп тә үтә алмыйсың. Күп кенә яшүсмерләрнең тизрәк олы кеше буласы килсә дә, кеше табигатенең үз кырыс законнары бар.

Яшүсмер чак — һәр кешегә бирелгән сынау ул. Сезгә кадәр бу юлны күпме кеше узганын беләсезме? 100 миллиардтан күбрәк! Әле тагын күпмесе узачак.

Тормышның бу тәҗрибәсен икенче кешегә тапшырып булмый. Кызганычка каршы, һәр яшүсмер үз юлын яңадан башлый. Шул ук юлдан узган миллиардлаган кешеләрнең яшьлек хаталары һәркемгә сабак була алмый. Сез, бәлки, шул ук хаталарны кабатларсыз, шул ук мәңгелек мәсьәләләрне хәл итеп азапланырсыз. Сезгә әзер зирәклек рецептларын бирсәләр дә, табигать авазына буйсынып, тормыш сорауларына үзегез җавап эзләрсез.

Мөстәкыйль фикер йөртүегезне үстереп, вакыйгаларның сәбәпләрен, төрле тормыш вазгыятьләрендә кешеләрнең тәртибен, гамәлләрен анализлап, сез үз юлыгызны табарга, хаталарны булдырмаска өйрәнерсез.

Йомгак ясыйбыз

11 яшьтән 15 яшькәчә яшүсмерләрдә мөһим физиологик һәм психологик үзгәрешләр чорында әйләнә-тирә дөньяны яңача кабул итү формалаша. Үз тормыш тәҗрибәңне булдырырга вакыт җитә.

Белемегезне тикшерегез

1. Яшүсмер чакның чикләре нинди?

2. «Күчү яше», «борылыш чоры» буларак, яшүсмер чакка гомуми характеристика бирегез.

3. «Балачак», «яшүсмер чак», «яшьлек», «тинейджер» төшенчәләренең мәгънәләрен ачыгыз. Бу төшенчәләр кайчан тәңгәл килә, кайчан аерымлана?

Практикум

1. «Яшүсмер чак — һәр кешегә бирелгән сынау» дигән гыйбарәнең асылын ничек аңлыйсыз?

2. Тарих буенча белемнәрегездән файдаланып, шуны аңлатыгыз: ни өчен төрле тарихи чорларда яшүсмер чакның чикләре һәм яшүсмерләргә мөнәсәбәт төрлечә булган?

3. Яшүсмер чакны характерлап, психологлар иптәшлек хисе, дусларча аралашу ихтыяҗы, дуслыкка аңлы караш кебек шәхси сыйфатларны үстерүгә игътибар бирәләр.
Үз тәҗрибәгезгә, сыйныфыгыздагы, мәктәп җәмәгатьчелегендәге мөнәсәбәтләргә таянып, әлеге фикер белән килешегез яисә аны кире кагыгыз.

§ 2. Яшүсмер чакның бурычлары һәм кыенлыклары

Яшүсмер чакның бурычлары

Яшүсмер чакны **күчеш чоры** дип саныйлар: үсмер өлешчә — балалар төркеменә, өлешчә олыларныкына керә. Бериш очракларда яшүсмерләргә балаларга караган кебек, ә икенчеләрендә олылар итеп карыйлар. Тәртипнең кайбер балаларча рәвешләре яшүсмер өчен инде яраксыз. Шул ук вакытта олыларча тәртип рәвешләре рөхсәт ителми яисә, рөхсәт ителсә дә, аңа таныш түгел. Яшүсмер олыларда булган өстенлекләрдән файдалана алмый, әмма балачактагы өстенлекләрне инде югалта.

Яшүсмер бер яшь төркеменнән икенчесенә күчеш халәтендә була. Ул тизрәк өлкән кеше булмакчы, ләкин олылар гына ерып чыгарлык катлаулы һәм җаваплы бурычларны хәл итә белми әле. Ә яшүсмернең көндәлек тормышында күпме проблема чыгып тора! Мәктәп дуслары уздырган күмәк чарага аны чакырмаганнар. Таныш малайлар аңардан көлгән. Иртән уянгач, йөзендә яңа бетчәләр күргән.

Үсә барган саен, яшүсмергә шактый катлаулы бик күп бурычларны хәл итәргә туры килә. Мәктәптәге гадәти бурычлардан тыш, һәркайсыбыз чишәргә тиешле башка мәсьәләләр дә бар. Аларны Америка психологы *Р. Хэвигхерст* ачыклаган. Үзенең «Үсеш бурычлары һәм мәгариф» дигән китабында ул яшьлектә мәҗбүри дип саналган үсеш бурычларын аерып карый:

1. Үзеңнең тышкы кыяфәтеңне кабул итү һәм гәүдә белән нәтиҗәле идарә итү осталыгы.

2. Ике җенестәге яшьтәшләрең белән дә яңа, камилрәк мөнәсәбәтләр булдыру.

3. Ир-ат яисә хатын-кыз ролен кабул итү.

4. Әти-әниегездән һәм башка өлкән кешеләрдән эмоциональ бәйсезлеккә ирешү.

5. Хезмәт эшчәнлегенә әзерлек.

6. Никахлашуга һәм гаилә тормышына әзерлек.

7. Үзең һәм җәмгыять өчен җаваплылык тою теләге туу.

8. Тормышта таянырга мөмкин булган кыйммәтләр һәм этик принциплар системасы булдыру.

Бу бурычларны хәл итүдән качып булмый, аларны үтәүне соңга калдырырга, читкә куеп торырга ярамый. Әлеге бурычларны үтәмәсәң, «Олы тормыш» дигән поездга өлгермәдең дип сана. Яшьтәшләрең белән җитди мөнәсәбәтләр урнаштыра белмәсәң, син нинди зур кеше инде. Тормышның бөтен бурычларын үз вакытында чишәргә кирәк. Җәмгыять тормышының язылмаган кагыйдәсе шундый. Катлаулырак бурычны җиңелрәген чишкәч кенә хәл итеп була. Яшүсмерләр һәм яшьләрнең бурычлары катгый эзлеклелеккә корылган. Үтәлгән бурыч тәҗрибәсе алдагы бурычларны хәл иткәндә кирәк булачак.

Кызыклы фактлар

Шәхси тәҗрибә

Кеше каршылыкларны һәм хәтта бәхетсезлекләрне җиңә барып өлгерә, олыгая. Әлбәттә, алар аның шәхесен сындырырлык көчле булырга тиеш түгел. Алар кешене чыныктырырга һәм күп нәрсәгә өйрәтергә тиеш. Американың педагогика өлкәсендә күренекле белгече *Дж. Добсон* үзенең яшьлеге турында менә нәрсәләр яза:

«Зур булмаган киеренкелекнең нинди әһәмияткә ия булуын мин үз тәҗрибәмнән чыгып аңладым. Минем бала чагым гаҗәеп бәхетле һәм кайгысыз булды. Мин мәхәббәт мохитендә үстем, мәктәптә укыганда минем белән бернинди күңелсезлекләр булмады. Мин бәхет эчендә йөздем, минем теләкләрем гомерем буе үтәлә килде бугай. Авыр кичерешләр белән бәйле ике ел гомерем генә моңа керми.

Бу вакытта миңа 13—14 яшь булып, җиденче һәм сигезенче сыйныфларда укый идем. Ул елларда мин, социаль күзлектән караганда, ниндидер икелемикеле халәттә калдым, бу үземнең тулы булмавымны бик көчле тоюга, үз-үземә карата шикләнүләр барлыкка килүгә китерде. Ләкин, ни гаҗәп, нәкъ менә шушы ике елның социаль тәҗрибәсе, тормышымның башка теләсә нинди чоры белән чагыштырганда минем характерымны һәм индивидуальлегемне формалаштыруга иң зур уңай өлеш кертте. Кайгыртуга сәләтем, тормышта уңышка ирешү теләге, тулы кыйммәтле булмау хисен җиңү, яшүсмерләр белән элемтәләр урнаштыру осталыгы —барлык бу сыйфатлар яшьлек кичерешләре белән тулы чорда барлыкка килде. Әлеге егерме дүрт ай ниндидер файда китерә алыр дип кем уйлаган? Ул вакытта кичергән уңайсызлыклар күп нәрсәгә өйрәнергә ярдәм итте».

Билгеле булганча, яшьлектән соң балигъ булырга вакыт җитә. Яшүсмер һәм яшь егет чагында хәл ителергә тиешле бурычларны кем дә кем үз вакытында үти алмаса, ул, өлкән яшьтә дә башка кешеләр белән аралашканда, даими рәвештә шөбһә һәм кыенлыклар кичерәчәк. Әлеге бурычларны үтәү нидән гыйбарәт соң? Аларны тәкъдим ителгән эзлеклелектә карыйк.

Тормыш бурычларын үтәүгә әзерлек

1. Үзеңнең тышкы кыяфәтеңне кабул итү һәм гәүдә белән нәтиҗәле идарә итү осталыгы. Яшүсмер чакта кешегә үзенең физик күрсәткечләре турында артыгы белән борчылу хас: йә буе бик кечкенә, йә сипкелләре бик күп. Яшүсмергә үзенең физик кыяфәтен һәм организмда барган үзгәрешләрне ничек бар шулай кабул итү, шулай ук үзенең тәне турында кайгырту, физкультура һәм спорт, ял һәм күңел ачу, уку һәм көндәлек эшләр кебек эшчәнлек төрләрендә гәүдәсе белән нәтиҗәле идарә итәргә өйрәнү зарур.

2. Ике җенестәге яшьтәшләрең белән дә яңа, камилрәк мөнәсәбәтләр булдыру. Яшүсмерләрнең, егетләр һәм кызларның бер үк җенестәге яшьтәшләре арасындагы балачак мәнфәгатьләре һәм дуслыгы төрле җенесләр арасындагы дуслык белән тулыланырга тиеш. Кызларга пальтоларын кидерергә ярдәм итү, аларны туңдырма белән сыйлау яисә киного чакыру урынына сез әле һаман аларны тәртәсезме, чәчләреннән тартасызмы? Димәк, сез әле үсеп җитмәгәнсез. Олы кеше булу өчен, башка җенес вәкиле белән аралашу сәнгатенә өйрәнергә кирәк.

3. Ир-ат яисә хатын-кыз ролен кабул итү. Ир-егет булу нәрсә ул? Хатын-кыз булу ни дигән сүз? Ир-ат ничек күренергә тиеш, ә хатын-кыз — ничек? Алар үз-үзләрен ничек тотарга тиешләр? Тормышта кем булырга тиешләр? Малайларга — сугышлы, ә кызларга курчаклы уйнау гына җитми. Ир-ат һәм хатын-кызлар арасында олырак мөнәсәбәтләр булдырырга өйрәнергә кирәк. Әти-әниегез белән киңәшегез. Алар сезгә өлкәннәр дөньясында кемнең кем, нәрсәнең нәрсә икәнлеген танып белергә ярдәм итәрләр.

4. Әти-әниегездән һәм башка өлкән кешеләрдән эмоциональ бәйсезлеккә ирешү. Яшүсмер үзара аңлашуга, якын күрүгә һәм хөрмәт итүгә нигезләнгән, әмма эмоциональ бәйлелектән азат мөнәсәбәтләр урнаштырырга тиеш. Әти-әниләренә һәм башка өлкәннәргә каршы чыгучы һәм алар белән конфликтка керүче яшүсмерләр үзләрен һәм өлкәннәрне аңларга, бәхәснең сәбәпләрен ачыкларга өйрәнергә тиешләр.

5. Икътисади бәйсезлекне тәэмин итәрлек хезмәт эшчәнлегенә әзерлек. Яшьлекнең иң беренче бурычларыннан берсе булып һөнәр сайлау, һөнәри эшчәнлеккә әзерлек һәм егет яисә кызның үз-үзен мөстәкыйль рәвештә тәэмин итәрлек икътисади бәйсезлеккә ирешүе санала. Әлеге бурычның беренче өлеше сезнең тормыштан нәрсә таләп итүегезне ачыклаудан гыйбарәт. Икенче өлеше — һөнәр сайлау, һөнәри эшчәнлеккә өйрәнү һәм аны башлап җибәрү.

6. Никахлашуга һәм гаилә тормышына әзерлек. Күпчелек егетләр һәм кызлар бәхетле гаилә корырга телиләр. Мәктәптә үк акрынлап капма-каршы җенес вәкилләре белән дустанә мөнәсәбәт күнекмәләре, игътибар күрсәтү генә түгел, озакка сузылган һәм ныклы шәхесара мөнәсәбәтләр урнаштыру осталыгы да булдырылырга тиеш. Кызларга әниләренең тормыш тәҗрибәсенә, гаиләдә конфликтларны хәл итү, балалар карау һәм йорт хуҗалыгын алып бару осталыгына күз салырга, ә егетләргә — әтиләренең тормыш һәм социаль тәҗрибәсенә, акча эшләү, гаилә тоту, кабул ителгән карарлар өчен җавап бирү осталыгына, кызгана белү сәләтенә һәм киң күңеллелегенә игътибар бирергә тәкъдим ителә.

Яшүсмер чак проблемалары

Яшүсмер алдында торган бурычларны хәл итү байтак кыенлыкларны җиңүне таләп итә. Дөрес стратегия эшли белү бик мөһим. Мондый стратегия элек үзләштерелгән һәм үз-үзеңне гадәти тоту рәвешләре ярдәмендә хәл итәргә мөмкин булмаган яңа таләпләр белән очрашканда кирәк.

Болар барысы да тиешле сәләтләргә ия булуны күздә тота.

Кыенлыкларны җиңү процессы түбәндәгечә бара:

— башта вазгыятьне «беренчел бәяләү» була;

— аннан соң, тирә-юньдәгеләрдән көтелгән ярдәмне дә кертеп, шәхси мөмкинлекләр бәяләнә;

— ниһаять, уңышсызлыклардан чыгып яисә яңа мәгълүмат нигезендә яңача бурыч куюны һәм үз-үзеңне тотуның яңа вариантларын эченә алган проблеманы бәяләүгә күчәргә мөмкин.

Көндәлек язу проблемаларны хәл итү стратегиясенең бер мисалы булып тора. Егетләр көндәлекне башлыча җитлегү чорының башында язалар. Алар көндәлекне кызларга караганда уртача ике елга алданрак, барыннан да бигрәк, тышкы сәбәпләр аркасында яза башлыйлар. Алар өчен көндәлектәге фактик мәгълүмат мөһимрәк. Кызлар көндәлекне соңрак башлыйлар, ләкин аңардан озак аерыла алмыйлар. Аны «үзләренең көндәлек проблемаларын хәл итүдә тугры дус» итеп күрәләр. Егетләр көндәлегенең эчтәлеге аларның үзләренә яисә уртак шөгыль һәм көндәшлек белән бәйле иптәшләренә кагыла. Кызларны күбрәк эмоциональ проблемалар һәм рухи якынлык кызыксындыра. Алар еш кына туры сөйләм кулланалар һәм көндәлекләрен яшереп сакларга тырышалар.

Көндәлек язмалары җитлегү чорындагы проблемаларны хәл итүдә зур әһәмияткә ия, үз-үзеңне аңлауның мөһим формасы булып хезмәт итә.

Мөмкинлекләре чикле булса да, яшүсмерләр яңа дөньяга караш һәм әхлакый мәсьәләләр белән очрашалар. Балигълык яшендә ул проблемалар инде хәл ителгән була. Тормыш тәҗрибәсе җитенкерәмәү сәбәпле, алар өлкәннәр, балалар яисә картлардан күбрәк хата ясарга мәҗбүр булалар. Ләкин иң мөһиме — хаталарның санында түгел, ә сыйфатында, аларның җинаятьчелек, наркотиклар куллану, җенси тотнаксызлык, шәхесне ирексезләү кебек җитди нәтиҗәләргә китерүендә. Кайбер яшүсмерләр мәктәпне ташлыйлар, нәтиҗәдә җәмгыять тормышына керүнең табигый процессы бозыла. Белем алуның тәмамланмавы

шунда ук икътисади хәлдә чагыла, эш эзли башлагач, мондый үсмерләр, тулы белем алган яшьтәшләре белән чагыштырганда, начаррак хәлдә калалар. Нык үскән илләрдә 18 яше тулмаган кешеләр арасында эшсезлек өлкәннәргә караганда өч тапкыр югарырак.

Галимнәр сексуаль тотнаксызлык, исерткеч эчемлекләр белән шаяру, автомобильдә егетлек күрсәтәм дип, юл йөрү кагыйдәләрен бозу өлкәннәр ролен уйнарга маташу гына ул дип саныйлар. Мөгаен, мәктәпне ташларга омтылуның сәбәбе дә шулдыр. Мондый хаталар өчен аннан соңгы тормышың белән түләргә туры килү ихтималын да истән чыгарырга ярамый.

Яшүсмер чакның драматизмы организмдагы үзгәрешләрдән генә тормый. Җенесәргә тиешле проблемаларның әһәмияте дә алардан ким түгел. Ләкин бу кеше тормышының зарури чоры, аннан башка балигълыкка күчеп булмый.

Йомгак ясыйбыз

Күчеш чорында, әле олы кеше булырга да өлгермичә, яшүсмер балалар ия булган өстенлекләрне югалта. Җәмгыять, гаилә кагыйдәләре һәм гореф-гадәтләре системасын ул кискен кабул итә. Яшүсмердә бәйсезлеккә һәм карарлар кабул итүдә мөстәкыйльлеккә ихтыяҗ туа.

Белемегезне тикшерегез

1. Яшүсмерләр хәл итәргә тиешле бурычларны санагыз. Аларның бер ишесе мөһимрәк, икенчеләре алай ук түгел, дип әйтеп буламы?

2. Яшүсмерләрнең әти-әниләренә һәм башка өлкәннәргә бәйлелек чорын нәрсә озайта ала?

3. Сез кайсы гыйбарә яклы һәм ни өчен: «яшүсмер үз хаталарына караганда башкаларныкыннан күбрәк сабак ала»; «яшүсмер үз хаталарыннан һәм үз тәҗрибәсеннән күбрәк сабак ала»?

4. Яшүсмер чак проблемаларын читләтеп үтеп була дип саныйсызмы? Фикерегезне дәлилләгез.

Практикум

1. Шәхси тәҗрибәгездән, нәфис фильмнардан, спектакльләрдән, матур әдәбият әсәрләреннән чыгып, «Яшүсмер чак проблемалары» дигән темага хәбәр әзерләгез.

2. Әти-әниегез һәм өлкән туганнарыгыз белән «Яшүсмер чакта нинди проблемаларыгыз булды? Аларны нинди ысуллар белән хәл итә алдыгыз?» дигән темага әңгәмә үткәрегез.

3. Сез рус философы *А. Ф. Лосевның* (1893—1988): «...укучы барлык... эшләрдә бөтен нәрсә өлкәннәрдән генә тора дип уйламасын. Яхшы, чын укучы — әле балигъ булганчы ук, инде мөстәкыйль кеше. Ул, әлегә тар гына кысаларда булса да, үзе өчен үзе җавап бирә» дигән фикерен ничек аңлыйсыз? Җавап биргәндә, сез дәреслек параграфы эчтәлегеннән файдалана аласыз.

3. Зурлар булу

Җитлегү чоры

Яшүсмер чакны **җитлегү чоры** дип тә атарга мөмкин. Ул кешегә — егеткә дә, кызга да — җенси өлгерүнең беренче билгеләре белән килә. Яшүсмерләр бик тиз үсәләр (бигрәк тә үсмерлек чорының уртасында). Аларның тән пропорцияләре олыларныкына охшый башлый, психологияләрендә дә зур үзгәрешләр барлыкка килә. Барлык үзгәрешләр яшүсмернең тәртибендә, аның тирә-юньдәгеләргә, әти-әниләренә, яшьтәшләренә мөнәсәбәтендә чагыла.

Яшүсмер тизрәк зур кеше булырга теләгәнгә күрә, ул тиз арада аларның идеяләрен, идеалларын һәм үз-үзләрен күрсәтү ысулларын өлешчә кабул итеп, аңарда үз урынын табу омтылышы барлыкка килә. Тора-бара ул үзен өлкәннәргә тиң итеп саный башлый һәм, дуслары турында ничек уйласа, аларны да шул караштан чыгып бәяли. Яшүсмерләр, барыннан да элек, тыелган темаларга, «олыларча»

сөйләшә башлыйлар, әти-әниләрен күздә тотып, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрнең дөрес булу-булмавын «ачыклыйлар». Малайлар әтиләре белән физик көчләрен сынашалар, аларны җиңәргә тырышалар.

Балаларның игътибары бер предметтан икенчесенә җиңел генә күчә. Шул ук вакытта алар сәгатьләр буе үзләре өчен чынлап та кызыклы нәрсә белән мавыгып утыра алалар. Яшүсмерләр кайчакта тирә-юньдәгеләргә карата игътибарсыз һәм каты күңелле булып күренәләр, әмма якын кешеләренә карата җылы хисләрен һәм яратуларын, булышырга һәрвакыт әзер торуларын күрсәтергә мөмкиннәр. Ул бер үк вакытта игътибарлы һәм игътибарсыз да, сак һәм алдан уйлап бетермәүчән дә, каршылыклы һәм көтелмәгән дә. Боларның барысында да яшүсмер чакның асылы ачыла.

Бу — контрастлар, үзгәрешләр, экспериментлар ясау һәм үсеш чоры. Аларның эзләнүләре, олылар дөньясына якынаеп, тормышта үз юлларын табарга ярдәм итә. Ә бу сайлау,— мөгаен, әлеге этапта иң мөһим бурычтыр.

Яшүсмер вакытта кеше үзенең олы кеше буларак образын сайлый башлый. Кайгысыз балачак узды. Әхлакый һәм һөнәри проблемаларны хәл итү белән җитди рәвештә шөгыльләнергә вакыт җитте.

Әле генә әхлакый нормаларны үзләштергән, ләкин әле аларны бөтен тирәнлеген дә аңламаган егетләр һәм кызлар аерым бер олы кешеләргә генә түгел, гомумән, тулаем җәмгыятькә мораль бәя бирергә тырышалар. Бу бәяләрнең ике үзенчәлеге бар. Беренчедән, алар бик кискен һәм катгый. Икенчедән, алар үзләре теләгән яки идеаллаштырган

Истә калдырырга киңәш итәбез

Альтруизм (*фр.* altruisme, *лат.* alter — башка) — башка кешеләр хакын риясыз хаклау, кайгырту, эгоизмның киресе.

позициядән чыгып бирелә. Алар җәмгыять төзелешенең никадәр катлаулы булуын белеп бетермиләр әле.

Яшүсмерләр үз аңнарында тудырылган яисә китап һәм фильмнардан алынган ниндидер бер идеалга таяналар. Яшүсмернең булган әйберне булырга мөмкин әйбер белән чагыштыру сәләте аны еш кына бунтарь-идеалистка әйләндерә. Мөмкин булган нәрсәне чынбарлык белән чагыштырып, ул соңгысының идеаллардан ерак булуын аңлый һәм еш кына тәнкыйтьче рәвешен ала. Яшүсмерләр бертуктаусыз тормышны аңларга, төшенергә тырышалар. Шуңа күрә аларда кеше хәленә керә белү сәләте барлыкка килә. Авыр тормыш халәтендә психологик яктан якланмаганлыктан яшүсмер үзен рәхимсез җәмгыятьнең зәгыйфь, мескен корбаннары белән тиңләштерергә мөмкин. Аларның гаделсезлекне кабул итүләре шәхси эчке кичерешләрен чагылдыра. Алар үзләренә генә түгел, тирәюньдәге олы кешеләргә дә тәнкыйть күзлегеннән карый башлыйлар. Соңрак, инде яшьлеккә аяк баскач, кеше үз идеалларын анык гамәлләр белән бәйләп карый, мөмкинлекләрен барлый, «хыял диңгезендә йөзүдән» туктый. Ул аңлаучан, сабыр була башлый. Егет кеше чын-чынлап эшкә кергәч җитлегеп бетә. Нәкъ менә шул вакытта ул реаль казанышларга омтылучы кешегә әверелә.

Яшүсмер чак, мөгаен, иң каршылыклысыдыр. Ул — һәркем өчен зур сынау чоры. Аны үзең генә узу бик катлаулы, янәшәдә зирәк остаз — олы кеше булырга тиеш. Дөньяга киң карашлы, тормышны яхшырак белүче, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең никадәр катлаулы икәнлеген белгән, һөнәре һәм осталыгы булган **олы кеше** генә яшүсмергә тормыш турындагы белемнәр капиталын тапшыруга сәләтле.

Яшүсмерне тәрбияләү

Яшүсмерне тәрбияләү нәни баланы тәрбияләүдән еш кына бик нык аерыла. Өлкәннәр арсеналында таләпчәнлек һәм дисциплина һәрвакыт саклана шикелле. Шулай да балага 12—13 яшь тулгач, күпчелек ата-ана аның инде шактый зур булуын һәм аңа карата кечкенә вакыттагы ысулларның кулланыла алмавын аңлый башлый.

Кызыклы фактлар

Примитив җәмгыятьтә балалар җаваплылыкның ни икәненә гаять иртә төшенәләр. 6—7 яшеннән баланы ике төрле мөнәсәбәткә — буйсынуга һәм хакимлек итүгә күнектерәләр. 10 яшьлек кызчыкның энекәшләрен һәм сеңелкәшләрен тәртипкә өйрәтүен, бер үк вакытта өлкәннәр кушканны һичшиксез үтәвен еш күзәтергә мөмкин. Европа культурасында, һәрчак булмаса да, бала мөнәсәбәтләрнең бер генә төренә өйрәтелә —ул барысына да буйсынырга тиеш. Шуңа күрә аның олы тормышка күчүе катлаулана: аңа әйләнә-тирәдәгеләр белән мөнәсәбәтләрен үзгәртергә кирәк була.

Шуңа күрә психологлар, яшүсмерләр үз юлларын сайлаганда, аларга күбрәк ирек бирергә киңәш бирәләр. Алар яшьләрне олылар җәмгыятенә яшьли алырга тәкъдим итәләр. Түләүле эшкә керү, эш көне йә атнасы тулы булмаса да, яшүсмернең финанс бәйсезлеген тәэмин итәргә мөмкин. Галимнәр егет һәм кызларга җәмгыятьнең социаль һәм сәяси тормышында күбрәк хокук бирергә кирәк дип саныйлар. Әлеге чаралар яшьлектән олы тормышка аңлабрак күчүне тәэмин итә алырлар иде.

Йомгак ясыйбыз

Яшүсмернең җитлегүе бәйсезлек һәм җаваплылыкны аңлау дәрәҗәсе белән билгеләнә.

Җитлегү дәрәҗәсе һәм тизлеге бик күп шартларга бәйле. Эшләү, якыннарың турында кайгырту зарурлыгы җитлегү процессын тизләтә. Эш хакы алу мөмкинлеге тугач, билгеле бер финанс бәйсезлеге барлыкка килә. Әгәр дә яшүсмер гаилә алдындагы вазифалары турында да онытмаса, ул инде, — чыннан да, олы кеше булды дигән сүз.

Белемегезне тикшерегез

1. Яшүсмернең гомумиләштерелгән характеристикасын төзегез. Бу яшьнең нинди аерымлыклары бар?

2. Яшүсмернең җитлегүенә нинди тормыш шартлары йогынты ясый?

3. «Олы кеше» төшенчәсенең мәгънәсен аңлатыгыз.

4. Сез «Хәзерге яшүсмерләр тормышка азрак яраклашкан» дигән сүзләр белән килешәсезме?

Практикум

1. «Мин олы кеше булырга телим, чөнки...», «Мин олы кеше булырга ашыкмыйм, чөнки...» дигән фразаларны дәвам итегез.

2. Сез ничек уйлыйсыз, ата-ана яшүсмергә кайчан олы кешегә карагандай карый башлый?

а) Алар аның фикере һәм тойгылары белән санаша башлагач;

б) аның кем белән китүен һәм өйгә кайчан кайтуын контрольдә тотудан туктагач;

в) ул акча эшли башлап, алар бу фактны таныгач;

г) ул үз гамәлен аңлап сайлый һәм моның өчен үзе җавап бирә ала башлагач.
Үз дәлилләрегезне китерегез.

§ 4. Яшүсмерләрдәге физик үзгәрешләр

Яшүсмер чак — организмның көчле һәм тигезсез үсеш вакыты; бу чорда гәүдә интенсив үсә, мускул аппараты камилләшә, скелетның сөяккә әйләнү процессы бара. Йөрәк һәм кан тамырлары үсешенең туры килмәве, тигезсез баруы, шулай ук эчке секреция бизләренең көчле эшчәнлеге еш кына кан әйләнешенең вакытлыча бозылуына, кан басымының күтәрелүенә, йөрәк эшчәнлегенең киеренкеләнүенә, шулай ук яшүсмерләрнең ярсучанлыгына китерә, бу исә аларның кызып китүчәнлегендә, тиз талчыгуында, баш әйләнүдә һәм йөрәк тибешендә чагылыш табарга мөмкин. Үсмернең нерв системасы көчле яисә озакка сузылган киеренкелекне күтәрә алмый һәм аның тәэсире астында еш кына тормозлану яисә, киресенчә, көчле ярсучан халәткә күчә.

Буйга үсеп китү иң беренче һәм сизелерлек физик үзгәрешләрнең берсе булып тора.

Төрле еллар статистикасы хәзерге балаларның ата-бабаларына караганда озынрак буйлы булуын күрсәтә. Бу, барыннан да бигрәк, яхшы туклану, медицина хезмәте күрсәтү, физик күнегүләр ясау, ял итү һәм үз көчләрен торгызу мөмкинлеге булу аркасындадыр. Бүген кеше җенси яктан да элеккегә караганда күпкә тизрәк өлгерә.

Хәзерге заман мәгълүматлары күрсәткәнчә, уртача җенси өлгерү чоры — 13 яшьләр тирәсе. Шул ук вакытта малайларның һәм кызларның буйлары төрлечә үзгәрә. Кызлар чама белән 12 яшьтә тиз үсәләр. Малайларның буе һәм авырлыгы якынча 14 яшьтә бик тиз арта. Бала вакытта кызлар, гадәттә, үз яшьләрендәге малайлардан буй һәм авырлык ягыннан калышалар. Ләкин алар алданрак өлгерә башлыйлар һәм 10 яшьтән башлап малайларны — авырлык буенча, ә 12 яшьтән буйга узып китәләр. Малайларның һәм кызларның буй һәм авырлыкларының мондый чагыштырмасы якынча 14 яшькә кадәр саклана.

Кешенең үсешенә күп төрле факторлар, шул исәптән дөрес тормыш режимы, аерым алганда, хезмәт, ял, йокы һәм туклану, физик тәрбия һәм спорт режимнары йогынты ясый. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, актив үсеш елларында яхшы тукланган балалар тулы кыйммәтле тукланмаган балалардан озынрак буйлы булалар. Хәзерге заман җәмгыятендә яшүсмернең үсешенә туклануның сыйфаты да тәэсир итә. Әгәр дә балалар вакытында ашамаса, корысары ашаса, концентратларны күп кулланса, кагыйдә буларак, алар начар үсәләр һәм соң җитлегәләр.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Динамизм (динамика) — хәрәкәт, үсеш, эчке энергия.

Кызыклы фактлар

Британия яшүсмерләренең дөрес тукланмавы

Британия сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан бастырып чыгарылган сорау алу нәтиҗәләре бу илдә күпчелек балалар һәм яшүсмерләрнең дөрес тукланмавын күрсәтте. Экспертлар фикере буенча, аларның рационында даими туклану өчен яраксыз ризыклар — чипс, шоколад, печеньелар — аеруча күп, ә җиләк-җимеш һәм яшелчә бик аз.

Британия яшүсмерләренең һәр бишенчесе атналар буе җиләк-җимеш һәм яшелчә ашамый, ә тиз әзерләнә торган һәм коры ризык белән тукланып йөри. Дөрес тукланмауның нәтиҗәләре күпчелек балаларның аз хәрәкәтләнүе аркасында тагын да катлаулана, җитмәсә, кызлар малайлардан да пассиврак була бара.

Күпчелек үсмерләр ризык белән бергә тозны артык күп кулланалар, витаминлы һәм минераль өстәмәләрне кирәгеннән артык файдаланалар. Галимнәр рациональ туклану кагыйдәләрен сакламау киләчәктә аларның сәламәтлегенә зур куркыныч тудыра дип шөбһәләнә. Клетчаткага бай яшелчәләрне җитәрлек кулланмау рак (аеруча эчәклек рагы) белән авыручыларның күбәюенә китерергә, ә углеводларга бай продуктларны кирәгеннән артык куллану симерүгә сәбәпче булырга мөмкин.

Белгечләр балаларның һәм яшүсмерләрнең мәктәпкә әти-әниләренең машиналарында, йә мәктәп автобусында түгел, ә җәяү яисә велосипедларда йөрүен хуплаган яңа схемалар эшли. Бу гиподинамия проблемасын хәл итәргә мөмкинлек бирә. Азык-төлек сәнәгатенең иң эре предприятие вәкилләре балалар арасында файдалы азык-төлекне, бигрәк тә җиләк-җимеш һәм яшелчәләрне пропагандаларга әзер икәнлекләрен белдерделәр.

Тышкы күркәмлекнең нинди критерийларын атар идегез? Фикерегезне дәлилләгез.

Баланың үсешенә шулай ук илдәге сәяси һәм икътисади вазгыять тә йогынты ясый. Төрле хәрби конфликтлар массакүләм ачлыкка, туклануның бик нык начарлануына китерә. Икенче бөтендөнья сугышы елларында һәм ул тәмамланганнан соңгы беренче унъеллыкта бик күп балалар буйга җитәрлек үсмәде.

Фәнни мәгълүматлар хәзерге вакытта кешенең үсеш процессы тизләнә баруны күрсәтә. Хәзерге заман балалары һәм яшүсмерләре моннан 60 йә 70 ел элеккегә караганда тиз үсү чорына алданрак керәләр һәм үсүдән дә элегрәк туктыйлар. Нормаль сәламәт кыз бала әнисеннән 1,3—2,5 сантиметрга биегрәк. XIX—XX гасырлар чигендә кызлар үсүдән 18—19 яшьтә туктаганнар, ә бүген 16 яшьтә туктыйлар. Соңгы йөз елда олы ир-атның буе 6—9 сантиметрга артты. 1880 елда ирләр 23—25 яшькә генә буйга үсеп җиткәннәр. Ә хәзер егетләр 18 яшьтә үк үсүдән туктыйлар. Хәзерге заман уртача статистик ир заты 42—43 үлчәмле аяк киеме кия, ә аның бабасы 39 үлчәмле аяк киеменнән йөргән. XVIII гасыр театрында тамашачы урындыгының киңлеге 45 сантиметр була. Ә бүген уңайлы урындыкның киңлеге 60 сантиметрдан ким булмаска тиеш.

Тышкы күркәмлек

Яшүсмерләр гәүдә һәм тышкы кыяфәтләре үзгәрүне бик нык тоялар, шуңа алар үз кыяфәтләре турында бик нык кайгырта башлыйлар. Аларны күркәм күренү, тән

төзелеше, авырлык кебек мәсьәләләр борчый. Яшүсмерләр үзләренең нормаль үсешләрен игътибар белән күзәтәләр.

Еш кына кешенең үз-үзенә нинди бәя бирүе генә түгел, ә дуслары һәм танышларының бәясе дә аның тышкы кыяфәтенә бәйле. Кайчак шулай да була: малай белән аның яшьтәшләре ул симез яисә тотлыгучан булган өчен генә дә дуслашмыйлар. Күркәм тышкы кыяфәткә ия үсмерләр исә, кагыйдә буларак, яшьтәшләренең уңай мөнәсәбәтенә лаек булалар. Алар сизгер, игелекле, акыллы һәм уңышка ирешүчән булып саналалар. Матур һәм төз буйлы кешеләр шәхесара мөнәсәбәтләрне тизрәк урнаштыра. Матурлар һәм төз буйлылар үзләренә магнит кебек тартып тора. Бу бигрәк тә кешедә иң мөһиме тышкы кыяфәт түгел, рухи сыйфатлар (рух) икәнлеген әле аңларга өйрәнмәгән яшьтәгеләргә хас.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, уртак фикер буенча күркәм үсмерләрнең ата-аналары, яшьтәшләре белән үзара мөнәсәбәтләре күркәм түгел дип саналганнардан яхшырак була. Башка кешеләр белән үзара мөнәсәбәтләрегезгә тышкы кыяфәтегез тәэсир итсә, димәк, уйланырга сәбәп бар дигән сүз.

Кешенең тышкы кыяфәте аның шәхес буларак үсешенә дә йогынты ясый. Үз кыяфәтеннән оялучы еш кына йомыкый, тиз кабынучан, тынычсыз кеше булып үсә. Аның үз-үзеннән канәгатьсезлеге елдан-ел арта бара. Канәгатьсезлек психологлар **тулы кыйммәтсезлек комплексы** дип аталган нәрсәгә әверелә. Иң яхшысы — тулы кыйммәтсезлек комплексы барлыкка килү сәбәпләрен аңлау һәм аны җиңәргә тырышу.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Үз-үзеңә бәя бирү — кешенең үз-үзенә, үзенең тышкы кыяфәтенә һәм эчке дөньясына бәя бирүе (ул югары, уртача һәм түбән булырга мөмкин).

Тулы кыйммәтсезлек комплексы — үзеңнең нинди дә булса кимчелекләреңне яисә нәрсәгәдер (кыю адымнарга, музыка яисә математика белән шөгыльләнүгә һ. б.) сәләтсезлегеңне тотрыклы рәвештә тою хисенең бәйләнчек идеягә әверелүе.

Кешенең тән төзелешенең төп өч төрен аерып карыйлар, нигездә, бу яшүсмерләргә кагыла.

Беренче төр — баскетболчы тән төзелешен хәтерләткән озын, ябык, сөякчел фигура.

Икенче төр — тыгыз, нык мускуллы гәүдә, киң иңбашлар һәм уртача озынлыктагы аяк-куллар, көчле һәм чыдам атлет тән төзелеше.

Өченче төр — түгәрәк, таркау, авыр гәүдә һәм юан аяккуллар, көрәшче тән төзелеше.

Тормышта безнең күпчелегебез шушы өч төрнең катышмасыннан (дөрес, бер төр өстенлек итә) тора. Кагыйдә буларак, егетләр һәм кызлар урта тән төзелешле булырга телиләр. Тышкы кыяфәт аркасында шөбһәләнү башка үсмерләрнең көлеп каравын арттырырга мөмкин. Иң яхшы чара — барысын да юмор белән кабул итү: «Мин, мәсәлән, спорт секциясенә язылып яхшы якка үзгәрә алам әле, ә менә син бу корткыч характерың белән нишләрсең?»

Яшүсмерләрнең тигезсез үсеше

Яшүсмерләрнең үсеше тигез генә бармый. Аларның барысы да уртача стандартларга сыймый. Кайберәүләр үсештә башкаларны узып китә һәм иртә җитлеккәннәргә керә, икенче берәүләр калыша һәм соң җитлеккән санала. Теләсә нинди тайпылыш, кагыйдә буларак, өстәмә проблемалар тудыра. Малайларның иртә җитлегүе яхшы дип санала һәм ул, гадәттә, аларның үз-үзләренә уңай бәя бирүләре белән бәйле. Малайларны соң җитлегү борчый, ә кызларда бу сизелмичәрәк үтә. Иртә җитлегүчән малайлар үз яшьләреннән өлкән күренәләр, буйга озынрак булып мускуллары яхшырак сизелә, хәрәкәтләре ышанычлы була. Әтиләре аларга үз ярдәмчеләре итеп карыйлар.

Тән төзелешендәге өстенлек аларга спортта җиңәргә, яшьтәшләре арасында лидер булырга мөмкинлек бирә. Андый яшүсмерләр зурлар белән тигез хокуклы мөнәсәбәтләр корырга тырышалар. Соң җитлеккән малайлар тулы кыйммәтле булмау хисе кичерәләр. Гадәттә, аларны яшьтәшләре арасында бик үк өнәп бетермиләр һәм алар популярлык казана алмыйлар, тынычсыз булалар, команда бирергә яраталар, әти-әниләренә каршы сөйлиләр һәм

Кызыклы фактлар

Россия Фәннәр академиясенең (РФА) Социология институты хезмәткәрләре төркеме Мәскәү мәктәпләренең 6—11 сыйныфларында укучылар арасында сорашу үткәрде. Үзләренең тышкы кыяфәтләрен бәяләү турында сорау бирү нәтиҗәсендә кече яшьтәге мәктәп балаларының бу мәсьәләгә күбрәк тәнкыйть күзлегеннән каравы ачыкланды. Мәктәп балаларының уртача 9% ы үз кыяфәтләрен «куркәм түгел» дип саный; 42% ы —«уртача»; 27% ы — «күркәм» дип исәпли. 6—7 сыйныфларда бу саннар 12, 47, 20% ка тигез, ә 8—9 сыйныфларда — 8, 47, 26%. Ә өлкән сыйныфларда 37% укучы үзләрен «күркәм», 31% ы «уртача» дип саный.

даими рәвештә үзләренең шәхси бәйлелекләрен тоялар, еш кына оялган булалар. Күпләр үз эчләренә бикләнә, эчке киеренкелек кичерә. Андый үсмерләрдә кирәгеннән артык бәйлелек яисә рәнҗетүләргә йә аларның ирегең кысуларга сизгерлек хисе көчәя.

Мондый үсмерләр спорт ярышларыннан читләшәләр, аның каравы интеллектуаль әңгәмәләрдә һәм төрле фәннәр буенча олимпиадаларда бик теләп катнашалар. Алар үзлегеннән белем алуга зур игътибар бирәләр, бу өлкәдә тагын да зуррак уңышларга ирешергә омтылалар.

Йомгак ясыйбыз

Яшүсмерләрдәге физик үзгәрешләр нәселдәнлек, туклану, яшәү мохите кебек факторларга бәйле. Бу факторлар исә берберсе белән дә үзара бәйләнгән. Үсү чорында үз-үзеңне бәяләү һәм тирә-юньдәгеләрнең сине бәяләве кебек психологик проблемалар тышкы кыяфәт үзгәрү белән тыгыз бәйләнештә карала.

Белемегезне тикшерегез

1. Яшүсмер чакта нинди физик үзгәрешләр күзәтелә?

2. Төрле халыкларда һәм төрле вакытта тышкы күркәмлекне төрлечә аңлаганнар. Ә күркәмлеккә бердәй караш турында сөйләргә буламы?

3. Еш кына озын буйлы кешеләр — кыскарак, кыска буйлылар, киресенчә, озынрак булырга тели, тулы гәүдәлеләр — ябыгырга, ә ябыклар тазарырга хыяллана. Блондинкалар — кара чәчле, ә брюнеткалар ак йөзле, аксыл-сары чәчле булырга тели. Сез моны ничек аңлатыр идегез?

4. Ни өчен кыяфәтеңне ничек бар, шулай кабул итү мөһим?

Практикум

1. Дустыгыз классташлары яисә яшьтәшләре тарафыннан үз кыяфәте турында мыскыллы шаяртуларга дучар була дип, күз алдына китерегез.
Аңа ни эшләргә киңәш итәр идегез һәм ничек булыша аласыз?

2. «Яшүсмер чакта үз кыяфәтеңне ничек яхшыртырга була» дигән темага файдалы киңәшләр исемлеге төзегез.

3. Сезнең яшьтә спортның нинди төрләре яхшырак дип саныйсыз? (Малайлар өчен, кызлар өчен.) Физкультура укытучысы белән киңәшегез.

Спартал ыларның сурәтләреннән чыгып аларның тормыш рәвеше турында нәрсә әйтергә мөмкин?

Бирем

Сез Антик чорны өйрәндегез һәм спарталыларның тәрбия системасы белән таныш инде. *Борынгы Спарта* дошманнарны һәрчак җиңеп килгән кыю һәм физик яктан көчле сугышчылар үстерә. 300 спарталының каһарманлыгына бөтендөнья ике мең ярым ел буена соклана инде. Күпләр физик чыныгуны, егетләргә куелган авыр сынауларны педагогик идеал итеп саный. Сәламәт тәндә сәламәт рух булырга тиеш.

Ләкин башкача караш та бар. Аны кайбер Америка психологлары әйтә: «Спарталылар яшьләрне, үзләренең кырыс җәмгыяте ихтыяҗларыннан чыгып, артык физик сынауларга дучар итәләр. Алар моңа аңлы рәвештә бара, әмма яшь кешеләрне күпләп югалту нәтиҗәсендә җәмгыять эчтән җимерелә».

Димәк, спарталылар безнең тормыш өчен һич тә идеал түгел. Кирәгеннән артык көч кую стрессларга һәм иртә үлемгә китергән. Ә бәлки, хәрәкәт, физик йөкләмәләр җитәрлек булмаган хәзерге заманда безгә спарталылар ысулы кирәктер дә?

Бу турыда нәрсә уйлыйсыз? Уйлап кына җавап бирегез һәм аны нигезләгез.

5. Шәхеснең психологик портреты: темперамент һәм характер

Шәхес

«Шәхес» (личность) сүзе «лицо», «личина» сүзләреннән барлыкка килгән. Борынгы Греция, аннан соң Борынгы Рим театрларында актер сәхнәгә теге яки бу характерның — явыз, кәмитче, каһарман — сыйфатлары эре итеп төшерелгән (иң арткы рәтләрдән дә күренсен өчен) битлек киеп чыккан. Битлектәге буяулар кешенең әхлакый һәм психологик сыйфатларына ишарәләгән. Кеше шәхесенең нигезен нәкъ менә шулар тәшкил итә. **Шәхеснең психологик портреты** түбәндәге төп сыйфатларны үз эченә ала:

1) темперамент; 2) характер; 3) сәләтләр; 4) интеллект; 5) хисләр; 6) эмоцияләр.

Темперамент

Кешеләрне, аларның ничек эшләүләрен, укуларын, аралашуларын, шатлык һәм кайгыны ни рәвешле кичерүләрен күзәткәндә без, һичшиксез, аларның тәртибендәге аермаларга игътибар итәбез. Берәүләре — өлгер һәм омтылучан, хәрәкәтчән, көчле эмоциональ реакцияләргә тартылучан, икенчеләре акрын, тыныч, борчылмаучан, хисләрен бик сиздермиләр һ. б. Мондый аерымлыкларның сәбәбе — кешенең аңа туганда ук бирелгән темпераментында.

Кызыклы фактлар

Темперамент турындагы тәгълиматка борынгы грек табибы *Гиппократ* нигез сала. Ул кеше тәнендә төп дүрт сыекча — кан, лайла, үт һәм кара үт бар дип саный. Дүрт төрле темпераментка әлеге сыекчаларның атамасы буенча бирелгән исемнәр безнең көннәргә кадәр саклана: холерик («үт» (желчь) сүзеннән килеп чыккан); сангвиник («кан» сүзеннән); флегматик («лайла» сүзеннән) һәм меланхолик («кара үт»тән). Гиппократ кешенең темпераментын, аның җанында барган процессларның темпын, ритмын, интенсивлыгын теге яки бу сыекчаның күбрәк булуы белән аңлата:

1) сангвиник — нерв системасы басынкы, сабыр, хәрәкәтчән булган кеше (аның формуласы — «ышан, ләкин тикшер»);

2) холерик, киресенчә, сабырсыз тип (аның формуласы — «бер минут тынгылык юк»);

3) флегматик — нерв системасы көчле, ләкин хәрәкәтчән түгел (аның формуласы — «ашыктырма»);

4) меланхолик — нерв системасы көчсез һәм сабырсыз тип (аның формуласы — «зарар китермә»).

Сангвиникның тормыш сөючәнлеген, мавыгучанлыгын, кеше хәленә керә белүен, аралашучанлыгын уңай сыйфатларга кертергә була. Тискәре сыйфатлары — минминлек, бер чиктән икенчесенә ташлану, җиңел акыл-

лылык, өстән-өстән генә фикер йөртү, артык аралашучанлык һәм ышанычсызлык. Сангвиник, башкаларны үпкәләтмәс өчен, вәгъдәләрне күп бирә, ләкин аларны үтәргә генә ашыкмый. Ул даими контрольгә мохтаҗ.

Холерикның өстенлекләре: энергияле, мавыгучан, дәртле, хәрәкәтчән, максатка омтылучан. Йомшак яклары: тиз кызып китүчән, агрессив, сабырсыз, конфликт тудыручан. Холерик һәрвакыт эш белән мәшгуль булырга тиеш, юкса ул үз активлыгын коллективка юнәлтергә һәм аны эчтән таркатырга мөмкин.

Флегматик тотрыклы, тугрылыклы, актив, түзем, үз-үзен кулда тотучан, ышанычлы. Ләкин аңа акрынлык, битарафлык, «калын тиреле булу», корылык хас. Нинди дә булса эшне башкарып чыгу өчен аңа күбрәк вакыт таләп ителә. Аны ашыктырырга ярамый, ул үз вакытын үзе исәпли һәм эшне башкарып чыга.

Меланхолик — сизгер һәм тиз җәрәхәтләнүчән кеше, ул башкаларга игелек тели һәм максимум теләктәшлек күрсәтә. Җитешсез яклары: эшкә сәләте түбән булу, үзе турында югары фикердә тору, үз эченә бикләнгәнлек, оялчанлык. Меланхоликка кычкырырга, бик нык басым ясарга, кискен һәм катгый күрсәтмәләр бирергә ярамый, ул интонацияләргә һәм үзенә мөрәҗәгать итү рәвешенә карата бик сизгер. Әгәр сез хискә бирелүчән меланхолик икәнсез, димәк, сез бик әйбәт дус.

Әгәр сез флегматик икәнсез, сезгә «таш дивар артына яшеренгәндәй» якыннарыгыз һәм дусларыгыз сыена ала, чөнки сез бик ышанычлы кеше. Әгәр дә холерик икәнсез, уңышлы тормыш карьерасына исәп тота аласыз, чөнки максатларны бик яхшы куя һәм аларга ирешә беләсез. Сангвиник булсагыз, сездән җылы кояш яктысы бөркелә, кешеләргә бусы да бик кирәк.

Характер

Характер үзен шулай ук тотрыклы тәртип үзенчәлекләре җыелмасында күрсәтә. Ләкин темпераменттан аермалы буларак, характер тумыштан килми. Ул, барыннан да бигрәк, җитлегү барышында формалаша. Нәселдән килгән характер үзенчәлекләренә тәрбия нәтиҗәсендә бирелгәннәре, нигездә әхлакый сыйфатлар өстәлә.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Шәхес — иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең билгеле бер системасында формалашкан иҗтимагый зат буларак кеше. Шәхес характеристикасында төп нәрсә — аның дөньяга карашы белән турыдан-туры бәйләнгән иҗтимагый юнәлгәнлеге.
Темперамент (*лат.* temperamentum — өлешләрнең тиешенчә кушылуы) — кешенең, барыннан да бигрәк, хисләр барлыкка килү тизлеге һәм аларның көче белән характерланучы индивидуаль-психик сыйфатлары җыелмасы. Темперамент шулай ук кешенең хәрәкәтләнү үзенчәлегендә дә чагылыш таба.
Характер (*грек.* character — мөһер, сыйфат, үзенчәлек) — кешенең тәртибендә, эшчәнлегендә күренүче индивидуаль тотрыклы психик үзенчәлекләре җыелмасы.

Кешенең характерына уңай яктан бәя биргәндә, хезмәт сөючәнлек, эшкә намуслы караш, җаваплылык, инициативалылык, аралашучанлык, кайгыртучанлык, үз дәрәҗәңне белү, үзеңә тәнкыйди караш, тыйнаклык, пөхтәлек, сакчыллык, юмартлык; тискәре яктан караганда, ялкаулык, җавапсызлык, пассивлык, рәхимсезлек, тупаслык, кешеләргә түбәнсетеп карау, үзең турында артык югары фикердә булу, дан ярату, борын чөю, тиз үпкәләү, эгоистлык, саранлык, тәртипсезлек кебек сыйфатлар турында сөйләргә туры килә.

Характерның үзәген шәхеснең әхлакый-ихтыяри сыйфатлары тәшкил итә. Көчле ихтыярлы кешенең теләкләре һәм эш гамәлләре анык билгеле була, ул мөстәкыйль булуы белән аерылып тора. Ул үз максатларына ирешүдә катгый һәм нык ихтыярлы. Ихтыярсызлык, гадәттә, йомшак характерлы булуга тиңләп карала. Ихтыярсыз кеше, зур белемле һәм бик сәләтле булса да, үзенең барлык мөмкинлекләрен гамәлгә ашыра алмый.

Йомгак ясыйбыз

Шәхеснең психологик портреты нигезләре тумыштан салына. Аның нигезен психик процесслар нигезендә барлыкка килгән темперамент тәшкил итә. Психологик портретның иң мөһим өлеше — төрле факторлар йогынтысында формалашкан характер. Үзгәрешләр кертергә теләк булганда һәм шәхес ягыннан өстәмә көч куелганда, характерны үзгәртеп була. Бер үк вакытта психологик портрет та үзгәрә.

Белемегезне тикшерегез

1. «Шәхес», «темперамент», «характер» төшенчәләренең мәгънәсен ачыгыз.

2. Характерның уңай һәм тискәре якларын санап чыгыгыз. Нинди характерны сайлавыгызны аңлатыгыз.

3. «Характерсыз кешенең характерыннан да төссезрәк нәрсә юк» дигән әйтемнең мәгънәсен ничек аңлыйсыз?

4. «Теләк булганда начар характерны төзәтеп була» дигән раслау белән килешәсезме?

5. Сезнеңчә, начар тәртипне (гамәлне) характерның катлаулы булуы белән аклап буламы? Җавабыгызны аңлатыгыз.

Практикум

1. Үзегезне күзәтегез һәм үз темпераментыгыз төрен билгеләргә тырышыгыз. Мөгаен, үзегездә темпераментның төрле төрләренә хас үзенчәлекләрне табарсыз.

2. «Мин үз характерымдагы түбәндәге сыйфатлардан котылырга теләр идем» дигән темага кечкенә генә инша языгыз.



6. Шәхеснең психологик портреты: интеллект, эмоцияләр һәм хисләр

Сәләт һәм интеллект

Кешенең **сәләте** ул анык, әйтик, математика яисә музыка өлкәсендәге бурычларның ничек тиз һәм уңышлы хәл ителүенә бәйле рәвештә билгеләнә. Сәләт ул кешенең нәрсә белән булса да (скрипкада уйнаумы йә булмаса маркалар коллекцияләүме) көчле мавыгуында һәм мәгълүм бер шөгыльгә яисә эшчәнлеккә тартылуында чагылыш таба.

Мәктәп яшендә кешенең *гомуми сәләтләре*: хезмәт сөючәнлек һәм эшкә сәләтлелек; игътибарлылык, җыйнаклык, максатка омтылучанлык, күзәтүчәнлек; иҗади фикерләү, зирәклек, авыр хәлләрдә ориентлаша белү һ. б. формалаша. Соңрак һөнәр сайлау һәм эш тәҗрибәсе белән бәйле *махсус сәләтләр* дә ачыла. Ләкин кайбер кешеләрдә алар (мәсәлән, музыкаль һәм тикшеренү сәләтләре) мәктәп эскәмиясендә үк барлыкка килә.

Теләсә нинди проблемада иң мөһимен аерып карарга, аны өлешләргә бүлеп анализларга һәм хәл итү юлларын табарга сәләтле кеше генә **интеллектка** ия.

Интеллект гадәти булмаган хәлләрдә аеруча мөһим. Чөнки яңа бурычларны хәл итү өчен, иске ысуллар инде яраксыз булып чыга. Интеллект кешенең яшенә, белем дәрәҗәсенә, индивидуаль сәләтләренә бәйле. Интеллект мантыйклы (логик) фикер йөртү һәм исәп-хисап ясау, максат кую һәм хисләрне, фикер һәм реаль гамәлләрне аңа ирешүгә юнәлтү, гади һәм катлаулы, аеруча мөһим һәм икенчел дәрәҗәдәге проблемаларны бәяләү сәләтендә күренә.

Хис һәм эмоция

Хис һәм эмоцияләр кешегә ни өчен кирәк?

Хисләр — күп санлы психик күренешләрнең гомумиләштерелгән атамасы. Көндәлек тормышта без ачыгу, сусау, авырту хисләре; күңелле һәм күңелсез хәлләр; ару, авыру һәм саулык; шатлык һәм кайгы, мәхәббәт һәм нәфрәт; кот очу, оятлы булу, курку, соклану, кайгы уртаклашу; өметсезлек һәм рәхәтлек хисләре кичерү турында сөйлибез. Шулай итеп, хисләр үзләренең дәвамлылыгы һәм көче, дәрәҗәсе, характеры һәм эчтәлеге (кыска вакытлы һәм дәвамлы, җиңел эмоцияләр һәм тирән, тотрыклы хисләр) ягыннан аерылып торган күп кенә күренешләрне үз эчләренә алалар. Барлык хисләр *аффектларга, эмоцияләргә, хисләрнең үзенә, кәеф-рухларга һәм стресс халәтләренә* бүленә.

! Истә калдырырга киңәш итәбез

Кешенең сәләте — кешенең нәрсә дә булса эшли белүендә, билгеле бер шөгыльгә йә һөнәргә тартылуында күренгән индивидуаль үзенчәлекләре.

Интеллект — танып белү һәм мантыйклы фикер йөртү сәләте.

Аффект — кешенең аерым бер халәте ул. Аффект кешенең бөтен уйларын һәм хәрәкәтләрен үзенә буйсындыра. Ул һәрвакыт анык бер хәл белән бәйләнгән. Бу хәл узуга, аффект та юкка чыга. Ул бик көчле, тик озакка бармый. Аффект уңай да, тискәре дә була ала. Уңай аффект рухи якынлык, гаилә әгъзалары үзара кызыксынучанлык һәм кайгыртучанлык күрсәткәндәге мәхәббәт һәм аңлашу белән бәйле. Гаиләдә салкынлык, дошманлык һәм кире кагу хөкем сөргәндә, без тискәре аффект турында сөйлибез. Мондый гаиләләрдә бер-береңә тартылу, эмоциональ булышлык, кайгыртучанлык күрсәтү һәм аңлашу юк. Аффектлар, кагыйдә буларак, уйлап эш итүгә каршы килә.

Иң киң таралган эмоцияләрне «үз эчеңә бикләнү» һәм ялгызлык тойгысы тәшкил итә. Без еш кына хисләребезне яшерәбез, ялгызлыкка ныграк омтылабыз, һәм бу хисләрне актив белгертергә кирәк чакта була.

Әгәр сез паника, курку хисләре кичерәсез, янау яисә басым ясау тоясыз икән, бу вакытта хисләрне тышка чыгару зарур. Бастырылган хисләр һәм тирәнгә куалап кертелгән эмоцияләр сезнең физик һәм психик сәламәтлегегездә чагыла. Сәламәт һәм тулы энергияле булу өчен, уңай эмоцияләрне хупларга, тискәреләренә юл куймаска кирәк. Моңа ирешү өчен, үз хисләреңне белдерү шарт.

«Эмоция» һәм «хис» терминнары еш кына синонимнар буларак кулланылсалар да, аларны аера белергә кирәк. Эмоция — ул психик реакциянең иң түбән, ә хисләр — иң югары төре. Эмоциянең иң югары төрен юкка гына хисләр (интеллектуаль, нәфасәти, әхлакый) дип санамыйлар. Без курку кичерәбез, ә курку — ул эмоция, ягъни нерв системасын ярсыту. Курку бик примитив. Хисләр кичерешләр һәм кайгы-хәсрәтне уртаклашу белән бәйле. Сез бәлагә тарыган кешегә теләктәшлек күрсәтәсез. Монда сезнең әхлакый башлангычыгыз күренә. Хисләр — анык вакыйгаларга яисә кешеләргә (бәлкем, хыялдагыларга) мөнәсәбәт ул.

Алар характер үзенчәлегенә әверелергә мөмкин. Мәсәлән, көнче турында аерым бер төрдәге кеше итеп сөйлиләр. Дөрес, куркак та — кешеләрнең аерым бер төре. Ул бар нәрсәдән яки күпләрдән курка. Димәк, куркаклык та

Истә калдырырга киңәш итәбез

Аффект – кагыйдә буларак, көчле ярсыткычка җавап буларак барлыкка килгән кыска вакытлы көчле эмоциональ реакция (мәсәлән, нәфрәт, кот очу).
Эмоцияләр — әйләнә-тирә дөньяны психика тарафыннан чагылдыруның нигездә кичерешләрдә гәүдәләнгән аерым формасы.
Хисләр — әйләнә-тирә дөньяга, анык вакыйгаларга яисә кешеләргә (бәлкем, хыялдагыларга) мөнәсәбәт ул.

характер үзенчәлеге булырга мөмкин. Вакытлы халәт буларак куркуны бөтен кеше, хәтта иң кыюлар да тоя. Сугышта курку хисе солдатка тормышын саклап калырга ярдәм итә. Ләкин куркуны характер үзенчәлеге, даими хис итәргә, дөньяны аның аша кабул итәргә ярамый.

Даими курку хисе тою барлык кешеләрне дә куркакка әверелдерә алмый. Эзәрлекләү маниясе даими куркуга, синең арттан кемдер килә, сине кемдер үтерергә, агуларга, буарга тели дигән хискә нигезләнә. Психик авырулар гына түгел, хәтта кайбер бөек хөкемдарлар да маниягә бирелергә мөмкин. Сез ничек уйлыйсыз, ни өчен?

Хисләр ярдәмендә без әйләнә-тирәдәгеләргә үз кәефебез яки халәтебез турында хәбәр итеп кенә калмыйбыз, аларга йогынты ясарга да тырышабыз. Балалар әти-әниләренә тәэсир итәргә, нәрсәгәдер ышандырырга, аларның игътибарын җәлеп итәргә һәм җавап гамәлләренә өметләнеп елыйлар, елмаялар, зарланалар. Елмайганда, «рәхим итегез» яисә «рәхмәт» сүзләрен әйтеп, без әңгәмәдәшебезне йомшартырга, аның уңай мөнәсәбәтенә ирешергә, юмалап үзебезгә каратырга мөмкин.

Хисләр дөньясының төрлелеген *рухи байлык* дип атыйлар. Эмоцияләргә һәм кичерешләргә нигезләнгән ярдәмчеллек, кайгыртучанлык, теләктәшлек, чиста күңеллелек һәм бик күп башка сыйфатлар кешенең рухына карый.

Кызыклы фактлар

Моннан 1000 ел элек бөек гарәп галиме һәм табибы *Әбүгалисина* (Авиценна) куркуның нәрсәгә китерүен күрсәткән. Ул ике тәкәне бәйдә тоткан. Аларны бертөрле үк ашаткан. Әмма бер тәкә янында бүре дә бәйдә торган. Сыналучы хайван бик тиз ябыккан һәм үлеп тә киткән.

Яшүсмерләрдә стресс төрле сәбәпләр аркасында барлыкка килергә мөмкин: гаилә таркалу, мәктәптәге уңышсызлыклар, милициягә алып киту, наркотикларга һәм спиртлы эчемлекләргә бәйлелеккә төшү, дустың белән талашу яисә яңа тору урынына күчену. Күпчелек яшьләр йә үзләре бер яисә берничә проблемага тарыйлар, йә аларның шуларны кичерүгә дучар дуслары бар. Тормышта стресс тудыручы вакыйгаларның исемлеген китерик. Алар үсмерләргә йогынты ясау көче кими бару тәртибендә урнашкан: гаиләдә кеше үлү, ата-аналарның аерылышуы, мәктәп, милиция, эти-әни һәм дуслар, сәламәтлек белән бәйле проблемалар, наркотикка бәйле булу, эшне югалту, дусты яисә яраткан кешесе белән арасы өзелү, якыннарының авыруы, яраткан җәнлеген югалту...

Истә калдырырга киңәш итәбез

Кәеф кеше кичерешләренең гомуми торышын чагылдыра. Кәеф күтәренке яисә төшенке булырга мөмкин. Күңелсезлек, кайгы, курку, өметсезлек, шатлык, өмет, мавыгуны кәефкә кертәләр.

Стресс — организмның көтелмәгән һәм киеренке хәлгә җавабы. Бу организмның резерв мөмкинлекләрен мобилизацияләүдә чагылучы физиологик реакция. Ул теләсә нинди тискәре йогынтыга (суык, ару-талчыгу, авырту, түбәнсетү һ. б.) җавап буларак туа.

Өстәмә уку

О. Извекова

Стресс: кешелек исән калырмы?

Хәвефлелек факторлары арасында беренче урында тормыш темпының тизләнүе тора. Икенчедә — артык күп мәгълүмат алу. Эре шәһәрләрдәге ыгы-зыгы — бик куәтле стресс факторы. Аңа шәһәрдә яшәүчеләрнең аз хәрәкәтләнүен дә өстәргә кирәк. Хәзерге заман ризыклары тәмле, әмма натураль түгел. Мәктәптә дәресләрнең чамадан тыш күп булуы һәм компьютер янында озак утыру аркасында 80% балаларның нормаль физиологик функцияләре (йөрәк эшчәнлеге, сулыш алу һәм азык эшкәртү) бозылган.

Немец галиме *Э. фон Хольст* кызыклы эксперимент үткәргән: кечкенә тиеннәрне чикле пространствога урнаштырганнар. Башта барысы да тәртиптә була, җәнлекләр үрчиләр, үзләрен тыныч тоталар. Аннан соң, алар нык күбәйгәч, ягъни популяцияләре иң чик массага җиткәч, барлык җәнлекләрнең кинәт кенә койрыклары мамыкланган. Ана тиеннәрнең сөте беткән, алар үз балаларын, аннары ата тиеннәрне ашый башлаганнар. Аннан җәнлекләр аерым төркемнәргә берләшеп, үлгәнче сугыша башлыйлар. Нерв системасы функцияләренең масса-күләм бозылуы, кан басымының күтәрелүе, җенси функцияләрнең бозылуы күзәтелә. Шул рәвешле, популяция стрессны җиңәргә тырыша. Иң көчлеләр исән кала һәм алар өчен яңа этап башлана.

Компьютер янында озак утыру баланың сәламәтлегенә ничек тәэсир итә?

Үз эмоцияләреңне кайчан һәм ничек күрсәтү урынлы? Эмоцияләрне белгертү аралашуга ярдәм итәме?

Өстәмә уку

Эмоция һәм хисләр белән ничек идарә итәргә?

Кешенең барлык психик тормышы өч өлешкә: акыл, ихтыяр һәм хисләргә (эмоцияләргә) бүленә. Акыл һәм ихтыярны без контрольдә тота алабыз, ә теләк һәм хисләребезне — һәрвакыт түгел. Психологлар тарафыннан эшләнгән шактый гади, ләкин бик нәтиҗәле кагыйдәләр бар.

Сез үзегезне ничек бар, шулай кабул итәргә һәм яратырга тиеш!

- Дуслар һәм танышларыгыз күбрәк булсын;
- актив һәм күп аралашыгыз;
- үз эмоцияләрегезне белдерегез, ләкин оятка калырлык булмасын;
- үз хисләрегездән баш тартмагыз;
- хисләрегезне үзегез ышанган кеше белән уртаклашыгыз.

Көлү — стресс белән көрәшүнең менә дигән чарасы.

Моннан тыш, психологлар бернинди вазгыятьне, бернинди проблеманы күңелгә авыр алмаска тәкъдим итәләр. Еш кына алар башта уйлаганнан күпкә сай булып чыгалар.

Киеренкелекне бетерә белергә дә кирәк. Көлгәндә, тән җиңеләеп китә, баш мие ял ала, һәм сез проблемага башка яктан карарга сәләтле буласыз. Саф һавада йөреп керергә яисә яңа эш белән шөгыльләнергә була һәм бу игътибарны бүтән нәрсәгә юнәлтергә мөмкинлек бирә. Нәтиҗәдә сез ял итәсез һәм, яңа көч туплап, проблеманы чишә аласыз.

Йомгак ясыйбыз

Индивидуаль сәләт, интеллект, шулай ук шәхеснең хисләре һәм эмоцияләре психологик портретка өстәмә булып тора. Хискә бирелүчәнлек, эмоциональлек һәм үз шәхесенең әлеге сыйфатлары белән идарә итү мөмкинлеге кешенең характерына бәйле.

Белемегезне тикшерегез

1. «Сәләтләр», «интеллект», «хисләр», «эмоцияләр» төшенчәләренең мәгънәсен аңлатыгыз.

2. Кешедә хисләр төрлелеген ни өчен рухи байлык дип атыйлар?

3. Хәзерге яшүсмерләр еш кына стресска юлыгалар. Шуңа мисаллар китерегез. Стресстан ничек котылырга икәнлеген уйлап карагыз.

4. Сезнеңчә, кемне «кәефенә карап үзгәрә торган кеше» дип атыйлар? Ни өчен?

Практикум

1. Сез, мөгаен, сәләтсез кеше түгелсездер. Бәлки, сезгә бу хакта уйланырга туры килмәгәндер. Үзегезгә дикъкать белән карагыз һәм кайсы эшчәнлек өлкәләрендә иң зур уңышларга ирешүегезне, иң зур кызыксыну күрсәтүегезне билгеләгез. Сәләтләрегезне ничек үстереп була?

2. «Эмоция һәм хисләрне яшерә белергә кирәк»; «Үз хисләрегезне һәм эмоцияләрегезне күрсәтүдән курыкмагыз» дигән раслаулар бар.
Аларның кайсысы сезгә дөрес булып тоела? Ә бәлки, икесе белән дә килешерсез? Җавабыгызны дәлилләгез.

§ 7. Яшүсмернең үз-үзен бәяләве

Яшүсмер шәхесе үсешендә иң мөһим шартларның берсе булып аның үз-үзен бәяләве тора; үсмер үзе белән кызыксына башлый, аңарда үз шәхесенә хас сыйфатларны өйрәнү, үзен башкалар белән чагыштыру, үз-үзен бәяләү, үз хисләрен һәм кичерешләрен тәртипкә салу ихтыяҗы туа. Шул нигездә кайвакыт яшүсмернең дәгъвалары дәрәҗәсе һәм аның коллективтагы объектив урыны арасындагы каршылыклар аркасында конфликтлар да барлыкка килә.

Үз-үзенә бәя бирү ярдәмендә шәхеснең тәртибе җайга салына. Үз-үзеңә *артык югары бәя бирү*, үзеңне югарырак бәяләү әйләнә-тирәдәгеләр белән каршылыклар тудырырга мөмкин. Ул үпкәләүчәнлек, шикләнүчәнлек һәм хәтта агрессивлык сыйфатлары барлыкка китерә. Ә шәхеснең *үз-үзен түбән бәяләве*, киресенчә, үзеңә үзең ышанмау, шомлану хисләре формалаштырырга, инициативасызлыкка китерергә мөмкин. Яшүсмернең үсеше өчен үз-үзен бәяләве генә җитми. Аңа дуслары, укытучылары, әти-әнисе һ. б. биргән бәянең үзенә үзе биргән бәягә тәңгәл булуы кирәк. Шулай итеп, **үз-үзеңне бәяләү** — кешенең үз бәясен белүе, үз сыйфатларын, абруен һәм җитешсезлекләрен бәяләве ул.

Яшүсмернең үз-үзен бәяләвенә кемнәр һәм нәрсәләр йогынты ясый

Яшүсмернең үз-үзен бәяләве күп очракта әти-әнисенең аның дәрәҗәсен аңлавына бәйле. Әти-әнисе аны хуплый, аңа карата игътибарлы һәм ягымлы икән, яшүсмер үзенең алар өчен дә, үзе өчен дә әһәмиятле булуын аңлый. Үз-үзеңне бәяләү үз казанышларың һәм уңышларың һәм олыларның мактавы хисабына үсә.

Үз-үзләрен түбән бәяләгән яшүсмерләр оялчан һәм тиз кимсенүчән булалар. Үз-үзеңне түбән бәяләүнең аппетит югалуга, төшенкелеккә, сәламәтлек өчен зарарлы гадәтләр формалашуга китерүе ачыкланган. Яшүсмердән көлсәләр, нәрсәдә дә булса гаепләсәләр, башкаларда аның турында начар фикер калса, ул моны бик авыр кичерә. Ул, кимсенүчән булган саен, күбрәк шөбһәләнә. Нәтиҗәдә андый яшүсмерләр оялчан булалар, җәмгыятьтә уңайсызлык хисе кичерәләр һәм бөтен көчләре белән көлкегә калмаска тырышалар.

Алар мөмкин кадәр күзгә азрак чагылырга омтылалар. Бу үсмерләрне «күрмиләр» һәм лидерлыкка сайламыйлар, алар мәктәп һәм җәмәгать эшендә сирәк катнашалар, үзләрен яклый белмиләр һәм борчыган мәсьәләләр буенча үз фикерләрен әйтмиләр. Андый яшүсмерләрдә, гадәттә, еш кына ялгызлык хисе туа. Оялчан кешеләр җәмгыятьтә уңайсызлык һәм киеренкелек тоялар, бу әйләнә-тирәдәгеләр белән аралашуны кыенлаштыра.

Башкаларга ошарга теләгәнгә, бу яшүсмерләр белән идарә итү һәм йогынты ясау җиңелрәк, алар башкаларга үзләре өчен карар кабул итәргә мөмкинлек бирәләр.

Үз-үзеңне бәяләү һәм мәктәптәге өлгереш үзара тыгыз бәйләнгән. Үзен хөрмәт иткән һәм үз бәясен белгән кеше, кагыйдә буларак, яхшы яисә бик яхшы укый. Ә укуда алдынгы үз-үзен югары бәяли. Үзенә ышанган һәм үзен югары бәяләгән яшүсмернең башка кешеләр алдында әйбәт күренүгә, югары репутациясен саклауга стимуллары күп. Моннан тыш, алар үзләре турында нәрсә уйлауларын расларга җыеналар. Үз көчләренә ышанмаган яшүсмерләр еш кына укуда артта калалар. Аларга һәрвакыт бурычлар — бик авыр, ә таләпләр кирәгеннән артык югары булып

тоела. Мондый укучылар үз көчләренә ышанмыйлар гына түгел, үз сәләтләрен үстермиләр дә.

Яшүсмер чакның соңгы чорында кызларның үз-үзләрен бәяләвенә — дуслары, ә егетләргә этиләре бик зур йогынты ясый.

Кызыклы фактлар

Яшүсмерләрнең үз-үзләрен бәяләвенә укытучылар, ата-аналар һәм дусларының йогынтысын билгеләү максатында уздырылган тикшеренүләрнең берсендә яшьләре буенча өч төркемгә бүленгән 399 яшүсмер тикшерелә. Төркемнәргә уртача 13, 15 һәм 17 яшьлекләр кертелә. Барлык өч төркемдә дә кызларның үз-үзен бәяләве бер үк яшьтәге малайларныкыннан югарырак була. Моны кызларның малайлар белән чагыштырганда физик һәм социаль яктан иртәрәк өлгерүе белән аңлатырга мөмкин.

Башка бер тикшеренү кече яшьтәге үсмерләрнең үз-үзләрен өлкән яшьтәгеләргә караганда югарырак бәяләвен күрсәтте.

Яшүсмернең үз-үзен түбән бәяләве ата-ананың матди хәленнән генә тормый. Ярлы гаиләдә, әгәр әти-әнисе үзләрен югары бәяләсә, үз-үзен югары бәяләүче бала үсәргә мөмкин.

Һиндстан, Америка, Австралия һәм Ирландия яшүсмерләрен чагыштыру Америка яшьләренең үз-үзләрен башка илләрдәге яшүсмерләрдән югарырак бәяләвен күрсәтте; алардан соң (кимү тәртибендә) Австралия, Һиндстан һәм Ирландия яшүсмерләре бара.

Гаиләдә бердәнбер баланың үз-үзен югары бәяләү ихтималы энеләре һәм сеңелләре булган яшүсмерләрнекеннән зуррак. Моннан тыш, гаиләдә билгеле бер җенестәге беренче бала үз-үзен беркадәр югары бәяли. Мәсәлән, моңарчы бары тик кызлар гына булган гаиләдә туган беренче ир бала, тик малайлар гына булган гаиләдәге

беренче кыз бала кебек үк, гадәттә, үз-үзен югарырак бәяләргә тырыша.

Яшүсмер алдында торган проблемалар никадәр күбрәк булса, аларның үз-үзләрен бәяләве шулкадәр түбәнрәк була икән. 14 тән алып 16 яшькәчә булган 200 үсмерне тикшерү кызларның үз-үзләрен бәяләвенә дүрт проблеманың — сәламәтлек, физик үсеш, йорт һәм гаиләнең — тәэсир итүен күрсәтте.

Күңелле вакыйга, мәсәлән, җәйге лагерьда үткәргән көннәрне искә алу үз-үзеңә бәяне арттырырга мөмкин.

Шулай итеп, яшь чакта «мин» образы әле тулысынча формалашмаган була. Кеше үсә, җитлегә барган саен, аңа хас сыйфатлар да (уңайлары да, тискәреләре дә) тотрыклырак була бара. Яшүсмергә тискәре образдан уңай «мин»гә күчү җиңел түгел, ләкин бу — мөмкин эш. Яшь чакта образны үзгәртү, үз-үзеңә бәяне күтәрү олы яшьтәгегә караганда күпкә җиңелрәк.

Үз-үзеңне тәрбияләү

Шәхес формалашуда үз-үзеңне тәрбияләү бик зур роль уйный. Гомер буена тукталмаган бу эштә китап уку алыштыргысыз кыйммәткә ия. Яхшы китап герое белән танышыгыз — сезнең тирәгездә тагын бер гүзәл кеше пәйда булыр. Китаплар интеллектуаль, рухи, физик өлкәләрдә кешенең гаять зур мөмкинлекләргә ия булуы хакында сөйли. Үз мөмкинлекләрен аңлаган саен, кеше көчлерәк була бара, аңарда үз-үзен тәрбияләү ихтыяҗы туа.

Галим *М. И. Станкин* тарафыннан тәкъдим ителгән **үз-үзеңне тәрбияләү ысуллары** белән танышыйк. Аларның берсе *үз-үзеңә фәрман бирү* — бу үзеңә бирелгән кыска, төгәл күрсәтмәдән гыйбарәт, мәсәлән: «Тыныч кына сөйләшергә!» Үз-үзеңә фәрман бирү ысулын кеше үз җитешсезлекләрен ачык күргәндә, әмма үзен аларны җиңү өчен, аерым гамәлләр кылырга мәҗбүр итә алмаганда куллана. *Үз-үзеңне ышандыру* исә иң кыен хәлләрдә дә үзеңне кулда тотарга булыша. Уйда үз-үзеңне ышандыру гади һәм кыска «Мин үземә ышанам», «Мин бу материалны өйрәнәчәкмен» кебек катгый һәм, һичшиксез, уңай раслаулар-

дан гыйбарәт булырга тиеш. Күп кенә тормыш хәлләрендә *үз-үзеңне хуплау* алымын куллану максатка ярашлы. Мәсәлән, уңышсызлыкка тарыганда үзеңнең казанышларың турында искә төшерү файдалы, бу үз көчеңә ышаныч тудыра. Үз җитешсезлекләреңә башкача, *юмор белән* карау да файдалы. «Минем колакларым дөньяда иң матур,— дигән борынгы грек философы Сократ елмаеп.— Колакның бурычы — авазларны ишетү. Минем биниһая зур, тырпайган колак казаным моны бик нәтиҗәле башкара». Хәтта кечкенә генә уңышка ирешсәң дә, үзеңне мактау максатка ярашлы, күңелдән генә үзеңә: «Акыллы баш!», «Булдырдым!», «Шәп килеп чыкты», «Шулай дәвам итәргә!» дияргә кирәк. Ә эшең барып чыкмаса, үзеңне шелтәләү дә комачауламас: «Начар!», «Бик начар!». Мондый алым *үз-үзеңне стимуллаштыру* дип атала.

Үз тәнеңә йогынты ясауда үз мөмкинлекләреңә ышану, карашларыңны үзгәртү, ихтыярыңны ныгыту, үзеңне сәламәт һәм көчле итү бик мөһим. Ләкин мондый эш үзеңә таләпчәнлек эзлекле рәвештә арта барган очракта гына нәтиҗә бирә. Бөек рус язучысы Л. Н. Толстой, үз-үзенә таләпчәнлекне арттырып, 63 ел буе туктаусыз көндәлек язып барган.

Йомгак ясыйбыз

Үз-үзен бәяләүне формалаштыруда яшүсмернең үз тойгыларыннан тыш, аңа яшьтәшләре, укытучылар һәм әти-әнисенең мөнәсәбәте дә зур роль уйный. Объектив югары бәя яшүсмернең үсешен тизләтә.

Белемегезне тикшерегез

1. «Үз-үзеңне бәяләү» төшенчәсенең мәгънәсен аңлатыгыз.

2. Яшүсмернең үз-үзен югары һәм түбән бәяләвенә нәрсә этәргеч бирә?

3. Үз-үзен түбән бәяләгән яшүсмер тормышта нинди авырлыкларга юлыга? Әлеге авырлыклар белән ничек көрәшергә?

4. «Үзеңне ничек бар, шулай кабул итәргә кирәк» дигән гыйбарәне сез ничек аңлыйсыз?

Практикум

Яшүсмерләрне тәрбияләү өлкәсендә Америка белгече доктор *Дж. Добсон* үзенең педагогик тәҗрибәсе турында түбәндәгеләрне сөйли:
«Урта мәктәпнең өлкән сыйныфларында укыткан чакта миңа шундый сабак бирделәр. Берзаман мин укучылардан тәртип һәм дисциплинаны аларга хөрмәт белән караганда һәм абруйларын таныганда гына таләп итә алуымны ачык аңладым.
Мин үз укучыларымның дусларча мөнәсәбәтен мәктәптә дәресләр башланганчы да һәм дәрестән соң да, иртәнге ашны ашаганда яисә сыйныф бүлмәсендәге бәрелешләрдә дә яулау өчен бөтенесен эшләдем. Мин аеруча балалар миңа каршы килгәндә ныклык күрсәттем, ләкин ихтирамсызлык, теләктәшсезлек күрсәтмәдем, кемне дә булса нәни генә мәсхәрәләүгә дә юл куймадым. Мин балалар «кыйналучы малай» ролен биргән баланы якладым, һәр укучыга үз дәрәҗәсен тоярга, үзенә ышанычын табарга ярдәм иттем. Ләкин беркайчан да тәртип нормаларына карата компромисска бармадым. Укучылар сыйныфка кергәндә сөйләшмиләр иде. Алар сагыз чәйнәмәделәр, үзләрен бер-берсенә карата ихтирамсыз тотмадылар, әрләшмәделәр, бер-берсенең аркасына каләм белән төртмәделәр. Барысы да аңлый иде: мин корабны ныклы кулда тотучы капитан».
Яшүсмергә карата нинди мөнәсәбәтнең аңа үз-үзен хөрмәт итәргә булышуын аңлатыгыз.

8. Күренекле шәхес

Борынгы авторларның язмаларында ук инде без тарихны иҗат итүчеләрдән булган каһарманнарның — полководец, монархларның — тасвирламаларын очратабыз. Лидер-падишаһ образын беренчеләрдән булып Италия философы һәм язучысы *Н. Макиавелли* (1469—1527) тасвирлый һәм хөкемдарларга гамәли киңәшләр бирә. Җәмгыятьне туплау һәм тәртип саклау өчен, падишаһ теләсә нинди чаралардан файдалана, шул исәптән хәйләкәрлек һәм көч тә куллана ала дип саный ул. Француз тарихчысы *Т. Карнейль* (1795—1881), тарих — ул каһарман шәхесләр эшчәнлеге, ә кешеләрнең төп массасы зәгыйфь, лидерлар юнәлеш бирмәсә яши алмый, дип уйлый. Немец

Балалар һәм яшүсмерләрнең сәләтлелеге нинди формаларда чагылырга мөмкин? Сәләтлелекнең ачылуына нәрсә булыша, ә нәрсә комачаулый?

философы *Ф. Ницше* (1844—1900), бөек шәхесләр, кешелекнең иң югары вәкилләре буларак, гадәттән тыш кешеләр генә тарихны иҗат итә дип исбатлый. Гайре табигый кеше ул — лидерлыкка омтылган көчле, матур кеше. Хакимияткә омтылыш аның «иҗади инстинктын» чагылдыра. Мондый шәхес яхшылык һәм явызлыкның теге ягында тора. Һәм ул гадәти кешеләргә карата рәхимсез дә, шәфкатьле дә була ала, гамәлдәге әхлак нормаларын сакламаска да мөмкин, чөнки әхлак — йомшак кешеләр коралы.

Кайберәүләр, күренекле кеше булу өчен, һичшиксез даһи булырга кирәк дип ышаналар. Ләкин даһилык — тумыштан бирелгән сыйфат. Ул булырга да, булмаска да мөмкин. Даһилык табигатьтән яисә Алладан, диләр.

Ә күренекле шәхес ару-талусыз хезмәт итеп һәм сабырлык белән үзен үзе тәрбияләгән. Кайчакта табигатькә каршы килеп тә күренекле булалар. Кеше тумыштан кечкенә буйлы, кыяфәтсез булырга мөмкин, музыкага сәләте дә юк, җитмәсә, кәкре аяклы да, ди. Әмма философия яисә юриспруденциядә гаҗәеп уңышларга ирешкән.

Сәләтле балалар барлык илләрдә элек тә булган, хәзер дә очрый. Ләкин аларны һәркайда һәм үз вакытында танымыйлар гына. Бик сирәк кеше генә даһи дәрәҗәсенә ирешә. Акыл сәләте — биологик сыйфат. Ул үсәргә дә, сүнәргә дә мөмкин. Сәләт даһилыкка әверелсен өчен, ихтыяр көче, хезмәт сөю һәм моңа ирешү өчен кызыксыну кирәк, ә менә бу сыйфатлар кешеләрдә бер үк күләмдә үсмәгән, төгәлрәк әйткәндә тәрбияләнмәгән. Бу очракта гаилә тәрбиясе, мәктәптә алган белемнәр һәм җәмгыятьнең йогынтысы, башкача әйткәндә, социаль мохит зур роль уйный.

Кызыклы фактлар

Музыкага, сәнгатькә, математикага, шигъриятькә сәләтләрнең бик иртә ачылу фактлары киң мәгълүм. *Моцарт,* 3 яшь тулгач ук, белгечләрне үзенең музыкаль таланты белән шаккатыра. 8 яшендә инде ул үзенең беренче симфонияләрен иҗат итә. *Н. Римский-Корсаков* 2 яшендә үзенең гаҗәеп музыкаль хәтере белән таң калдыра. *С. Прокофьев* 8 яшендә композитор буларак чыгыш ясый. *Рафаэльнең* рәсем сәнгатенә таланты шул ук яшьтә ачыла. Ә *Микеланджелоныкы* — 13 яшьтә. *Фарадей* беренче электр лампасын 13 яшендә ясый, ә *Эдисон* уйлап табучылык белән 12 яшьтән шөгыльләнә. Кибернетикага нигез салган *Н. Винер* 14 яшендә гыйльми дәрәҗә ала, ә инглиз математигы *У. Гамильтон* 12 яшендә 12 тел белә.

Кайвакыт шулай да була: кече яшьтә сәләтле булулары ачыкланмаган кешеләр дә соңрак даһи булалар һәм кешелеккә бөек ачышлар бүләк итәләр. Әйтик, Эйнштейнны һәм Менделеевны мәктәп укытучылары сәләтсез дип саныйлар. П. Гогенның иҗади таланты —38 яшьтә, ә С. Т. Аксаковның язучылык сәләте 50 яшьтә ачыла. Гаҗәеп хезмәт

сөючәнлекләре аркасында алар иҗади үрләр яулыйлар. Һәм шушы юлда шәхес буларак формалашалар. Америка уйлап табучысы Томас Эдисон, даһи ул — 99% тирдән һәм 1% илһамнан тора, ди. Ләкин бу сүзләрне даһига түгел, ә бөек кешегә карата әйтү дөресрәк булыр иде. Талант һәм даһилык — биологик, тумыштан килгән акыл сәләте. Ләкин **бөек шәхес** — ул башка нәрсә. Күренекле шәхес — тәрбия һәм үз өстеңдә эшләү, авырлыкларны җиңү һәм тормыш тәҗрибәсе нәтиҗәләре ул. Бала чагында вундеркинд дип саналганнарның да байтагы үскәч өметләрне акламый. Алар иҗади сәләтле шәхесләр булалар, ләкин күренекле кешегә әверелә алмыйлар.

Кеше сәләтләре һәм казанышлары баскычында бала әти-әнисеннән бер баскыч югарырак була ала һәм шулай булырга тиеш тә. Кешелекнең прогрессы, мөгаен, балаларның ата-аналарыннан алгарак китүендәдер дә. Бала әти-әнисе теләге буенча гына яисә күз ачып йомганчы, эволюциянең берничә баскычын сикереп үтеп, бөек була алмый.



Психологлар фикере...

Француз психологлары билгеләп үткәнчә, сәләтле балаларның билгеле бер категориясе өчен типик булган критерийлар бар. Аларның натурасында үрнәк тәртип һәм тыңлаучанлык түгел, ә нәкъ менә ата-аналары һәм укытучылары сөймәгән нәрсәләр: бу балалар шартлылыкны танымыйлар, тәртип һәм дисциплинаны бар дип тә белмиләр, лидер булырга маташалар, бар нәрсәгә үзләренчә, янәшәдәгеләргә скептикларча юмор белән карыйлар. Белгечләр мондый балалар өчен аларның сәләтләрен үстерүгә һәм характер каршылыкларын тиешенчә тәрбияләүгә булышлык итүче индивидуаль программалар эшлиләр.



Кызыклы фактлар

Инглиз психологы *М. Хоу* үзенең «Теплица балалары турында хакыйкать һәм уйдырма» дигән китабында өч йөз ел элек булган хәлне мисалга китерә. XVIII гасыр башында Венециядә балалар приюты була, танылган композитор Антонио Вивальди анда музыка укыта. Табигый ки, язмыш кушуы буенча приютка эләккән балалар атаклы һәм сәләтле нәселдән булулары белән мактана алмыйлар, димәк, аларның тумыштан музыка сөюләре дә бик шикле. Шуңа да карамастан, шул заманда яшәүчеләр бәяләве буенча, приютта гаҗәеп югары дәрәҗәле концертлар куела. Анда тәрбияләнүчеләрнең чама белән өчтән бере соңрак җырчы һәм музыкант буларак таныла. Бу балаларның сәләтләрен үстерү өчен кирәкле уңай шартларның (тумыштан нинди булуларына карамастан) гаҗәеп нәтиҗәләргә китерә алуы турында сөйли.

Хәзерге заман тикшеренүләре күрсәткәнчә, мәгълүм шартлар тудырылганда кече яшьтәге мәктәп балалары математика һәм рус теле буенча абстракт теоретик материалны уңышлы үзләштерә ала. Укытучыга баланың теоретик фикер йөртү башлангычларын үстерә барырга һәм, анык образлы фикер йөртү белән берлектә, акрынлап иң гади абстракт уйлау алымнары тәрбияләргә кирәк.

Галимнәр һәрвакытта да сәләтләрне кирәгеннән артык үстерергә кирәк дип санамыйлар. Күпчелек яшьтәшләреннән сизелерлек аерылып торган бала, алар белән аралашканда, җитди проблемалар белән очрашырга мөмкин, ә бу исә кирәкмәгән психологик үзенчәлекләр формалашуга китерә.

Дүрт яшьлек сабыйны, әлбәттә, укырга өйрәтергә мөмкин. Ләкин бу яшьтә аңа укый белү кирәкме соң? Бәлки, аның әти-әнисе танышлары алдында нәни вундеркинд белән мактанырга гына телидер? Әмма сабыйның үзенә, объектив законнар аркасында, яшьтәшләре, бигрәк тә әти-әнисе белән эмоциональ аралашу күпкә мөһимрәк. Ул

энциклопедия ятлап утырмаячак һәм Достоевскийны да укымаячак, чөнки аларны аңламаячак. Күренекле сәясәтче У. Черчилль дүрт яшенә кадәр, гомумән, сөйләшмәгән дә, диләр.

Әгәр, игътибарны бер генә нәрсәгә юнәлтеп, әйтик, музыкага яисә чит телләргә, үзеңнән күренекле музыкант ясарга ниятләп, башка сәләтләр турында онытсаң, математикадан «ике»ләләргә яки физкультура дәресләрен калдыруга тыныч карасаң, нәтиҗәдә бер яклы гына үсеш алган шәхес килеп чыга.

Инглиз психологы *М. Хоу* фикеренчә, теләсә кайсы бала, әгәр аңа уңай шартлар тудырсаң, бик югары нәтиҗәләргә ирешә ала. Шул ук вакытта шунысын истә тотарга кирәк: баланың мөмкинлекләре бик зур, әмма чиксез түгел, кече яшьтә уку-өйрәтү шөгыльләренең артык күп булуы психологик яктан тискәре үзгәрешләргә китерергә мөмкин.

Кызыклы фактлар

Галимнәр сәясәттә һәм иҗтимагый тормышта кешелек дөньясы биргән барлык даһилар турындагы мәгълүматларны гомумиләштерәләр һәм аларның географик яктан тигез бүленмәвен ачыклыйлар. Африка өч даһи биргән, Латин Америкасы — берне генә, Азия — 18 не, АКШ — 7 не. Калган 71 даһи Европада туган. Шуларның өчесе — Россиядән.

Кеше күренекле булып тумый, ә тәрбияләнә. Үзенең рухи табигате буенча ул, барыннан да элек, җиңүче булырга тиеш. Ул кыенлыклар һәм уңайсызлыклар кичерә, иң кризислы хәлләрдән дә чыга, оптимизмын һәм үзенә ышанычын югалтмый. Үз-үзенә ышаныч, тыныч холык һәм рухи бөтенлек — менә ул җиңүчегә хас сыйфатлар. Аннан бөркелгән шәхес энергиясе кайчакта бөтенесен бастыра.

Үз-үзеңә максат кую сәләтен, аларга ирешү юлларын билгели белүне, көндәлек вак-төяк эшләр аркасында төп нәрсәне югалтмауны җиңүче рухына ия күренекле кешенең башка билгеләре дип санарга була. Мондый кешеләр кирәкмәгән эшләргә, файдасыз максатларга вакыт сарыф итмиләр. Моннан тыш, алар нинди генә хәлләрдә дә бик тиз һәм төгәл ориентлаша алалар.

Дөньяга карашыгызны киңәйтегез, кешеләр белән аралашыгыз, бәлки, алар проблемаларны хәл итүнең башка юлларын тәкъдим итәрләр. Көннән-көн әйләнә-тирәдәгеләрнең сезгә карата кызыксынулары арта барсын. Мәсәлән, әгәр сезгә язып иҗат итү ошаса, үз уй-фикерләрегезне яшереп ятмагыз, стена газетасына языгыз, нинди дә булса газетаның «Укучыларыбыз хатлары» рубрикасына хат юллагыз. Австрия язучысы М. Эбнер-Эшенбах әйткәнчә: «Бөеклек үзең омтылган уңышларга башкалар ирешүне көнләшмичә күзәтә белүдән гыйбарәт».

Аерылып торуның тагын бер ысулы — күренекле булу һәм башкаларны узып китү. Соры, күңелсез кешеләр заманы үтте. Илебезгә талантлар кирәк. Талантлы булыгыз!

Йомгак ясыйбыз

Күренекле шәхес булу өчен, талант, ихтыяр көче булу, хезмәт ярату һәм теләк кирәк. Күренекле шәхес тәрбияләүдә гаилә, мәгариф һәм җәмгыятьнең йогынтысы зур роль уйный.

Белемегезне тикшерегез

1. Күренекле кеше булу ни дигән сүз?

2. Россия дөньяга бик күп талантлы һәм даһи кешеләр бирде. Аларның берсе турында кыскача мәгълүмат әзерләгез.

3. Сез ничек уйлыйсыз, күренекле кешеләргә яшәү җиңелме?

4. Уйлагыз, үз сәләтләреңне үстерү һәм күренекле кеше булу өчен, нинди шәхси сыйфатларга ия булу кирәк?

Практикум

Сез көчле шәхесме?

Сез җирдә үз эзегезне калдырачаксызмы яисә сезнең гомерегез билгесезлектә үтәрме? Түбәндәге сорауларга ачыктан-ачык җавап бирегез, һәм сез тормыштан нәрсә көтәргә мөмкин булуын белерсез. «а» яки «б» вариантларын сайлап алыгыз һәм җавапны ахырдан карарсыз.

1. а) Сез стандарт булмаган карарларга әзер.
б) Сезнең карашларыгыз мәңге үзгәрмәячәк.

2. а) Теләсә нинди бәхәстә сез үз позициягезне ачык һәм эзлекле бәян итәсез.
б) Сез бутала башлыйсыз һәм фикерләрегезне авырлык белән генә җиткерәсез.

3. а) Сез «юк» дигән сүзне җавапка саныйсыз.
б) Сез аңлатулар таләп итәсез.

4. а) Әйтик, сез чиратта торасыз һәм ниндидер оятсыз бәндә сезнең алга керә. Сез, нәрсәдер мыгырданып, аның белән бәйләнешмисез.
б) Сез ул җир битне чиратка басарга мәҗбүр итәсез.

5. а) Сез башкаларга үзегез өчен карар кабул итәргә юл куясыз.
б) Сез үз акылыгыз белән яшисез.

6. а) Сез карар кабул итәсез һәм үзегезнең хаклы икәнлегегезне беләсез. Ләкин сезне шуның киресенә дә ышандырып була.
б) Ни генә булса да сез үз дигәнегездә торасыз.

7. а) Тирә-юньдәгеләр сезне бернинди яңа нәрсәгә өйрәтә алмый дип санныйсыз.
б) Кайчакта сабый бала да хакыйкатьне әйтеп бирә ала дип санныйсыз.

8. а) Сез карьерага ирешергә тырышачаксыз.
б) Сез хәзерге заманда зур нәрсәгә ирешү мөмкин түгел дип санныйсыз.

9. а) Әйтик, күпьеллык көрәштән соң сез иң югарыга мендегез, ди, ә иртәгәсен бөтен нәрсә җимерелеп төшә. Сез бөтенесен яңадан башлыйсыз.
б) Сез булган хәл белән килешәсез.

10. а) Әгәр сезгә кемдер мирас итеп зур күләмдә акча калдырса, сез шунда ук эшегезне ташлыйсыз һәм шул акчага яшисез.
б) Бу акча бик яхшы нигез дип санныйсыз һәм үз планнарыгызны кирәгенчә үзгәртәсез.

Һәр дөрес җавап өчен 5 әр бал санагыз.

Дөрес җаваплар:
1а; 2а; 3б; 4б; 5б; 6б; 7б; 8а; 9а; 10б.

Иң зур сумма — 50.

Әгәр сез 40—50 балл җыйсагыз, сезне, чыннан да, уңыш көтә.

25—35 балл сезнең тәвәккәл дә, ихтыярлы да булуыгызны күрсәтә, сезнең гамәлләрегез көчле характерлы кеше булуыгыз хакында сөйли.

20 балл һәм аннан да азрак булса, үзегезне кулга алырга вакыт, юкса сезне уңышсызлык көтә. Шулай да ул сезгә аралашу өчен күңелле кеше булырга комачауламый.

9. Лидер һәм аның сыйфатлары

Үз төркемендә иң зур абруйга ия булган һәм танылган, башкаларны да үз артыннан ияртергә сәләтле кешене **лидер** дип саныйлар. Лидерны билгеләп куймыйлар, шәхси сыйфатлары аркасында ул үзе күтәрелә.

Беренче тикшеренүләрдә үк тарихта «бөек кешеләрне» массалардан аерып торган сыйфатларны ачыкларга тырышканнар. Тикшеренүчеләр лидерлар гаять тотрыклы, вакытлар узу белән үзгәрмәгән уникаль, аларны лидер була алмаган кешеләрдән аерып торган сыйфатларга ия дип ышанганнар.

XX гасыр башында Америка социологы *Э. Богардус* лидерда булырга тиешле дистәләрчә сыйфатны санап үтә. Алар түбәндәгеләр: юмор хисе, такт, алдан күрә белү, үзенә игътибар җәлеп итү сәләте, кешеләргә ошый белү, җаваплылыкны үзенә алуга әзерлек һ. б. Ул кешене акыл, энергия, характер кебек сыйфатлар лидер ясый дип саный.

Аның ватандашы *Р. Стогдилл* 1948 елда, күп санлы тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен гомумиләштереп, лидерлыкның 124 сыйфатын атый. Ул лидерның үз янәшәсендәгеләрдән күбрәк интеллектка ия булырга тиешлеген исбат итәргә омтыла. Ләкин аңа каршы төшәләр: бизнеста, янәсе, башкалардан акыллы булу уңышның мәҗбүри факторы түгел. Башка сыйфатлар, мәсәлән, максатка омтылучанлыкның да роле зур.

Мәдәниятләр һәм тарихи чорлар гына түгел, социаль сыйныфлар, катлаулар, төркемнәр, бергәлекләр дә төрле сыйфатларга ия лидерларның булуын таләп итәләр. Бериш сыйфатлар — футбол командасы капитаны, икенчеләре — фәнни коллектив җитәкчесе, өченчесе — партия лидеры өчен зарур.

Психологлар фикере...

Мәктәп балаларына белемнәрнең төрле өлкәләрендәге материалларны кабул итүдә, истә калдыруда, гомумиләштерүдә аермачык индивидуаль үзенчәлекләр хас. Берәүләр математик формуланы тизрәк үзләштерәләр, төгәлрәк гомумиләштерәләр һәм яхшырак истә калдыралар, икенчеләре — текст, өченчеләре күргәзмә материал белән эш иткәндә үзләрен ышанычлырак хис итәләр һ. б.

Урта яшьтәге үсмерләрнең мәгънәви мантыйк хәтере, төшенчәләр белән фикер йөртү тиз үсә. Яшүсмер акыл экспериментларына, нинди дә булса фаразлау нигезендә мәсьәләне хәтердән чишүгә сәләтле була.

Физик сыйфатлар да җитди әһәмияткә ия. Моңа кешенең буе, авырлыгы, тән төзелеше яисә фигурасы, тышкы кыяфәте, энергияле хәрәкәте һәм сәламәтлеге керә. Ләкин төркемдәге уртача гәүдәле кешедән физик яктан эрерәк һәм озынрак булу гына әле аңа лидерлыкка дәгъва итү хокукы бирми. Тарихтан күренгәнчә, кечкенә буйлы кешеләр дә биниһая зур дәрәҗәләргә ирешкәннәр, ягъни мәсәлән, Наполеон кебек дөнья тарихына йогынты ясарлык фигураларга әверелгәннәр.

Лидерга кирәкле сыйфатлар исемлеге һаман киңәя барган, ләкин бу феноменга дөрес аңлатма әле дә табылмаган. Кайберәүләр һаман да лидерлык тумыштан килә яисә ул бөтенләй булмый, дип уйлый.

Бу ялган теория, лидер булу сәнгатенә өйрәнергә була. Осталык серләрен һәр буын яңадан ача, әмма алар бик гади. Аларны өйрәнеп, без Цезарь яки Наполеон була алмабыз, ләкин нәтиҗәле эш итәргә өйрәнербез, күп очракта шунысы да җиткән. Инглиз язучысы *С. Норткот Паркинсон фикеренчә, лидерлыкның төп алты элементы* бар, аларны булдырырга яисә уку һәм гамәл итү белән үзеңдә үстерергә мөмкин.

Беренче элемент — **күзаллау**. Әгәр дә ни дә булса төзергә, күчерергә яисә оештырырга кирәк булса, кеше нәтиҗәдә нәрсә килеп чыгачагын ачык күз алдына китерергә тиеш. Моның өчен әле дөньяда юк әйберне күзаллау сәләте булу зарур. Бу күзаллау, хыялдагы картина кайчандыр без күргән, ләкин үзгәртелгән һәм яңача яраклаштырылган реаль әйберләрдән гыйбарәт.

Икенче элемент — **белем**. Ул күзаллау ясаган максатка ирешү юлын планлаштыру өчен кирәк. Белем лидерга ышаныч бирә.

Өченче элемент — **талант**. Талант һәм сәләтне төгәл аерып карый белергә кирәк. Сәләтле кеше башкалар авырсынган нәрсәне чагыштырмача җиңел башкара. Бу виолончельдә уйнау, атта йөрү яисә футбол булырга мөмкин. Ләкин башкаларның да эшен оештырып (оркестр белән дирижерлык итүме, сугышта гаскәрләр яисә уен кырында футбол командасы белән идарә итүме), сәләттән өстен күтәрелү өчен талант кирәк. Талантлы кеше хәлне һәрчак үзе контрольдә тота.

Дүртенче элемент — **катгыйлык**. Бу уңышка ирешү теләге генә түгел инде. Ул өч компоненттан тора. Беренчедән, лидер куелган бурычның кеше мөмкинлекләре белән чикләнгән булуын белә. Икенчедән, ул нәрсә эшләнергә тиеш, барысы да эшләнәчәк дип ышана. Өченчедән, ул үз инануын башкаларга да җиткерергә тиеш. Мондый тыныч ышаныч команданың башка әгъзаларына да көч бирә.

Бишенче сыйфат — **аяусызлык**. Мөгаен, бүген күпләр моны кабул итәргә әзер түгелдер, ләкин тәҗрибә, дошманнарыңа, эшлексезләргә һәм ялкауларга карата аяусыз булсаң гына, уңышка ирешергә мөмкин булуын күрсәтә. Шундый лидерлар бар, аларны яраталар да, хөрмәт тә итәләр, ләкин бу әле аларның һичкайчан аяусыз булмавын күрсәтми.

Һәм, ниһаять, алтынчы элемент — **җәлеп итү**. Лидер магнит, үзәк фигура булырга, башкалар аңа тартылырга тиеш. Сез күз алдында булган саен, үзегезгә җәлеп итү көче күбрәк. Әлбәттә, эре компаниядә даими күз алдында булу кыен, ләкин анда лидер турында һаман сөйләп торалар. Ул легенда, чынбарлыктагы һәм уйлап чыгарылган хәлләр каһарманы булырга тиеш. Ул үзенә дан һәм игътибар эзләп, ялагайлар җыеп ятмый, лидерның дан-шөһрәте болай да бар инде. Аңа үзенең әһәмиятен һаман күрсәтеп тору да кирәкми. Ул күз алдында.

Әгәр кеше 30 яшенә җитеп, үзен беркайчан да лидер ролендә сынамаса, үз вакыты җиткәч, булдыра алмаска да мөмкин. Барысы да нормаль барганда ул идеаль оештыручы булырга мөмкин. Ләкин кинәт, аның теләгеннән бәйсез рәвештә, эшне үз кулына алырга кирәк булган вазгыять килеп туа. Шул чакта нишләргә? Өйрәнә башларга инде соң булачак.

Әле санап үтелгән сыйфатлардан тыш, лидерга тагын кимендә ике төрле осталыкка ия булырга кирәк. Бу — бик үтемле итеп сөйли белү һәм башкалар сөйләгәнне тыңлый белү. **Аралашу сәнгате** һәрвакыт лидерның аерылгысыз сыйфаты булды. Элек-электән лидер булырга омтылган кеше хәрби батырлыктан ким булмаган күләмдә ораторлык сәнгатенә ия булырга тиеш булган. Ләкин ул аның берсеннән — тыныч вакытта, икенчесеннән сугышта файдаланган.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Лидер (*ингл.* leader — әйдәп баручы, җитәкче) — төркемнең иң абруйлы әгъзасы.

Кызыклы фактлар

• Америка антропологы *К. Клакхон* кеше сәләтенең 93 % ы ачылмый калуын, нибары 7 % ы гына тормышта гамәлгә ашуын басым ясап күрсәтә.

• Россия галиме *В. П. Эфроимсон* тикшеренүләре күрсәткәнчә, мәсәлән, биш миллион кеше яшәгән кечкенә ил, үзенең 10 % потенциаль даһиларының үсешенә һәм үз-үзләрен реализацияләвенә ирешсә, ярты гасыр эчендә йөз тапкыр күбрәк халкы булган, ләкин интеллектуаль потенциалын үстерүне тоткарлаган илне артта калдыра. Бу тәҗрибә белән раслана. Әле күптән түгел генә начар үсеш алган дип саналган Көньяк Корея, Сингапур, Тайвань фәндә, бигрәк тә техникада нинди уңышларга ирештеләр!

• Россиядән һәм СССРдан эмиграциягә киткән һәм эмигрантлар гаиләсендә туган 20 дән артык кеше Нобель премиясе алды.

Ораторлар үз-үзләрен тотышлары, сөйләм стиле белән аерылып торалар. Шул ук вакытта интонация, артистлык, акцентларны дөрес кую еш кына тыңлаучыларга сүзләрнең мәгънәсенә караганда да күбрәк тәэсир итә. Үз фикерен әйтер алдыннан озак һәм образлы сөйли алучылар аеруча хөрмәт ителә. Яхшы оратор тактны тоя, әңгәмәдәшенең характерыннан оста файдалана, халыклар тарихын әйбәт белә. «Зур кешеләр» җыелыш ахырында, күпчелекнең фикерен чагылдырырга кирәк булгач, чыгыш ясыйлар.

Халык алдында чыгыш ясау сәнгате, аралашу осталыгы бүген дә югары бәяләнә. Күп кенә халык депутатлары да сүзгә осталыклары аркасында сайлана.

Кешеләр белән аралаша белү — һәркем акрынлап үзләштерә алырлык күнекмә ул. Яхшы тойгы калдыру өчен, сез аңлаешлы язарга һәм дөрес итеп сөйләргә тиеш.

Берәү дә язу осталыгына ия булып тумый. Сезгә берәр нәрсә язарга кирәк булса, аны ни өчен язуыгызны аңлаткан сүз яки җөмләдән башлагыз. Аннары үзегезне аны укыячак кеше урынына куеп карагыз. Аңа сезнең



Ораторны характерлаучы сыйфатлар исемлеген төзегез. Ораторлык күнекмәләре тормышта булышамы?

эшне уку нигә кирәк? Җавап бер — ниндидер мәгълүмат алу өчен. Димәк, сезнең эшегездә башкаларда булмаган һәм аларны гаҗәпләндерергә, алар белән уртаклашырга мөмкин булган яңалыклар, ягъни мәгълүматлар булырга тиеш.

Нинди дә булса фән буенча доклад яисә реферат язганда, аның әдәбият буенча инша түгеллеген исегездән чыгармагыз, монда гадилек һәм ачыклык кирәк.

Тагын бер кагыйдә. Укытучыны дәреслектән алынган акыллы сүзләр һәм әйтемнәр белән шаккатырырга тырышмагыз. Аларның сезнеке булмавын ул барыбер аңлаячак. Әгәр сездән мәгълүмат җыю һәм аны әлеге язманы укыячак кеше предмет турында башлангыч белем алырлык итеп кенә бәян итү таләп ителсә, алдан төзелгән план буенча эш итү яхшы.

Аралашу мәгълүмат бирүне күздә тоткан берьяклы процесс түгел. Аралашканда, без дә мәгълүмат алабыз, ә бу процесс бездән тыңлый белүне таләп итә.

Тыңлау ул ишетү генә түгел. Без, нигездә, ишетергә теләгән нәрсәне генә «ишетәбез». Тыңлаганда, без әңгәмәдәшебезнең сүзләрен, интонациясен һәм кул хәрәкәтләренең мәгънәсен үзебез аша уздырабыз. Моңа без әңгәмәдәшебезне игътибар белән тыңлавыбызны аңлаткан үз реакциябезне дә өстәргә тиеш. Бу реакциягә йөз-кыяфәт, елмаю, баш селкү һ. б. керә.

Мәгълүмат алганда, сөйләүчегә тулы игътибар юнәлтергә, ә сезгә нәрсә хәбәр итәргә җыенулары турында уйланып утырмаска кирәк. Мөмкинлек булса, кыйммәтле мәгълүматны язып алырга тырышыгыз. Бу бигрәк тә телефон буенча мәгълүмат алганда мөһим, шалтыраткан урында барган вакыйга сезгә таныш түгел бит. Шуңа күрә сезне буташтырырга мөмкин.

Тыңлаганда:

- бөтен игътибарыгызны шуңа юнәлтегез;
- әңгәмәдәшегезнең сезгә нәрсә хәбәр итәргә җыенуы турында ашыгыч фараз ясамагыз;
- башка кешене тыңлаганда, җавапны формалаштырырга маташып, вакытны югалтмагыз;
- күзенә карап, сез аны, чыннан да, игътибар белән тыңлавыгызны күрсәтегез;
- әңгәмәдәшегезне телефоннан тыңлаганда, бүлмәдә барган хәлләрнең сезнең игътибарны җәлеп итүенә юл куймагыз;
- телефоннан сөйләшкәндә, вакыт-вакыт «Алай икән...», «Әйе...», «Яхшы...» һ. б. дип, шалтыратучыны игътибар белән тыңлавыгызны аңлатыгыз;

кирәк булганда язгалап барыгыз.

Тыңлау осталыгына һичшиксез өйрәнергә мөмкин. Ул куелган сорауларга дөрес җаваплардан, әңгәмәдәшегез өчен актуаль темаларга кереп китә белү сәләтеннән гыйбарәт. Сөйләүчедә сез аның белән бик нык кызыксынасыз, сез бик игътибарлы һәм әңгәмәне дәвам итәргә телисез дигән фикер калсын.

Сорауларга реакция тыныч һәм кыска, ягъни ул чыгыш ясаучы яисә сөйләүченең фикер агышына комачауламаслык булсын. Әгәр реакция чын күңелдән үк булмаса, ул манипуляцияле, ялган һәм нәтиҗәсез булырга мөмкин. Әйтелгәннең мәгънәсенә реакцияне пауза ясаган мизгелдә белгертү яхшырак.

Йомгак ясыйбыз

Лидерның характерында байтак үзенчәлекле сыйфатлар булырга, ул билгеле бер максатка омтылырга, кызыксындыра, кешеләрне оештыра белергә тиеш. Лидерлыкка төрле юнәлешләрдә ирешергә була. Лидерлык өчен белем һәм осталык кирәк.

Белемегезне тикшерегез

1. «Лидер» төшенчәсенең мәгънәсен ничек аңлыйсыз?

2. Уйлап карагыз, ни өчен кайбер кешеләр лидер булырга омтыла?

3. Лидерлык өчен көрәштә бөтен ысулларны да кулланырга ярыймы? Ни өчен?

4. «Көчле характерлы кеше генә лидер була ала» дигән фикер белән килешәсезме?

5. «Лидер» һәм «җаваплылык» дигән төшенчәләр үзара бәйлеме?

Практикум

1. Шәхеснең сыйныф яисә мәктәп лидерына кирәк булган сыйфатлары исемлеген төзегез.

2. Үзегезгә билгеле лидерлар турында зур булмаган хәбәр языгыз. Алар ничек лидер булганнар?

3. Уйлап карагыз, Россия тарихында лидерлар нинди роль уйнаган? Берничә анык мисал китерегез.

4. Генерал М. Скобелевның параграф башындагы сурәтен карагыз. Аның лидерлыгын нинди билгеләр буенча билгеләп була? Энциклопедиядән генералның язмышы турында укыгыз.

II бүлек

Яшүсмер социаль даирәдә

10. Яшүсмернең социаль даирәсе

Нәрсә ул социаль даирә?

Кеше гомере буе җәмгыятьтә (социумда) башка кешеләр арасында, ягъни социаль чолганышта, **социаль даирәдә** яши. Социаль даирә шәхесне үстерү, аның мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен шартлар тудыра. Социаль даирә аша кеше башка кешеләр белән мөнәсәбәткә керә.

Яшүсмер тирәсендә аңа турыдан-туры һәм читләтеп, якын һәм ерак мөнәсәбәттә булган кешеләр яши. Гаилә әгъзаларын, туганнарны, дусларны, күршеләрне, башкача әйткәндә, кем белән бик еш аралашасың, шуларны якын

мөнәсәбәттә торучыларга кертәләр. Алар барысы да *иң якын даирәне* тәшкил итә. Ул күп кенә кече төркемнәрдән тора: гаилә, ишегалды дуслары, классташлар.

Мәктәп нindидер аралыктагы урынны били: ул ике — якын һәм ерак даирәләр арасында тора. Укытучы, бигрәк тә сыйныф җитәкчесе, якын кеше булырга мөмкин. Ләкин мәктәп, учреждение буларак, гаиләдән ераграк тора. Яшүсмернең аңына радио, газета һәм телевидение көчле йогынты ясый. Ләкин алар таныш булмаган кешеләр дөньясына керә. Таныш түгел кешеләр дөньясы *ерак даирәне* тәшкил итә.

Аралашу даирәсе яшүсмердән ераграк торган саен, аңа ышану дәрәҗәсе дә кимрәк. Дөньяның күп кенә илләрендә уздырылган халыкара тикшеренүләр барышында яшүсмерләрнең Интернет мәгълүматларына бик аз ышанулары ачыкланды (массакүләм мәгълүмат чараларына — бераз гына артык). Гаиләдә ышаныч дәрәҗәсе иң югары. Яшүсмерләрнең 50 % тан күбрәге ата-анасыннан алган мәгълүматны иң дөрес дип саный.

Гаиләнең йогынтысы йомшара барган саен, кино каһарманнары, популяр музыкант һәм дуслар үрнәгенең роле үсә бара. Сөйләмдә, чәч йөртү һәм кием-салым сайлауда, музыкаль зәвыкта һәм төп социаль кыйммәтләрдә бу аеруча көчле чагылыш таба.

Яшүсмергә ничек йогынты ясыйлар

Бериш кешеләр яшүсмергә *турыдан-туры йогынты* ясаса, икенчеләре *читләтеп* тәэсир итәләр, ләкин шулай да ул гаять үтемле була. Әйтик, әти-әнисенең эше аларда зур тәэсир калдыра, ә соңгысы үз чиратында яшүсмернең үсешенә йогынты ясый. Мәсәлән, эш хакының күләме, эш һәм ял графигы, коллективның составы, эштән китү һ. б. Болар барысы да әти-әнинең яшүсмер белән үзара мөнәсәбәтендә чагылыш таба.

Җәмәгать оешмалары да үсмергә күпьяклы йогынты ясый. Мәктәп администрациясе дәресләр тәртибен, уку графигын төзи, укытучыларны эшкә ала. Шәһәр хакимияте яшьләр үзәген яисә йөзү бассейнын ачарга яки ябарга мөмкин.

Психологларның күпчелеге безнең үз-үзебезне тотышыбызга башка кешеләр, бигрәк тә таныш-белеш яисә туганнарның реакциясе никадәр зур булуына игътибар юнәлтә. Алар бериш гамәлләрне хуплый һәм безгә рәхәт була. Кайчакта алар безне рухландырып җибәрә, үзең белән горурланырга җирлек бирә. Икенче төрле гамәлләребезгә исә гаепләп карыйлар, һәм безгә үзебез өчен уңайсыз, оят булып китә.

Кайбер эш-гамәлләребездә без, чыннан да, гаепле. Кырын карашны без гадел рәвештә үзебезнең адреска гаепләү буларак кабул итәбез. Мин нинди саран, булдыксыз яки ялкау. Үзем өчен оят миңа.

Шул ук вакытта безнең өчен күңелсез, әмма аңлап эшләнмәгән гамәлләр дә бар.

Ләкин уйлап эшләнгәнне дә, аңышмыйча башкарганны да без үз хисабыбызга язабыз. Хәтта күңел түрендә моны эшләргә ярамаганлыгын аңласак та.

Без ни өчен үзебезнең җитез булмавыбыз өчен (мәсәлән, кышкы тайгак юлда таеп егылганда) кызарып чыгабыз? Бәлки, башкалар көләр һәм гаеп итәрләр диптер? Без янәшәдәгеләрнең реакциясенә, ул хәтта кычкырып әйтелмәсә дә, хисләнеп җавап бирәбез. Берәү дә ачыктан-ачык көлмәде, бернинди сүз булмады. Әмма барыбер күңелгә ошамый.

Димәк, без үзебез ишетмәгән һәм күрмәгән, ләкин күз алдына китергән нәрсәгә дә җавап бирә алабыз. Мәсьәләнең

чишелеше шунда. Безнең күңел калганын үзе ясап бетерә. Без эчтән генә алар миннән көләргә мөмкин, дип уйлыйбыз.

Нигә әле без, аларның реакциясен күрми дә, ишетми дә торып, кешеләр турында шулай начар уйлыйбыз? Мөгаен, үзебезне алар урынына куеп карагач, шундый хәл булганда мин көлеп җибәргән яисә нәрсәдер әйткән булыр идем дип саныйбыздыр. Бигрәк тә бу кешене бик яратып бетермәсәк. Димәк, башкаларда без үзебезне күрәбез. Үзебезнең акрын кыймылдавыбыз өчен без үзебездән оялабыз.

Шулай итеп, безнең һәркайсыбыз үз-үзен тоту линиясен янәшәдәге кешеләрнең реакциясеннән чыгып билгели. Моны *турыдан-туры бәйлелек* дип атыйк. Ә тагын *турыдан-туры булмаганы да* бар. Ул нидән гыйбарәт соң?

Бу — кеше күзәтә торган гамәлләрнең уңай һәм тискәре нәтиҗәләре. Яшүсмер кемнәрдер үзләрен агрессив тотканны һәм шуның өчен уңай бәя алганны күзәтеп торса, аның үзенең тәртибе агрессивлана бару мөмкинлеге арта. Өлкән сыйныф укучысы кече сыйныфтагы балага сукты, ди. Һәм менә аның янына завуч килә һәм, тагын шулай эшләсә, өлкән сыйныф укучысының тәртибе буенча «канәгатьләнмәслек» билгесе алачагы турында кисәтә. Кисәтү үтемле булды. Өлкән сыйныф укучысы уңайсызлана, ә моны күзәтеп торучылар шундый гамәл өчен бик авыр хәлдә калырга мөмкин булуын аңлый. Мондый хәлләрне булдырмау хәерлерәк. Башка кешеләр мисалында сабак алырга кирәк. Янәшәдәгеләр минем гамәлне түгел, ә бөтенләй башка кешене гаепләделәр, ә мин сабак алдым. Үзең хата ясаганчы башкалар хатасында өйрәнү яхшырак.

40 еллар элек, әле үзем яшүсмер чакта, һәркайда өлкәннәрнең ризасызлык чагылган карашына юлыга идем. Яшьләр урам буйлап йөриме, җырлыймы, тавышлана яисә тәрткәләшәме, үтеп йөрүчеләрдән ишетеп торасың: яшьләр бигрәк хәтәр хәзер, алардан киләчәктә ни көтәргә була?! Яшьтәшләрем олыгая барган саен, алардан да шуны ишетәм: алар бүгенге яшьләрдән канәгать түгел. Бәлки, әтиләр һәм балалар конфликты — безнең заманның үзенчәлегедер?

Юк, яшьләрне бөтен тарихи чорларда да сүккәннәр. Безнең заманнарга килеп ирешкән тарихи истәлекләрдә үк

без яшьләргә үгет-нәсыйхәт бирелгән өзекләр табабыз, анда яшьләрдән зарлану гына түгел, ачыктан-ачык ризасызлык та бар: янәсе, яшьләр элеккеге кебек түгел инде хәзер. Һәм бу фикерләр 4—5 мең еллар элек әйтелгән.

Борынгы Мисыр манускриптларына күз салыйк: гаҗәпкә калырсыз, 5 мең ел элек тә картлар яшьләрдән риза булмаганнар икән.

Борынгы грекларның иң зирәге — философ *Сократ* (б. э. к. 470—399 еллар) — яшьләр турында болай дип яза: «Алар (яшүсмерләр) бүген байлыкка бик хирыс, манералары начар һәм абруйлы затларга бернинди ихтирам юк, өлкәннәргә хөрмәт белән карамыйлар, эшсез йөриләр, башкаларның гайбәтен чәйниләр. Алар һәрвакыт әти-әниләре белән бәхәсләшә, сүзгә кушыла һәм үзләренә игътибар җәлеп итәләр, алар күп ашый һәм укытучыларын газаплыйлар...»

Безнең эраның VIII гасырында яшәгән борынгы бөек шагыйрь *Геосид* та яшьләрдән риза булмаган: «Мин җиңел акыллы яшьләргә нык бәйле халкыбызның киләчәгенә бик ышанып карамыйм, чөнки безнең барлык яшьләр чиктән тыш акылсыз... Мин малай чагында өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәттеләр, ә бүгенге яшьләр үзләрен иң акыллы дип уйлыйлар һәм бернинди чикләүләргә дә түзмиләр».

Тагын 3 мең ел уза, һәм ул заман әдәбияты да элеккечә үк тыңлаусыз, җилбәзәк яшьләр турында зарланулар белән тулы. 1863 елда *У. Бертон*: «Танырга кирәк ки, безнең яшьләрдә ихтирамсыз, буйсынмас, күңел кайтаргыч рәхимсезлек тулы рух өстенлек итә...» — дип яза.

Йомгак ясыйбыз

Яшүсмер даими рәвештә кешеләр һәм мәгълүмат кыры (Интернет, матбугат, телевидение һ. б.) чолганышында яши. Болар барысы аңа йогынты ясый. Мөнәсәбәтләр якын булган саен, аның тәэсир итү дәрәҗәсе дә арта бара.

Белемегезне тикшерегез

1. «Яшүсмерләрнең социаль даирәсе», «әйләнә-тирәдәгеләрнең турыдан-туры йогынтысы», «читләтеп йогынты ясау» төшенчәләренең мәгънәсен аңлатыгыз.

2. Яшүсмергә якын һәм ерак даирәләрнең йогынтысына мисаллар китерегез.

3. Кешегә аның ихтыярыннан башка тәэсир итеп буламы?

4. Уйлап карагыз, «Дустыңның кем булуын әйт, мин синең кем булуыңны әйтеп бирәм» дигән мәкаль параграф темасына туры киләме?

Практикум

Тормышыгызда тирә-юньдәге кешеләрнең турыдан-туры һәм турыдан-туры булмаган реакциясе белән очрашканыгыз бардыр. Шундый мисаллар китерегез. Кайсы ысул сезгә көчлерәк йогынты ясады? Ни өчен?

11. Яшүсмер төркемдә

Җәмгыятьне нинди төркемнәр тәшкил итә?

Җәмгыять — төрле — *зур* һәм *кече*, *даими* һәм *вакытлы*, *һөнәри* һәм *дини*, *милли* һәм *сәяси* **социаль төркемнәр** җыелмасы. Алар бер-берсеннән нык аерылалар. Кайберләре аңа кергән кешеләр саны буенча бик кечкенә. Алар шулкадәр кечкенә ки, хәтта бер төркем әгъзалары көн дәвамында бер-берсен якыннан күрә, бер-берсенең гамәлләрен күзәтә алалар. Мондый төркемнәрдә бәйләнешләр еш һәм тыгыз. Болар — кече яисә шәхси бәйләнеш төркемнәре. Гаилә — шундый төркемнең аермачык мисалы.

Төркем — кешелек җәмгыятенең нигезе, чөнки җәмгыять — төркемнәрнең берсе, әмма иң зурысы. Җир шарында төркемнәр саны кеше санынннан күбрәк. Чөнки бер кеше берничә төркемдә: гаиләдә, сыйныфта, дуслар даирәсендә, музыка мәктәбендә, спорт түгәрәгендә булырга мөмкин. Билгеле бер төркемгә эләгү өчен, без зур көч куябыз. Мәктәп тәмамлаучылар, мәсәлән, ничек тә булса

институтка, университетка керергә һәм студент булырга тырышалар. Башка төркемнәрне, мәсәлән, музыка мәктәбен яисә рәсем сәнгате түгәрәген һәм башкаларны безгә әти-әниләребез сайлый. Без үзебез сайламаган, язмыш тарафыннан билгеләнгән төркемнәр дә бар. Гаилә — әнә шундыйлардан, чөнки аның составын билгеләүдә без өлешчә генә катнашабыз. Дусларны без үз теләгебез буенча сайлый һәм ташлый алабыз. Төркемдә без, башкалар белән бергәләп, үз шәхесебезне һәм тормыш кыйммәтләрен формалаштырабыз. Биредә без таныш булмаган кешеләр белән беркайчан бүлешә алмаган иң якын, иң нечкә хисләребезне уртаклашабыз.

Кеше төркем кануннары буенча яши. Галимнәр кешеләрнең күп кенә үзенчәлекләре — абстракт фикер йөртү сәләте, сөйләме, теле, үздисциплинасы һәм әхлагы —төркемдәге эшчәнлек нәтиҗәсе булып торуын исбатладылар. Төркемдә нормалар, кагыйдәләр, гореф-гадәтләр, ритуаллар, тантаналар туа. Кеше төркемгә мохтаҗ һәм аңа бәйле. Кешеләр бергәләшеп кенә яши алалар.

Һәм бүген дә кеше үзен төркемнән башка күз алдына китерә алмый. Ул — гаилә, сыйныф, яшьләр компаниясе, хезмәт коллективы әгъзасы һ. б.

Төркем кануннары

Көче социаль төркем — вазифалары һәм рольләре төгәл бүленгән, уртак хәрәкәтләр яхшы уйланылган һәм килештерелгән, әйбәт оештырылган команда ул. Әйтик, самолет яисә космик корабль экипажының эше бик нык җайга салынган булырга тиеш. Командага темперамент, характер, инанулары буенча охшаш кешеләрне махсус сайлыйлар. Мондый төркем, гамәлләре үзара килештерелмәгән кешеләр төркеменнән кечерәк булса да, күбрәк эш башкарырга сәләтле. Спортта яхшы тупланган команда һәрвакыт начар тупланганны җиңә. Бу очракта сүз уенчыларның килешеп уйнаулары турында гына түгел, команданың аерым бер рухы —җиңүгә омтылыш, бер-береңне авыр хәлдә калдырмау турында да бара.

Команда рухы — төркемдәге аерым бер атмосфера ул. Озын җәйге каникуллардан соң классташларыгыз белән

очрашуны шатланып көтәсез икән, белегез — сезнең «командада» атмосфера яхшы.

Үзенең тупланганлыгы аркасында төркем аерым кешегә шундый тәртип кагыйдәләре, гамәлләр һәм таләпләр куя ки, ул алар белән килешмәсә дә, аларга буйсынырга мәҗбүр. Бу күренеш фәндә *төркем басымы* дип атала. Ата-аналар яшүсмерләрдән, урам йогынтысыннан зарланалар икән, алар, чыннан да, йогынтысы әти-әниләрнекеннән көчлерәк булган үсмерләр төркеме турында сөйлиләр. Һәм киресенчә: әгәр гаилә тупланган һәм анда сәламәт атмосфера хөкем сөрә икән, аңа бернинди урам йогынтысы да куркыныч түгел. Төркем басымына җавап рәвешендә кешедә, мөгаен, сезгә яхшы таныш аерым бер тәртип формасы, төгәлрәге — *төркемгә буйсыну*, күпчелек фикере белән килешү, аңа каршы килмәү барлыкка килә. Мондый күренешнең дә фәндә үз атамасы бар — **конформизм.**

Кызыклы фактлар

Япониянең икътисадтагы зур казанышларын галимнәр аерым бер «япон рухы» белән аңлаталар. Ул коллективлыктан, төркем фикерен аерым кешеләрнең эгоистлык теләкләреннән югары куюдан гыйбарәт. Бу — шулай ук команда яисә җәмгыять рухы да. Япон фирмалары психологик яктан туры килә торган коллективлар төзиләр. Бер-берсенә карата ягымлы һәм дустанә мөнәсәбәттәге кешеләр даирәсендә эш калдыру, соңга калу, начар эшләү бик уңайсыз. Төркем кешеләрне яклый. Ул кешене эшкә сәләтсезлеге өчен азат итәргә мөмкинлек бирми. Шуңа күрә япон кешесе, иптәшләрен авыр хәлгә куйганчы, үләргә дә әзер. Фирма яисә предприятие монда ныклы гаилә булып санала, аның белән элемтәләрне гомерең ахырына кадәр өзәргә мөмкин түгел. Нәкъ шуңа япон сәнәгатендә, гаиләдәге кебек үк, бөтен гомере буена эш урынын алыштырмыйча эшкә гомерлеккә яллану гамәле яшәп килә.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Конформизм — башка кеше яисә кешеләр төркеменең басымы астында үзеңнең тәртибеңне яки фикереңне үзгәртү ул.

Психологлар төркемнең безнең фикеребезгә һәм хәрәкәтләребезгә хәлиткеч йогынты ясавын исбатлаучы экспериментлар үткәрәләр.

1 нче мисал

Өйрәнелүче төркем белән экспериментта сыналучылар, сәгатькә карамыйча секундларны эчтән генә санап, бер минутның озынлыгын билгелиләр. Сыналучы һәр кеше аерым кабинада утыра һәм, үз эченнән төгәл бер минутны санаганнан соң, махсус төймәгә баса. Моннан тыш, барлык кабиналарда лампалар була. Эксперимент үткәрүче алар аша, янәсе, бер яисә берничә сыналучы биргән сигналларны тапшыра (кайчакта алар 35 секундтан соң ук бирелә), ә аннан соң, үз төймәсенә басарга ашыгып, алданучыларны билгели. Төркем басымына һәм йогынтысына бирелгән кешеләр бик күп булып чыга.

2 нче мисал

Психологлар күмәк теләктәшлек дәрәҗәсен ачыклаган эксперимент уздыралар. 7 нче сыйныф укучыларын тирга чакыралар һәм ике мишеньнең берсенә атарга тәкъдим итәләр. Алдан кисәтеп куялар: әгәр укучы беренче мишеньгә атса, барабаннан килеп чыккан акча уртак эшкә китә, ә икенчесенә атса, үз кесәсенә керә. Эксперимент үткәрүчеләр сыналучыларга ялган мәгълүмат бирүче хәйлә уйлап табалар. Мишеньнең һәркайсында алдагы укучылар күпме тидергәнне күрсәтүче якты нокталар пәйда була. Һәрвакыт икенче мишеньдә нокталар күбрәк күренә. Укучыларны гүя кисәтәләр: менә карагыз, барысы да үз файдасына тырыша. Яңа кергән һәр укучы сайларга тиеш була: үзен коллектив әгъзасы итеп күрсәтергә һәм

күпчелекнең фикере белән килешмәскәме яки эгоист булып калырга һәм күпчелек белән килешергәме? Дус, тупланган сыйныфта сыналучыларның 80 %ы беренче мишеньгә аткан.

Шундый экспериментлар ярдәмендә галимнәр кешенең «мөһим роль уйнаучы башкалар»га ориентлашуын исбатладылар. «Мөһим роль уйнаучы башкалар»ның кем булуын чамалагансыздыр инде. Алар — фикерләре яисә тәртипләре мөһим булган кешеләр.

Әлбәттә, безнең үз-үзебезне тотышыбызда күп нәрсә төркем басымына дучар булган кеше шәхесенә бәйле. Үз-үзенә түбән бәя биргән кешеләр, үзен югары бәяләүчеләргә караганда, иҗтимагый фикер басымына тизрәк биреләләр. Төркемдә кабул ителгән нормалардан анда үзен ышанычлы һәм комфортлы тойган кешеләр күпкә җиңелрәк тайпылалар икән.

Без карашлары буенча үзебезгә якын торган, кире кагылмаслык абруйлы, хакимиятне гәүдәләндергән яисә закон вәкиле булган кешеләр фикере белән тизрәк килешәбез. Галимнәр кешеләрнең штатский киемендәге кеше күрсәтмәсенә караганда, форма кигән кеше тарафыннан әйтелгән таләпне (эш гап-гади күрсәтмәгә генә кайтып калса да) үтәргә күбрәк әзер торуларын билгеләделәр.

Нинди билгеләр буенча фотографиядә сурәтләнгән кешеләрнең бер социаль төркемгә керүен әйтеп була?

Йомгак ясыйбыз

Яшүсмер, олы кеше кебек үк, объектив сәбәпләр аркасында даими рәвештә нинди дә булса төркем (җәмгыять) әгъзасы булып тора. Яшь кеше өчен бу — гаилә, мәктәп, түгәрәкләр, секцияләр һ. б. Төркемдәге үзара мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә яшүсмер үзен анда тулы яки өлешчә комфортлы итеп сизә.

Белемегезне тикшерегез

1. «Кече социаль төркем», «конформизм» төшенчәләренең мәгънәсен аңлатыгыз.
2. Яшүсмер өчен алар кергән төркем нинди әһәмияткә ия? Җавабыгызны мисаллар белән раслагыз.
3. Төркемдә яшүсмер өчен нинди проблемалар килеп туарга мөмкин? Әлеге проблемаларны хәл итү ысулларын тәкъдим итегез.
4. «Яшүсмер кергән төркем аңа үз-үзенә ышаныч бирә» дигән фикер белән килешәсезме? Җавабыгызны нигезләгез.
5. Яшүсмерләр төркеме аның һәр әгъзасының тәртибенә йогынты ясыймы?

Практикум

1. Түбәндә китерелгән фикерләрнең кайсы дөресрәк булып күренә: «Төркем яшүсмер шәхесен һәм аның сәләтләрен бастыра», «Яшүсмер бары тик төркемдә генә үз сәләтләрен һәм талантларын ача ала»?
2. Сез кайсы төркемнәргә керәсез? Әлеге төркемнәрдә югары бәяләнгән шәхес сыйфатларын атагыз.
3. Уйлап карагыз, нинди очракларда яшүсмер төркем фикеренә (мәсәлән, классташлары фикеренә) каршы тора ала?

§ 12. Шәхесара мөнәсәбәтләр

Шәхесара мөнәсәбәтләр

Кече төркем бер-берсен бик яхшы белгән кешеләрдән тора. Югыйсә аны тупланган дип булмас иде. Үзара даими аралашып, бергәләп нәрсәдер эшләп, кешеләр шәхси һәм гаилә проблемалары турында сөйләшәләр, соңгы яңалыкларны, белем алу мәсьәләләрен, эшкә урнашу һ. б. проблемаларны кызып-кызып тикшерәләр. Үзләре өчен бик мөһим мәсьәләләрне тикшерү аларны якынайта, алар арасында ышанычлы мөнәсәбәтләр булдыра.

Кешеләр арасындагы шундый төр мөнәсәбәтләрне галим-психологлар **шәхесара мөнәсәбәтләр** дип атыйлар. Аларны әле тагын психологик мөнәсәбәтләр дип тә йөртәләр, чөнки кешеләр арасындагы бәйләнешләрдә хис һәм эмоцияләр бар. Без танышларыбызга яисә туганнарыбызга

Истә калдырырга киңәш итәбез

Шәхесара мөнәсәбәтләр — ул кече төркемдә яхшы таныш кешеләр арасында аларның даими аралашуы барышында туган мөнәсәбәтләр.

теләктәшлек күрсәтәбез, шатлыклы вакыйга булганда бергә шатланабыз, кайгы килгәндә — уртаклашабыз.

Мондый мөнәсәбәтләрдә, психологик сыйфатлардан тыш, әхлакый нормалар да катнаша. Без дусларыбызны тугры һәм ышанычлы булганнары өчен югары бәялибез, алар белән мөнәсәбәтләрдә намуслы булырга тырышабыз. Күчү яше — барысы да кешенең көчле һәм иҗтимагый танылуга лаек шәхес икәнен күрсеннәр өчен, тирә-юньдәгеләр алдында үзен үзе күрсәтергә омтылу чоры ул.

Шәхесара мөнәсәбәтләр ниндидер абстракт көчләр арасында түгел, ике яисә күбрәк шәхес арасында барлыкка килә. Катгый мәгънәдә әйткәндә шәхесара мөнәсәбәтләр урамдагы төркемдә һәм, гомумән, очраклы рәвештә җыелган кешеләр арасында була алмый. Андый халәттә кешеләр, кагыйдә буларак, якыннан танышмыйлар һәм үзләрен шәхес буларак ачмыйлар.

Галимнәр бик кызыклы закончалыкны ачтылар: күпчелек очракта башкаларның мөнәсәбәте сезнең үз-үзегезгә карашыгыз белән билгеләнә. Моны аңларга һәм истә калдырырга тырышыгыз. Бу — шәхесара мөнәсәбәтләрнең иң мөһим кануны. Әгәр дә сез һаман үз-үзегездән канәгать түгел икән, сезнең кәефегез һәм ризасызлыгыгыз башкаларга да күчәргә мөмкин. Алар да сездән канәгать булмаячак. Әгәр дә үз-үзегезне түбән бәяләсәгез, янәшәдәгеләр дә сезне түбән бәяләячәк.

Ләкин кирәгеннән артык югары бәяләү дә хәерлегә түгел. Бу бит элементар мин-минлек тә булырга мөмкин. Теләсә нинди бер чиктән икенчесенә ташлану кебек үк үз-үзеңне бәяләп бетермәү һәм артык бәяләү дә әйбәт түгел.

Әйләнә-тирәдәгеләр дә, яшьтәшләр дә үз-үзен дөрес бәяләгән кешеләрне яхшырак кабул итәләр.

Шәхесара мөнәсәбәтләрдә үзара аңлашу

Үз-үзеңне кабул итү, сезнең башкаларны ничек кабул итүегез һәм башкаларның сезне ничек кабул итүе арасында мәгълүм бер бәйләнеш бар. Әгәр сез үзегезне күккә чөйсәгез, ә башкаларны түбәнсетсәгез, сезнең арада дуслык барлыкка килерме? Ә киресенчә булса? Бу сезнең һәрвакыт башкаларга бәйле булуыгызга китерә. Димәк, үз-үзеңне кабул итү һәм башкаларны кабул итү — шәхесара мөнәсәбәтләрнең нигезе. Дуслаша яисә яңа кешеләр белән таныша белмәү яшь чакта әйләнә-тирәдәгеләр белән мөнәсәбәтләр бозылуның бер билгесе булып тора.

Кеше үзен үзенә ошаган кешеләр арасында яхшырак хис иткәнгә, аларның яхшы тупланган төркемнәргә берләшүе табигый. Кече төркемнең нигезе булып **үзара аңлашу** тора. Төркемнән киткән кешеләрдән «Алар мине аңламый» дигән фразаны бик еш ишетергә туры килә. Яшьтәшләре үзен аңламаганга күрә, укучы башка сыйныфка күчерүләрен сорый. Үзара аңлашу тапмаганда, без ялгыз калабыз. Ә кешене куркыткан иң зур нәрсә —ялгызлык.

Кешеләр бергә озаграк яшәгән һәм эшләгән саен, аларның татулыклары ныгый баруы ачыкланган. Гадәттә, иң зур үзара аңлашу һәм кайгыртуны без бөтен тормышыбызны үткәргән гаиләдә, мәктәп сыйныфында яисә хезмәт коллективында табабыз. Кешелек, коллектив кыйммәтләрне санга сукмаган өчен, каты җәза да уйлап тапкан. Ватанны сатучыларны йә куалап җибәргәннәр, йә җәзалап үтергәннәр. Үз балаларын, ата-анасын, картларны, дусларын хөрмәт итмәгәннәрне, фронттагы туганлыкны, яраткан сыйныфын хәтерләмәгән кешеләрне нык гаеплиләр. Диннән язганнарны, сектантларны һәм еретикларны да кызганып тормыйлар. Сәяси партияләрдә уртак инануларга, гомуми программага сатлыкларча карап шулай ук нык гаепләнә.

Һәркайсыбызның, гаилә әгъзаларын, дусларын коткарганда, үз тормышларын куркыныч астына куйган кешеләр турында ишеткәнебез бар. Алар янган бинага бәреп

керәләр, куып килгән автомашина юлына каршы чыгалар...

Психологлар кешеләрнең нинди шартларда ярдәмгә килүен ачыкларга булалар. Башка кешегә кичекмәстән ярдәм кирәк булуын күргән һәр кеше үзенә мондый сораулар бирә:

• Хәл, чыннан да, минем ярдәмне таләп итәрлек җитдиме?

• Эш минем шәхси катышуымны таләп итәме?

• Ярдәм итү минем өчен авыр булырмы?

• Ул зур чыгымнар таләп итәрме?

• Минем катнашуым файда китерерме?

• Мин вакыйгага булган урыннан җиңел генә китеп бара аламмы?

Бу хәлләргә безнең реакция шушы сорауларның һәркайсына җавап табуга бәйле.

Ярдәм итүнең беренче шарты — хәлнең, чыннан да, гадәттән тыш булуына ышану. Әйтик, кеше эскәмиягә утырды, ди, ә сез аның хәлен белмисез: йөрәге авыртамы яисә ул ял итәргә генә уйлыймы? Бу очракта сезнең ярдәмгә килү теләгегез нык кими. Әгәр егылган кеше ярдәм сорап кычкырса, сез аңа шунда ук булышырга ашыгасыз.

Икенче шарт — мәҗбүри шәхси җаваплылык. Әгәр сез яралы кеше янына җыелган төркемдә торсагыз, янәшәдәгеләрнең саны арта барган саен, сезнең аңа ярдәм итү теләгегез кими. Тирә-юньдә кеше күбрәк булган саен, башкалар да ярдәм итә ала бит дигән фикер сезгә тизрәк килә. Әгәр сез үзегез генә булсагыз, җаваплылыкны башкаларга күчермәс идегез. Зыян күрүчегә ярдәм итүне үзегезнең шәхси җаваплылык дип карар идегез. Ләкин төркемдә бу хис башкаларга да бүленә. Үзегезнең гаять зур җаваплылыгыгызны сез янәшәдәге кешеләр санына бүләсез, һәм сезгә кечкенә генә бер кисәк кала. Аны хәтта күрмәскә дә мөмкин. Кешеләр, гадәттән тыш хәл турында үзләре генә белә дип ышанганда, ярдәмгә теләбрәк киләләр.

Өченче шарт — катышуның бәясен аңлау. Мондый катышуның бәясе югары булганда, кешеләр барыбер азрак ярдәм итә. Бер экспериментта ир кеше урамда кинәт кенә тротуарга егыла һәм сиздермичә генә авызындагы кызыл

буяулы капсуланы вата. Аның авызыннан кан аккан кебек күренә. Үтеп йөрүчеләр хәлнең җитди булуын һәм ярдәмгә ашыгырга кирәклеген аңласалар да, канга баткан «корбан» янына бик сирәк кеше килә. Әгәр мондый хәлдә бернинди кан күренмәсә, күбрәк кеше килгән булыр иде. Ни өчен? Каннан куркалармы? Яисә мондый кыяфәт аларны читкә этәрәме?

Дүртенче шарт — ярдәм күрсәткәндә кешеләр үзләре китерергә мөмкин булган файданы исәпкә алалар. Кешеләр, чыннан да, файда китерүләренә ышансалар, бер-берсенә һичшиксез ярдәм итәчәкләренә дәлилләр җитәрлек. Мисал өчен, экспериментларның берсендә түбәндәгеләр исбат ителә: кеше бик каты авырту тоя, ә ярдәмгә килүче аның газапларын киметә ала. Авырту көчлерәк булган саен, шаһит тизрәк хәрәкәт итә. Ә ярдәмгә килүче үзенең катнашуы авыру газапларын киметергә мөмкин булуга ышанмаган очракта, зыян күрүченең авыртуы арта барганда да, шаһитның реакциясе акрыная гына.

Башка кешенең газаплануын күзәткәндә, кешеләр күңелсез тойгылар кичерәләр. Чит кешенең авыртуы көчлерәк булган саен, безнең тойгыларыбыз да күңелсезрәк. Аны ике юл белән киметергә мөмкин: йә кичекмәстән ярдәм күрсәтергә, йә бу хәлдән качарга. Әгәр ярдәм итә алуыбыз ачык булса, без бик тиз, бигрәк тә авырту көчле чагында тиз хәрәкәт итәбез. Берни дә эшли алмаячагыбызны аңлаганда, киресенчә килеп чыга: зыян күрүче көчлерәк сызланган саен, без вакыйгадан ныграк читләшәбез.

Йомгак ясыйбыз

Категорияләрдән бәйсез рәвештә үзара аңлашу, дуслык мөнәсәбәтләре нигезендә кече төркемнәр барлыкка килә, алар тугрылык, хөрмәт, намуслылык төшенчәләренә таяна һәм эмоциональ төсмер ала.

Белемегезне тикшерегез

1. Шәхесара мөнәсәбәтләр нәрсә ул? Алар аз таныш кешеләр белән мөнәсәбәтләрдән нәрсәсе белән аерыла?

2. «Үзеңә ничек карауларын теләсәң, башкаларга да шулай ук кара» дигән фикерне ничек аңлыйсыз? Мондый мөнәсәбәтләр гаделме?

3. Шәхесара мөнәсәбәтләрдә үз-үзеңне кабул итү, башка кешеләрнең ихтыярын кабул итү һәм башка кешеләр тарафыннан сезне кабул итү арасында нинди бәйләнеш бар?

4. Сезнеңчә, бер-берсенә охшамаган кешеләрнең дус булулары һәм аңлашулары мөмкинме?

5. Бер философ болай дигән: «Битараф кешеләрдән күбрәк куркырга кирәк». Сез бу фикерне ничек аңлыйсыз һәм аның белән килешәсезме?

6. Безнең илдә коткару хезмәте (МЧС) бар. Бу хезмәт кешеләре өчен булышлык күрсәтү — һөнәр. Ничек уйлыйсыз, коткаручылар нинди проблемаларга һәм кыенлыкларга юлыга?

Практикум

1. Шәхесара мөнәсәбәтләрнең үзенчәлекләрен ачып бирүче хәлләр уйлап табыгыз.

2. Кемгәдер сезнең ярдәм кирәк булган хәл турында сөйләгез. Сез нишләр идегез һәм ни өчен шулай?

3. Башка кешеләр белән (якын, бик аз таныш) аралашу сездә нинди тәэсир калдыра? Җавабыгызны аңлатыгыз.

4. Ничек саныйсыз, Җир шарында башка кешеләрдән бөтенләй аерым яшәгән кешене табып буламы?

§ 13. «Без» һәм «алар»

«Без» һәм «алар»

«Мин», «без», «алар» — бу төшенчәләр ярдәмендә кешенең әйләнә-тирә мохите, анық нинди төркемгә керүе тасвирлана. **«Мин»** — бу үзе турында беренче затта фикер йөртүче һәр кеше. «Мин үзем» сүз тезмәсе беренче зат тарафыннан башкарылган эш-гамәлне, сөйләүченең авторлык позициясен чагылдыра.

«Без» — үземнекеләр, минем кебек үк дип санаган кешеләрнең гомуми атамасы. Бу төшенчә белән төркемнең аерым төре тамгалана.

«Алар» — бу «башка» кеше өчен күплек сандагы атама, ягъни башкалар күп булганда, алар «алар»га әйләнә. «Алар» мин үземне тәңгәлләштерергә теләмәгән, берләшергә һәм тупланырга уйламаган ят кешеләрне гәүдәләндерә. Бу бары тик узгынчылар, чит кешеләр генә. Урамдагы, кибеттәге, вокзалдагы төркем — бу «алар»ның массакүләм чагылышы.

«Мин», «без», «алар» төшенчәләренең яшьләре төрле. «Алар» төшенчәсе иң борынгы, ул борынгы ыруглык строенда ук барлыкка килә. «Без» төшенчәсе күпкә соңрак пәйда була. «Мин» төшенчәсе килеп чыкканчы тарихи үлчәмнәр буенча бик күп вакытлар уза.

«Без» һәм «алар» — бу кешеләрнең ике аерым төркеме, мәсәлән, төрле милләт кешеләре, милиционерлар һәм хокук бозучылар түгел, ә мөнәсәбәтләрнең ике төрен билгеләү. «Без» — мин симпатия күрсәткән, даими аралашкан, барлык мәсьәләләр буенча теләктәш булган, минем ышанычымнан файдаланган барлык кешеләр. «Алар» — бөтенләй башкача. Мин аларны «үзебезнекеләрдән» аерам һәм анда үзем белмәгән, аралашмаган һәм түзеп тормаган бөтен кешене кертәм.

«Без» — мин кергән төркем ул. Аның эчендәниләр барганын мин яхшы аңлыйм һәм, шуны аңлаганлыктан, алга таба ничек хәрәкәт итәргә икәнен беләм, үземне өйдәге кебек ышанычлы хис итәм. Яшьтәшләрем яисә иптәшләрем төркеме — бу минем табигый әйләнә-тирәм, ягъни мин булырга яраткан һәм анда шатланып кайткан урын.

«Алар» — бу, киресенчә, мин булырга теләмәгән яисә була алмаган төркем. Аның турында минем күзаллавым бик томанлы. Мин аларның үз-үзләрен тотышларын начар аңлыйм, минем өчен аларның тәртибе алдан күзалларлык түгел.

«Без» һәм «алар» — бергәлектә яшәгән, бер-берсенә каршы торган, әмма бер-берсен тулыландырган ике төрле полюс, ике капма-каршылык. Әгәр дә «мин» теләктәш булган иптәшләр даирәсенең бик тар булуын искә төшерсәгез, сез моның белән килешерсез, дип уйлыйм. Киресенчә, «мин» уемда һәм читләтеп кенә күз алдына китергән замандашлар даирәсе бик киң.

Кешеләрнең ике категориясе бер-берсенә кирәк һәм бер-берсеннән башка яши алмый. Чыннан да, «алар» кем соң ул? Минем белән дустанә мөнәсәбәттә булмаган кешеләр генәмени? Юк. Бу — шулай ук потенциаль яктан, бәлки, бүген-иртәгә миңа дус яисә яхшы таныш булырга мөмкин таныш булмаган кешеләр. Булачак дусларыбызны таба торган резервуар ул.

Барлык танышу культурасы башка кешеләрнең дә яшәвенә корылган. Мондый танышлык кайда һәм кайчан барлыкка килә? Танышулар еш кына уртак уку яисә эш урынында, транспортта, урамда, музейда, театрда, кинода, поездда була. Кешеләр шулай ук ял итү урыннарында, дискотекаларда, чакырылган кунакта, туган көннәрдә һәм хәтта йорт хайваннары белән урамда йөргән вакытта да танышалар.

«Үзебезнекеләр» һәм «читләр»

Һәр кеше, төркем үз дөньясын билгеләп куярга, аны башкалардан чикләп алырга омтыла. Моны үз сыйныфыңны яисә үз мәктәбеңне күршеләрдән, үз илеңне чит илләрдән, намуслы кешеләрне намуссызлардан, үзеңнең татулык сөйгән дусларыңны һаман саен «маҗаралар» эзләп йөргән яшьләрдән аеру өчен эшлиләр. Тора-бара «без» — **«үзебезнекеләр»**гә, ә «алар» **«читләр»**гә әверелә.

Бу төшенчәләр галимнәр тарафыннан файдаланыла һәм түбәндәге төрләргә бүленгән күп санлы кешеләр категорияләре өчен уртаклык исем булып тора. **«Башкалар»** шуларның беренче төре — алар «мин» нейтраль һәм битараф караган чит кешеләр генә. Икенче төр — **«үзгәләр»**. Аларга «мин»нән үзенең дөньяга карашы, мәдәни нормалары, тәртип модельләре белән аерылып торучылар керә. Башка кабилә, ил вәкилләре «үзгәләр»гә керә.

«Үзгәләр» сүзе еш кына «башкалар» сүзенең синонимы ролен уйный. «**Чит** ил кешесе» төшенчәсе бернинди әхлакый гаепләү түгел. Бу очракта «үзгәләр» «башкалар»га тигез.

«Үзгәләр» һәм «читләр» башка ил вәкилләренә генә түгел, үз халкыңа да карарга мөмкин. Алар безнең арада яшиләр, ләкин бездән аерылып торалар. Төрле сәбәпләр аркасында һәм төрле дәрәҗәдә алар без нормаль яшәү рәвеше яисә тәртибе дип санаган нәрсәләрдән тайпылалар.

Ә үзеңне нормаль тоту һәм нормаль тотмау нәрсә ул? Бу сорауга бер генә төрле җавап биреп булмый. Ул әлеге культура вәкилләренең мәгълүм бер тарихи чорда кабул ителгән критерийларына бәйле. Кичә генә нормаль булмаган нәрсә иртәгә нормаль булып күренергә мөмкин,

ә безгә кабул ителмәслек булып тоелган нәрсәләр кайчакта башка халыклар тормышына бик әйбәт килеп керә.

Без аларны «үзебезнеке» яисә «чит» дип санавыбызга карамастан, барлык кешеләргә хөрмәт белән, аңлап, дусларча, түземлелек күрсәтеп, ягъни **толерантлы** карарга кирәк. Тирә-юньдәге кешеләр безнең өчен чын мәгънәсендә «үзебезнекеләр» булуына омтылыйк.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Толерантлык (*лат.* tolerantia — түземлек) — чит кешеләрнең тормыш рәвешенә, тәртибенә, гореф-гадәтләренә, фикеренә, идеяләренә, дини ышануларына түземле караш.

Йомгак ясыйбыз

«Без» һәм «алар» төшенчәләре мәҗбүри рәвештә тискәре төсмер алырга тиеш түгел. «Алар» теләсә кайчан безнең яхшы танышлар була алалар. «Үзебезнекеләр» һәм «читләр» терминнары катгыйрак, ләкин «читләр» шулай ук «үзебезнекеләр» булырга мөмкин. «Чит итеп» тоюга көнчелек, аңлашмау, курку кебек тойгылар йогынты ясый ала, аларны җиңәргә кирәк.

Белемегезне тикшерегез

1. «Үзебезнекеләр», «читләр», «үзгәләр» дип кемнәрне атыйлар?

2. «Үзебезнекеләр» «читләр»дән түбәндәгеләр белән аерыла...», «Үзгәләргә» түбәндәгечә карау хәерле...» фразаларын дәвам итегез.

3. Нәрсә ул толерантлык? Үз-үзеңне толерантлы тотуга мисаллар китерегез.

Практикум

1. Тарихтан «без», «алар», «үзебезнекеләр», «читләр», «үзгәләр» төшенчәләрен ачучы мисаллар китерегез.

2. «Үзебезнекеләр» «читләр»гә әйләнгән хәлләргә мисаллар китерегез. «Читләр» «үзебезнекеләр»гә әйләнү мисалларын күрсәтегез.

3. Бер мәгълүм фильм «Читләр арасында үз, үзләр арасында чит» дип атала (реж. Н. Михалков). Ә сезнең тормышыгызда шундый хәлләр булдымы?

§ 14. Таныш һәм таныш булмаган кешеләр дөньясы

Таныш һәм таныш булмаган кешеләр

Цивилизацияле җәмгыятьтә кеше гасырлар дәвамында биниһая күп кешеләрнең ярдәменә һәм алар белән хезмәттәшлеккә ихтыяҗ кичерә, шул ук вакытта аңа берничә кеше белән генә дуслык мөнәсәбәтләренә керергә җитәрлек гомер бирелә. Күз алдына китерегез, гомерегезне ничек бар шулай итү өчен, бихисап сандагы сезгә таныш булмаган кешеләрнең эшчәнлеге таләп ителә. Безне ризыклар белән тәэмин итүчеләр, юллар һәм коммуналь хуҗалыкның торышын тикшереп торучылар, законнар кабул итеп, аларның үтәлеше өчен җавап бирүчеләрнең хезмәтләре дә бик кирәкле.

Кешеләрнең әлеге гаять зур массасын үзегез танып белгән һәм исемнәрен хәтерләгән танышларыгыз даирәсе белән чагыштырыгыз. Сез, әлбәттә, тормышыгызга йо-

гынты ясаучы барлык кешеләр арасында белгән яисә ишеткән кешеләрнең бик кечкенә өлешне тәшкил итүен күрерсез. Сезгә таныш булган кешеләр даирәсе нинди кечкенә, таныш булмаганнары никадәр күп.

Таныш кеше — без исемен белгән яисә тышкы кыяфәте буенча таныган кеше генә түгел. *Ерак танышлар* сезнең белән бер милләт, җәмгыять, ил вәкилләре дә булырга мөмкин.

Таныш һәм таныш булмаган кешеләр белән үзара бәйләнеш

Безгә исемнәре мәгълүм *якын танышлар* белән без үзара бәйләнештә торабыз, алар белән аралашабыз. Без алар белән еш кына сөйләшәбез, белемнәребезне уртаклашабыз, үзебезне кызыксындырган проблемаларны тикшерәбез. Танышлар белән без үзара аңлашырга һәм аларда уңай фикер тудырырга тырышабыз. Ә таныш булмаганнар белән болай эшләмибез. Алар безнең белән берничек бәйле түгел, безнең алда бернинди җаваплылык сизмиләр, безнең белән үзара бәйләнеш тотмыйлар. **Танышлар** —без җаваплылык, кызыксынучанлык һәм бәйлелек мөнәсәбәтләре белән бәйләнгән кешеләр алар.

Бериш танышлар белән без көн саен диярлек очрашабыз, ә икенчеләрен бик сирәк күрәбез. Күрше кибет сатучысы белән азык-төлек алганда шактый еш очрашабыз, мәктәп укытучысы белән дә шулай ук. Ә кайбер кешеләрне белсәк тә, безнең көндәлек эшләребез алар белән турыдан-туры бәйләнгән булмагач, үзара аралашу мөмкинлеге бик аз. Мәсәлән, артистлар, сәясәтчеләр белән.

Кечкенә шәһәрдә, поселокта яисә авылда без, нигездә, якын танышлар чолганышында яшибез. Без алар белән күптән таныш һәм аларның тормышы турында барысын да беләбез кебек тоела. Зур шәһәрдә якын танышларга караганда ерак танышлар күп тапкырлар күбрәк. Шәһәрнең зурлыгына бәйле рәвештә, без бөтенләй башка социаль даирәләрдә яшибез дип әйтергә мөмкин.

Галимнәр кешенең характеры, яшәү рәвеше, гадәтләре һәм хәтта сөйләме дә аның нинди җәмгыятьтә — таныш яисә таныш булмаган кешеләр арасында яшәвенә бик нык

бәйле булуын күптән ачыклаганнар. Авыл халкы ачык һәм дустанә мөнәсәбәттә. Эре шәһәргә баргач та, алар үзләрен күнегелгән рәвештә тоталар.

Таныш кешеләрдән, иң элек, куркырга кирәкми, алар ышанычлы, һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торалар. Аларның өйләрендә буласы, иң якын туганнарын күреп сөйләшәсе килә. Кеше белән күбрәк таныш булган саен, аның турында күбрәк беләсебез килә. Ләкин таныш булмаган кешеләр безне бөтенләй кызыксындырмый диярлек. Алар безнең язмышта бернинди роль уйнамыйлар. Алар белән без, мөгаен, бүтән беркайчан да очрашмабыз.

Дуслар һәм танышлар — тормышыбызның, рухыбызның, эчке «мин»ебезнең аерылгысыз өлеше. Алар безгә кирәк, без аларсыз тулы канлы тормыш белән яши алмабыз. Әгәр дә кайбер танышларыбызны йә дусларыбызны югалтсак, яңаларын булдырырга ашыгабыз. Кеше таныш һәм үзенә якын кешеләр арасында яшәргә тиеш.

Таныш һәм таныш булмаган кешеләр арасында мөнәсәбәтләр принципиаль аерыла. Беренчеләре белән без ышанычлы һәм шәхси мөнәсәбәттә торабыз, аларның эшләре, проблемалары белән кызыксынабыз. Таныш булмаган һәм аз таныш кешеләр белән фәкать эшлекле мөнәсәбәтләрне генә саклап була. Ни өчен? Әгәр дә күрше кибеттәге сатучыны яисә табиб-терапевтны без елга берничә тапкыр, үзебезгә кирәк булганда гына очратсак, алар безнең өчен шәхес буларак түгел, ә мәгълүм бер рольне башкаручылар яисә ниндидер функцияне үтәүчеләр буларак кына кирәк. Сатучының функциясе (ягъни бурычы) — товар җибәрү һәм аның өчен түләү алу, һич тә артыгы түгел. Такси йөртүче безне өйгә кайтарды, без акча түләдек һәм аның белән аерылыштык, мөгаен, бөтенләйгәдер. Кыска гына вакытка безнең арада *эшлекле (формаль) мөнәсәбәтләр* урнашты.

Якын танышлар һәм дуслар белән бөтенләй башка төрле мөнәсәбәтләр булдырыла. Алар *шәхси мөнәсәбәтләр* дип атала. Безгә якын кешеләрдән файда түгел, ә рухи аралашу кирәк. Без якын кешегә мохтаҗ, безгә аның тугрылыклыгы, эмоциональ ярдәме, киңәше, авыр вакытта булышуы һәм таныш булмаган кешедән алып булмый

торган бик күп нәрсәләр кирәк. Аларны формаль мөнәсәбәтләргә кертеп булмый.

«Мин» һәм «башкалар»

Кеше тирә-юньдәге кешеләрнең һәм тулаем җәмгыятьнең көчле йогынтысы астында формалаша. Безнең әйләнә-тирәбезне тәшкил иткән «башкалар» кемнәр алар? Алар бездән ни тели? Ирегебезне чиклиләрме яисә, киресенчә, аны киңәйтү өчен, бөтен шартларны тудыралармы?

Яшүсмерләр үзләрен күзәтеп торуларын, үзләренә билге куюларын, җәза бирүләрен, мәгълүм бер рәвештә яшәргә мәҗбүр итүләрен, үгет-нәсыйхәт белән хак юлга бастырырга теләүләрен беләләр. Бай тәҗрибә туплана бара, үсүче бала шәхесе формалаша. Балага йогынты ясаучы әлеге «башкалар», күрәсең, дөрес һәм дөрес булмаган тәртипне аера беләләрдер. Алар үз-үзеңне дөрес тотканда хуплыйлар һәм нормадан тайпылганда дөрес булмаган гамәлләр өчен җәза бирәләр. «Башкалар» — ул теләсә кем түгел һәм безнең даирәгә очраклы эләкмәгәннәр. Кеше үзе бәйләнешкә кергән бик күп кешеләрдән тик кайберләрен — **«әһәмиятле башкалар»ны,** ягъни аларның бәяләре үзе өчен күпкә мөһимрәк булганнарны гына сайлап ала. Дус яисә туганнан-туган абый «башкалар» санына керә, ә узгынчылар — юк.

Кеше үзе өчен ясарга тиешле иң тәүге ачышларның берсе — «башкалар»ның үзара аерылуы. Без әйләнә-тирә дөньяны һәм кешеләрне сайлап алып бәялибез. Бер ишеләренә теләктәшлек белдерәбез һәм алар белән соңгы әйберебезне уртаклашырга әзер, ә башкаларны сизмибез яисә хәтта белә торып санга сукмыйбыз. Башкача әйткәндә, бала сайлап алырга һәм гамәлләре өчен җаваплылык булдырырга өйрәнә.

Әгәр дә сез төркем фикеренә каршы тора аласыз икән, шул чакта үзегезне бәйсез шәхес дип саный аласыз. Ләкин моңа ирешү җиңел түгел.

Әгәр дә сез башкалар фикере белән (бигрәк тә ул бердәм булмаганда) килешмисез икән, сезгә әле игътибар итмәсләр. Икенче тапкыр коллектив фикереннән тайпылу гаҗәпләну яисә ризасызлык тудырырга мөмкин. Ләкин инде сезнең

мөстәкыйльлегегез даими күренешкә әверелсә, коллектив сездән йөз чөерергә дә сәләтле. Еш кына бер-береңне кӯралмауга китерерлек конфликт туа. Сез инде башкалардан аерылып кына калмыйсыз, ә каршы торасыз. Сезнең хисләрегез дә бик каршылыклы. Уртак дошманга каршы берләшкән коллектив канатланып китә. Ә сез, киресенчә, үзегезне басынкы һәм югалып калган итеп сизәрсез. Сез, коллективка каршы барып, үз карашымны уртак фикергә каршы куеп, дөрес эшләдемме дип шикләнәсез. Бәлки, мин яклаган әхлакый принциплар һәм инанулар алай ук мөһим түгелдер? Үзегез генә калып сез хаклы булу-булмавыгыз турында шикләнә башлыйсыз. Бик сирәк кешеләр генә үз позицияләрен ахыргача яклый алалар.

Ләкин коллектив ялгышмый. Аның һәр әгъзасы, бөтен кеше ялгыша алмый, ә менә бер кеше дөрес уйламаска мөмкин дип ышана.

Мондый хәлдә нишләргә? Үз тәртибеңә читтән карый белергә кирәк. Үз иптәшләрең күзлегеннән карап, аларның сезгә нигә ачуланганнарын аңларга тырышу зарур. Ләкин бу вакытта хәйләләргә маташмагыз. Бу юлы үзегезгә тыйнак кына, үз-үзегезне артык нык яратмыйча карагыз. Әгәр моңа ирешә алсагыз, ышаныгыз, сез хәтта үзегезнең хаксызлыгыгызны һәм коллективның хаклылыгын аңласагыз да, үзегезне җиңүче итеп тоярсыз. Беренчедән, мондый фикергә алар түгел, сез килдегез. Икенчедән, үз-үзегезне тәнкыйтьләү сезне, үз позициягезгә ябышып ятуга караганда, «мин»егезне формалаштыру юлында күпкә алга китәргә этәргеч бирә. Өченчедән, сезнең кешелеклелек сыйфатларының иң кыйммәтлесен — башкалар турында кайгыртучанлык һәм алар хәленә керә белүне тәрбияләү мөмкинлеге туа.

Еш кына, башкаларга үпкәләп, без үзебезне кызгана башлыйбыз. Үзеңә карата рәхимсез булырга ярамый. Болай үзеңне дә, башкаларны да кызгана белми торган җансыз роботка әверелергә мөмкин. Үзегезне кызганыгыз, яратыгыз, ләкин үз файдагызга гына. Артыгын кылансагыз — сез инде үз-үзегезгә гашыйк эгоист. Андыйлардан читләшәләр, коллектив алардан котылырга тели.

«Ят кеше» һәм «чит кеше»

«Чит кеше» таныш булмаган, ягъни без начар белгән яисә бөтенләй белмәгән кеше генә түгел. Мөгаен, киресенчәдер. Ул миңа дөньяга карашлары, инанулары, яшәү рәвеше һәм тәртибе буенча ят, дияр өчен ят кешене без яхшы белергә тиеш. **Ят кеше** бу очракта миңа капма-каршы дигәнне аңлата. Мин бер, ә ул — бөтенләй башка, миңа капма-каршы яисә миңа чит-ят кыйммәтләрне яклый.

Миңа, дингә ышанучы буларак, атеизм (*грек.* atheos — алласыз), демократик җәмгыять тарафдары буларак — тоталитар (*лат.* totalis — тулысынча, бөтенләй; иҗтимагый тормышның барлык өлкәләре өстеннән дәүләтнең тулы контроле) строй чит нәрсә. Ниһаять, базар икътисадына теләктәш кеше буларак, мин теләсә нинди инициативаны тыючы һәм хәрәкәт ирегеи чикләүче икътисадны кабул итә алмыйм. Мин хыянәт һәм культурасызлыкны танымыйм.

Исемлекне дәвам итәргә дә мөмкин, чөнки һәр кешенең ул якларга әзер торган, йә ул кабул итә алмаган кыйммәтләре бар.

Ләкин монда бик мөһим бер төзәтмә кертергә кирәк. Мин таныган кыйммәтләргә капма-каршы кыйммәтләр — бу миңа дошман кыйммәтләр һәм карашлар. Шундый карашлы кешене мин «чит кеше» димим, ә дошман дим. Әгәр мин «ак», ә ул «кара» дисә, мин игелек эшләп, ул явызлык кылса, хәл ачыклана. Без — дошманнар. Ләкин күбесенчә кешеләрнең карашы минекеннән аерыла, ләкин бу аерымлык дошманнарча булмый.

Кешеләр бар нәрсәдә бер-берсенә капма-каршы була алмыйлар. Әгәр алар нәрсәдәдер килешмәсәләр, икенче бер нәрсәдә уртак фикергә киләләр.

«Үзеңнекеләр»не яклау

Башка, бигрәк тә таныш булмаган кешеләр белән аралашып, без үз төркемебез — сыйныфыбыз, мәктәп, гаиләбезне кызып-кызып яклыйбыз. Без чүпне читкә чыгармыйбыз, үзебезнекеләргә яла якмыйбыз, якын кешеләрнең кимчелекләрен яшерәбез, ахыр килеп дусларның кечкенә генә уңай якларын да бизәп күрсәтәбез.

«Үзеңнекеләр»не яклау — кешелеклелек сыйфаты. Алар турында тискәре фикер ишеткәндә, без аны кире кагарга, якын кешеләрнең матур данын яклап калырга тырышабыз.

Классташлар, дуслар яисә туганнарыбыз үзләрен начар яктан күрсәтә дигән фикер ишетсәк, без бар көчебезгә моны агымдагы хәлләргә бәйләп яки усал гайбәт дип аңлатырга тырышабыз. Югыйсә эчтән генә аларның бөтенләй үк гөнаһсыз түгел икәнлекләрен беләбез бит. Ләкин моның, чыннан да, шулай булуын күрсәтергә теләмибез.

Дустым турында начар фикер миңа ошамый, чөнки минем хакта да начар уйлаулары бар. Дусның тискәре даны миңа да тарала. Аны дус итеп үзем сайладым бит. Иптәш итеп кемне алуыңны алдан карарга булган. Дусларның кимчелеге үзебезнекенә әверелә. Нәтиҗәдә, якыннарыбызны яклап, без үзебезне яклыйбыз.

Гаиләдә кайчак үзара мөнәсәбәтләр катлаулы булса да, без елышу урыны һәм аңлашу тапкан җир ул. Ата йорты уйлап чыгарылган төшенчә түгел. Бу — иң чын чынбарлык. Ата йортына үсеп җиткән балалар да ашыгып кайта. Тик монда гына алар аңлау һәм теләсә нинди гамәлгә аклау таба алачак. Мәгълүм ки, кешеләрнең шундый үзенчәлекләрен аңлап, милиция качып йөрүче җинаятьчене үз өендә яисә дуслары арасында тота. Алар — качкынның һәм эзәрлекләнүченең соңгы өмете. Якыннарыбызны яклап, киләчәктә җавап итеп алардан да шундый ук яклау табарга өметләнүебез дә гаҗәп түгел.

Туганнар кайчак тупас һәм эгоист булып тоела, ләкин кирәк булганда һәрвакыт аларның ярдәменә исәп тота аласың. Аларны без аңлыйбыз һәм ярдәм итәбез. Кирәкле вакытта алар да бездән баш тартмаслар дип ышанабыз. Аңлашмау таныш булмаган кешеләр арасында ешрак очрый.

Туган йортыңда гына иминлек хисен тоеп рәхәтләнә аласың. Куркыныч туса, аның турында беренче булып якыннарың кисәтә. Бәлане булдырмый калу өчен алар, мөгаен, берләшәчәк тә. Туганнарча теләктәшлек яхшыда да, начарда да, кечедә дә, зурда да ачыла.

Йомгак ясыйбыз

Мегаполиста яшәүчеләр дә, зур булмаган шәһәрчектә торучылар да үз ватандашлары белән даими аралашып яши, ләкин аларның аралашу характеры нык аерыла. Зур шәһәрдә үз төркемнәреннән читтә аралашу фәкать формаль характерда гына була. Дуслар һәм танышлар — тормышыбызның аерылгысыз өлеше. «Үзеңнекеләр»не яклау — кешелекнең төп сыйфатларының берсе.

Белемегезне тикшерегез

1. «Танышлар», «таныш булмаган кешеләр», «әһәмиятле башка кешеләр» төшенчәләренең мәгънәсен аңлатыгыз. Кеше мөнәсәбәтләре дөньясында әлеге төркемнәр нинди әһәмияткә ия?

2. Нинди кешеләрне таныш дип атарга була? «Танышлык даирәсе» нәрсә ул?

3. Таныш кешеләр очрашканда кул биреп күрешү, сәламләү традициясе бар. Аерылганда кешеләр бер-берсенә кул болгыйлар, «сау булыгыз», «күрешкәнгә кадәр» диләр.
Уйлагыз, бу традицияләр кайчан һәм ни өчен барлыкка килгән? Таныш кешеләрнең аралашуында сез тагын нинди традицияләрне беләсез?

4. «Үзеңнекеләрне теләсә нинди хәлләрдә дә якларга кирәк» дигән фикер белән килешәсезме?

Практикум

1. Таныш булмаган кешеләр белән үз-үзеңне ничек тотуның төп кагыйдәләрен формалаштырыгыз.

2. Таныш һәм таныш булмаган кешеләр белән мөнәсәбәтләрне ачып бирүче хәлләр уйлап чыгарыгыз.

15. Яшьләрнең социаль портреты

Яшьләр — зур социаль төркем

Дөньяда бер миллиард чамасы яшүсмер исәпләнә. Алар өлкән буыннар булдырган матди һәм рухи кыйммәтләрне кулланучыларның гаять зур армиясен тәшкил итә.

Яшүсмер үзенең кече төркеменә (әйтик, мәктәптәге сыйныфка яисә спорт командасына) генә түгел, шулай ук зур төркемгә дә керә. **Зур социаль төркем** дип, без бер яшьтә (яшүсмерләр, яшьләр яки өлкән кешеләр), бер җенестән (ир-атлар яки хатын-кызлар), бер милләттән булган (руслар, татарлар яки якутлар), бер һөнәргә ия (адвокатлар, укытучылар, шахтерлар) кешеләрне атыйбыз.

Россия җәмгыятендә **яшьләр** — халыкның иң күп санлы төркемнәренең берсе. Монда *14 яшьтән алып 30 га кадәр* интервалны яшь чикләре итеп санау кабул ителгән. Яшь чакта кеше гомерендә бик мөһим вакыйгалар була: гомуми белем алу тәмамлана, һөнәр сайлана һәм һөнәри белем алына, хезмәт юлы башлана, кешеләр өйләнешә, балалары туа.

Кече яшьтәге яшьләр төркеменә 18 яшькәчә үсмерләр керә. Алар, нигездә, әти-әниләре тәрбиясендә яшиләр, белем алуларын дәвам итәләр яисә тәмамлыйлар һәм тулы гражданлык хокукларына (сайлау хокукы, никах теркәү) ия булмыйлар әле.

Урта яшьтәге яшьләр төркемендә 18—24 яшьлекләр (студентлар, яшь эшчеләр). *Өлкән яшьтәге* яшьләр төркемен кагыйдә буларак, һөнәр сайлаган, билгеле бер квалификация алган 25—30 яшьтәге кешеләр тәшкил итә.

Хәзерге җәмгыятьтә яшьләр проблемалары

Яшьләр төрле: социаль, икътисади һәм әхлакый проблемалар белән очраша.

Беренче проблема — яшь кешеләрнең саны кимү, димәк, халыкның олыгая баруы, яшьләрнең роле түбән төшү.

Икенче проблема — балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтлеге начараю. Хәзерге яшь буын элеккесеннән һәм физик, һәм психик сәламәтлек ягыннан калыша. Россия буенча уртача алганда мәктәп тәмамлаучыларның фәкать 10% ы гына абсолют сәламәт дип саналырга мөмкин, 45—50% укучыларның сәламәтлегендә исә җитди тайпылышлар бар. Армиягә алынучыларның хәрби хезмәткә яраклылыгы 80% ка кадәр кимеде.

Өченче проблема — яшьләр арасындагы эшсезлек. Статистик мәгълүматлар эшсезләр арасында яшь кешеләрнең өлеше зур булып калуын күрсәтә. Соңгы елларда яшьләр тормышында «эшсез калудан курку хисе» киң тарала башлады. Уздырылган тикшеренүдә сорау алуда катнашкан яшьләрнең 70% тан артыгы киләчәктә эшсез калудан курка.

Дүртенче проблема — хезмәтнең социаль кыйммәте, җәмгыять өчен мөһим һөнәрләрнең абруе төшү. Соңгы тикшеренүләр күрсәткәнчә, яшьләр эчтәлеге буенча кызыклы профессиягә түгел, ә матди яктан файдалы һөнәрләргә өстенлек бирәләр. 17 яшьлекләрнең 59,9 %ы өчен югары хезмәт хакы хәлиткеч роль уйный, ә 27 яшьлекләрнең — 65,3 %ы, 31 яшьлекләрнең 67,4 %ы зур эш хакына кызыга.

Хәзерге заман яшьләре сайлаган кыйммәтләр

Кызганычка, яшь кешеләрнең күпчелеге өчен акча тормышта иң төп нәрсә булып тора. «Яхшы яшәргә» теләү кешеләрнең табигый омтылышын чагылдыра, ләкин аның әхлакый чикләрдән чыгып китмәве бик мөһим.

Илебездә үткәрелгән һәм халыкара тикшеренү нәтиҗәләре яшь кешеләрнең торган саен матди уңышларга күбрәк йөз тотуын раслый. АКШ, Бөекбритания, Швеция, Россиядә һәм башка илләрдә шундый хәл күзәтелә. Соңгы елларда эш сайлаганда, үз-үзеңне күрсәтүгә омтылыш яисә иҗат итү, үз мөмкинлекләреңне гамәлгә ашыру зарурлыгына көннән-көн азрак әһәмият бирелә.

Яшьләр институты мәгълүматлары буенча, һөнәри абруй шкаласында беренче 10 урынны түбәндәгеләр били: юрист, коммерция банкы хуҗасы, табиб, югары уку йорты профессоры, менеджер, журналист, бухгалтер, кибет хуҗасы, тән сакчысы һәм мәктәп укытучысы. Соңгы өч урында — инженер, предприятие эшчесе, тракторчы.

Бүгенге үсмерләр кырыс чынбарлыкка һәм тормыш авырлыкларына элеккеге яшьләргә караганда күбрәк дәрәҗәдә игътибар юнәлтә. Тикшеренүчеләр көтелмәгән нәтиҗәләргә киләләр. Баксаң, бөтендөнья тинейджерлары өчен яңа төр өлгергәнлек хас икән, алар үз яшьләре өчен артык акыллы һәм мәгълүматлы. Аларга аеруча намуслылык, әдәплелек һәм кешелеклелек кебек сыйфатлар хас. Яшьләр арасында юмор һәм күңел ачу аерым әһәмияткә ия. Алдагы буын инфантильлегеннән аермалы буларак, бүгенге үсмерләр тормыштан уңышлы карьера (81 %), өйләнешү (69 %), тыныч шартларда яшәү (66 %) кебек җитди нәрсәләр көтәләр.

Бүгенге мәшәкатьләр кичәге үсмерләр проблемаларыннан еш кына бик нык аерыла. Хәзерге заман яшьләренең 73 % ы яхшы эш табу турында кайгырта, 67 %ы — үзләре яраткан нәрсәләрне югалтудан, 63 % үсмерләр әти-әниләренең саулыклары какшаудан куркалар.

Бүгенге яшьләр матди яктан тәэмин ителеш кискен аерылган шартларда үсте. Россиядә яшәүче күпчелекнең тормыш дәрәҗәсе түбән төште, әмма кайберәүләр элеккедән дә баерак яши башлады. Болар барысы да турыдан-

туры яшьләргә кагылды. Кемнәргәдер ата-анасы кирәк кадәр акча биреп бара. Ә үсмерләрнең берише үзе яшәрлек акча эшләргә сәләтле. Яшьләрнең якынча яртысы укудан бушаган арада эшләп ала. Акчаларын алар, нигездә, күңел ачуга тоталар, бер өлешен гаилә бюджетына бирәләр һәм киләчәктә укуларын дәвам итү өчен җыеп баралар. Европа илләре һәм АКШ яшьләре дә шуңа охшаш шартларда яшиләр, аларга яшәү һәм күңел ачу өчен шулай ук эшләргә туры килә. Ләкин чын кыйммәтләр, мәсәлән, якын кешеңә булышырга теләү абруйлы эш урыны һәм акчага ия булу кебек максатлар белән алыштырылырга тиеш түгел.

Реаль тормыш белән танышкач, күп кенә яшьләрнең үзләре көткән нәрсәне шунда ук ала алмаганга күңелләре төшә. Проблемаларның берсе шунда ки, олыларның җитәрлек кадәр акча эшли башлаганчы зур тәҗрибә туплауларын һәм үз эшләрендә чын белгечкә әверелүләрен яшьләр әле аңлый алмый.

Муллыкка авыр хезмәт һәм зур тырышлык белән ирешкән ата-аналар еш кына балаларының тормышка һәм хезмәткә өстән һәм җиңел караулары белән ризалашмыйлар.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Инфантильлек (*лат.* Infantilis — балаларга хас) — өлкән кешенең кечерәк яшьтәгеләргә хас тәртибе, характер сыйфатлары.

Икътисади реформалар Россия яшьләрендә тискәре чагылыш тапса да, алар инде яңа чынбарлыкка яраклаштылар яисә яраклаша баралар. Яшьләрнең зур өлеше инде базар икътисадына күнде. Алар бүген җәмгыятьнең яңа катлауларына керә.

Яшьләр икътисадта гына түгел, сәясәттә дә актив хәрәкәт итә. Җәмгыятьнең җитәкче элитасы яшәрә бара. Икътисадта кайчак белемнәре дә җитеп бетмәгән «яңа руслар»га алмашка бер яки ике югары белемгә ия, чит телләрдә иркен сөйләшкән, компьютерны камил белгән «яңа яңа руслар» килә. Сәясәткә, банк эшенә, эшмәкәрлеккә, бизнеска килгән хәзерге заманның 30—40 яшьлекләре — югары дәрәҗәдәге профессионаллар.

Эшмәкәрлек үсеп килүче буынның шактый зур өлеше өчен көннән-көн кызыклырак була бара.

Яшьләр Россиянең иң йогынтылы социаль-сәяси көчләре арасына һаман саен активрак керә баралар. Яшүсмерләр дә җәмгыятьтә тоткан рольләрнең әһәмиятен күбрәк аңлый башладылар. Яшь буын үзен Россиянең тотрыклы үсешенең төп факторы һәм мәгълүм бер дәрәҗәдә җәмгыятьтәге тамырдан үзгәрешләрнең этәргеч көче дип саный. Болар барысы да яшь буында базар икътисадына, гражданнар җәмгыятенә хәрәкәт потенциалы үсә баруын дәлилли.

Йомгак ясыйбыз

Җәмгыятьнең социаль төзелеше үзгәргәндә, яшьләрнең социаль портреты да үзгәрә бара. Базар икътисады шартларында яшь кеше портретында прагматизм һәм күңел ачуга тартылу өстенлек итә. Шуңа да карамастан яшүсмерләр мәгълүматлы, максатка омтылучан буын буларак, белем алу зарурлыгын да аңлыйлар.

Белемегезне тикшерегез

1. Бүген яшүсмерләр һәм яшьләргә кагылган тормыш үзенчәлекләрен санап чыгыгыз. Алар яшьләргә ничек тәэсир итә?

2. Сез яшьләрнең нинди проблемалары барлыгын беләсез? Аларны ничек хәл итеп була?

3. Төрле чорларда яшьләрнең үз кумирлары (алар охшарга теләгән кешеләр) булган. Ә хәзерге заман яшьләре өчен кемне кумир дип атар идегез? Ни өчен?

4. Сез белгән яшүсмерләр нинди кыйммәтләргә йөз тота?

5. Әти-әниләрегезнең нинди кыйммәтләрен кабул итәсез һәм нindиләрен кире кагасыз? Ни өчен икәнен аңлатыгыз.

Практикум

1. Түбәндәге әйтемнәрнең кайсылары белән килешергә була?

«Хәзерге яшьләрнең кыйммәтләре үткән буын яшьләренеке кебек үк»;

«Хәзерге яшьләр тормышта элеккеге яшьләр хөрмәт иткән нәрсәләрне түгел, ә бөтенләй башка кыйммәтләрне югары бәяли»;

«Хәзерге яшьләрнең акчадан тыш бернинди даими кыйммәтләре юк».

Фикерегезне дәлилләгез.

2. «Сыйныф, мәктәп, район, шәһәр яшьләре проблемалары» дигән темага матбугат, радио, телевидение, Интернет материаллары нигезендә хәбәр әзерләгез.

III бүлек

Яшүсмер һәм закон

16. Яшүсмер чакның юридик чикләре

Балигъ булмаганнарның хокукый статусы үзенчәлекләре

Кешегә 14 яшь тулды. Балачак тәмам. 14 яшь ул — мөстәкыйльлеккә бер адым, аның башлангыч чорына аяк басу дигән сүз. Яшьлеккә керү кызларны һәм малайларны илебез гражданнары итеп рәсми рәвештә тану белән бергә туры килә. Аларга паспорт тапшыралар. Паспорт алу — олы вакыйга, бу көннең мөһим һәм шатлыклы булып истә калуы бик мөһим. Документ үзе — паспорт — җирле милиция бүлекчәсенең паспорт өстәлендә алдан ук, законнар белән билгеләнгән тәртипне төгәл саклап әзерләнә.

Һәрбер яшь — кешенең физик яисә социаль, шулай ук *юридик характеристикасы да* булып тора. Хокук һәм бурычларның булуы әнә шуны күрсәтә. Башка сүзләр белән әйткәндә, һәр яшьтә сез үз дәүләтегезгә карата бөтенләй башка бурычларны башкарасыз.

Безнең илдә яшүсмер чак ике категорияне — кече яшьтәгеләрне һәм балигъ булмаганнарны үз эченә ала.

Кече яшьтәгеләр дип безнең закон *6 яшьтән алып 14 яшькәчә* балаларны атый. Алар инде көнкүрештә вак алыш-биреш ясарга, мәсәлән, уенчыклар сатып алырга хокуклы. 10 яшьтән баланың фикеренә юридик мәгънә бирелә. Әйтик, әти-әни, баланың фикерен исәпкә алмый торып, аның өчен мәктәп сайлый яисә фамилиясен алыштыра алмый. Ә 14 яшьтән ул, үз хокукын яклап, судка мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Балигъ булмаганнар — бу *14 яшьтән алып 18 яшькәчә* затлар. Әлеге термин юриспруденция өлкәсендә еш кулланыла. Балигъ булмаганнар — закон хокукый сәләтлелеккә ия булу яшенә җитмәгән яшьтәгеләр дип саналган затлар. Балигъ булмаганнарның законлы мәнфәгатьләрен (тулысынча яки өлешчә) аларның әти-әнисе, башка законлы вәкилләр, опекуннар, попечительләр яклый. Закон бу яшьтәге категориянең хезмәт, гражданлык һәм башка хокукларын саклау чараларын күздә тота. РФның Җинаять кодексында балигъ булмаганнар турында эшләрне карауның аларны аеруча җентекләп тикшерү һәм карауны тәэмин итүче аерым тәртибе билгеләнгән.

Балигъ булмаганнар хезмәт хаклары һәм стипендияләре белән мөстәкыйль эш итә алалар. 16 яшьтән эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә һәм хәтта эшсез дип танылырга да мөмкин. Безнең законнар буенча баланың дәгъвасы (гаризасы) опека һәм попечительлек органнарында карала, ә 14 яшькә җиткәч, ул судка мөрәҗәгать итә ала.

Безнең илдә җинаять җаваплылыгы 16 яшьтән башлана. Ләкин бу әле моннан яшьрәкләрнең кылган җинаятьләре җәзасыз кала дигән сүз түгел. Аерым хокук бозулар өчен җаваплылык 14 яшьтән башлана. Аларның исемлеге РФның Җинаять кодексында китерелгән.

Җәза бирү чарасы буларак, 1 айдан 4 айгача кулга алу 16 яше тулганнарга карата кулланылырга мөмкин. Административ җаваплылыкка шулай ук 16 яшьтән соң тарталар. *Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре* 11 яшьтән 14 яшькәчә балаларны, хокук бозган өчен, дәвалау-тәрбияләү характерындагы махсус мәктәпкә җибәрергә мөмкин.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Хокукый сәләтлелек — хокуклар һәм бурычлар алу һәм аларны гамәлгә ашыру сәләте.

Хокук — чыганакларда (законнарда, указларда, карарларда) чагылдырылган, дәүләт билгеләгән, аның тарафыннан сакланган гомуммәҗбүри тәртип кагыйдәләре системасы, аларны бозу юридик җаваплылыкка китерә.

Юридик җаваплылык — дәүләтнең хокук таләпләрен үтәргә мәҗбүр итүе; хокук бозулар өчен җаваплылык.

Законга мөрәҗәгать итик

РФ Гражданлык кодексы. Өземтә

14 яшькә җитмәгән (кече яшьтәге) балигъ булмаганнар өчен алыш-бирешне... аларның ата-анасы, уллыкка-кызлыкка алучылар яисә опекуннары... башкара ала.

6 яшьтән алып 14 яшькәчә кече яшьтәгеләр мөстәкыйль рәвештә түбәндәгеләрне башкаруга хокуклы: көнкүрештә вак алыш-бирешләр...

Кече яшьтәгенең алыш-биреше буенча мөлкәти җаваплылык... аның әти-әнисенә йөкләнә...

14 яшьтән алып 18 яшькәчә балигъ булмаганнар мөстәкыйль рәвештә ата-ана рөхсәтеннән башка...:

1) үзенең эш хакы, стипендиясе һәм башка керемнәре белән эш итәргә;

2) фән, әдәбият яисә сәнгать әсәре, уйлап табу... авторы хокукын тормышка ашырырга;

3) ...кредит учреждениесенә кертемнәр кертергә һәм алар белән эш итәргә;

4) көнкүрештә вак алыш-бирешләр... башкарырга хокуклы.

14 яшьтән алып 18 яшькәчә балигъ булмаганнар мөлкәти җаваплылыкны мөстәкыйль башкара...

Җитәрлек кадәр дәлилләр булганда суд әти-әнисе үтенече буенча... 14 яшьтән алып 18 яшькәчә

балигъ булмаганнарның үз хезмәт хакы, стипендиясе яисә башка керемнәре белән мөстәкыйль эш итәргә хокукын чикләргә яки аннан мәхрүм итәргә мөмкин...

Балигъ булганнан соң, үсмер тавыш бирү хокукы ала, ул тулы хокуклы һәм актив гражданга әверелә. Шушы мизгелдән юридик күзлектән караганда яшүсмер өлкәннәр категориясенә керә.

Хокук яклавы астында

«Хокук» сүзе үз атамасын *лат.* «justitia» (дөреслек, гаделлек) сүзеннән алган, чөнки хокук борынгы заманнарда игелекле һәм гадел эш башкару сәнгате булып аңлашылган. Шуннан бирле бер генә җәмгыять тә хокуктан башка яши алмый: ул кешеләргә бәхәсләрне хәл итәргә мөмкинлек бирә, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен урнаштыра. Хокук гади гражданнарны яклый.

Борынгы Грециядә философ һәм җәмәгать эшлеклесе *Платон* (б. э. к. 427—347 еллар) яшәгән. Берзаман ул, үзенең укытучысы Сократны хөкем иткәнне һәм җәзалап үтергәнне күреп һәм гаҗиз булып, гадел һәм кешеләрне бәхетле итәрлек дәүләт төзелеше проекты эшләргә карар кыла. Һәр кеше үз эше белән шөгыльләнергә һәм аны бик оста башкарырга тиеш дип саный ул. Кешеләр тумыштан ук тигез хокуклы, дип уйлап, бар нәрсәнең үлчәме — кеше дип санылар безнең бабайлар да.

Без бүген бер генә кешенең дә икенчесенә охшамавын һәм безнең һәркайсыбызның индивидуаль булуын бик яхшы беләбез. Кешеләр тышкы кыяфәте, җенесе, яше, белеме, матди хәле, характеры һ. б. белән аерыла. Бер

Кызыклы фактлар

Мәгълүм ки, бик борынгы заманнарда ук кешеләрнең хокуклары бертигез булмаган. Коллар белән, мәсәлән, җансыз әйбер кебек эш иткәннәр: үтерә, кыргый җанварларга ташлый, авыр эш башкарырга мәҗбүр итә алганнар. Антик чорда коллар исемнәреннән дә мәхрүм ителгән, аларны йә туган җирләре, йә хуҗалары исеме белән атаганнар.



Кызыклы фактлар

Тарихта кешеләрне төрлечә җәзага тартканнар. Грециядә борынгы заманнарда качкан һәм буйсынмаган өчен колларга келәймә сукканнар, таш ватарга сөргәннәр, ә Римда озак вакытлар «ашка-аш, ташка-таш» принцибы хөкем сөргән, бу исә гаепледән, аның туганнарыннан үч алырга мөмкинлек биргән. Соңрак китерелгән зыянны акчалата штраф белән каплатканнар.

коллективта эшләп һәм яшәп, алар бердәй тәртип кагыйдәләренә буйсына. Соңгылары тыныч һәм тотрыклы җәмгыятьтә көн итү өчен кирәк.

Бик күп еллар элек кешеләр дәүләтнең, аларны берләштереп, хокуклар гарантияләргә һәм һәркайсының мәнфәгатьләрен якларга тиеш булуына инанганнар. Фәкать шул очракта гына дәүләт һәм кеше арасында яхшы мөнәсәбәтләргә ирешеп була.

Яшь кеше беренче адымнарыннан ук закон канаты астында яши. Шуларның иң мөһиме — Берләшкән Милләтләр Оешмасы (БМО) тарафыннан кабул ителгән (1989 елда) *Бала хокуклары турында конвенция.* Планетабыздагы барлык илләр диярлек Конвенция статьяларын үтәргә булалар. Балаларга белем бирү, тулы кыйммәтле үсеш, кыен хәлләрдә ярдәм итү, көч кулланудан яклау өлкәннәр тарафыннан гарантияләнә дигән сүз бу. Балалар күбесенчә үзләреннән өлкән, акыллырак һәм тәҗрибәлерәк кешеләргә бәйле бит.

Рәсемне карагыз. Борынгы Русьта гаделлек һәм яклауны кемнән эзләгәннәр?

Илебезнең хәзерге законнарында кешеләрнең бергәләп яшәвенең түбәндәге мөһим принцибы ныгып урнашты: үз хокукларында һәркем тигез. Һәм монда синең кем булуың: ир-атмы, хатын-кызмы; авырумы, сәламәт кешеме; акыллымы, юләрме; көчлеме, көчсезме; эшлисеңме, юкмы — һич тә мөһим түгел.

РФның Гражданлык процессуаль кодексы буенча үз хокукларыңны яклау максаты белән судка дәгъва бирү, үз эшеңне алып баруны вәкилеңә (мәсәлән, адвокатка) тапшыру хокукы тулысынча 18 яшьтә башлана. Бу — гражданлык-процессуаль хокукый сәләтлелек дип атала.

18 яшькә кадәр баланың мәнфәгатьләрен аның *законлы вәкилләре* (әти-әнисе яисә аны алыштыручы затлар) яклый, ягъни бала алар ризалыгыннан чыгып эш итә (объектив әйткәндә, ата-ана турыдан-туры бала белән бергә эш итә). Ләкин РФның Гаилә кодексында 56 нчы статья бар, ул балага инде 14 яшьтән үк, үзенең законлы мәнфәгатьләрен яклап, судка мөрәҗәгать итү мөмкинлеге бирә.

Кызыклы фактлар

Кешелек җәмгыяте тарихында кайбер кешеләрнең башкалар тормышына һәм хокукларына төкереп карау мисаллары да аз түгел. Мәгълүм *Иван Грозный* патша (1530—1584), үзенә ошамаган кешеләрне рәхимсез җәзалап, боярларны асарга һәм сихерчеләрне яндырырга әмер биргән. Кешеләр халык күз алдында җәзалап үтерелгән.

Халыкны куркытып, хакимият вәкилләре дәүләтне һәм анда үзләренең тоткан урыннарын ныгытырга маташканнар.

Җәмгыять шулай төзелгән ки, бер кешенең хокуклары икенчесе өчен бурычка әверелә. Бу якынча табигатьтә XVIII гасырда бөек М. В. Ломоносов ачкан матдә саклanышы турындагы мәгълүм закондагы сыман килеп чыга. Әгәр дә бер урында материя өстәлсә, кайдадыр икенче урында ул кими дигән сүз, дип яза ул.

Гражданин хокуклары да шулай ук. Сезнең *хокук* дәүләткә *бурыч* өсти. Сезгә бирелгән нәрсә аннан алына. Гражданнар, үзләре яшәгән дәүләт аларның иминлеген чынбарлыкта яклау белән шөгыльләнсен өчен, салым түлиләр дә. Дәүләт — кеше тормышы куркынычсызлыгының гаранты. Башкача әйткәндә, үз гражданнарының гомерен сакларга вәгъдә биреп, дәүләт алар алдында моның өчен җаваплылык ала.

Безнең илдә, кеше үтергән өчен, шулай ук аның гомеренә теләсә нинди башка зыян китергән өчен, суд карары нигезендә катгый җәза бирелә. Үзлегеңнән хөкем итү, ягъни дәүләтнең хокук саклау органнары катнашыннан тыш, андый кешегә җәза бирү турында карар чыгару тыела.

Безнең илдә берәү дә җәзаланырга, җәбер-золымга, яисә кешене түбәнсеткән рәхимсез мөнәсәбәткә дучар ителергә тиеш түгел. РФ Конституциясендә шулай диелә. Кеше өстеннән мәҗбүри медицина, фәнни тәҗрибәләр үткәрү көч куллануның бер төре булырга мөмкин. Мондый гамәлләр тыелган. Хәтта гадәти укол кебек кечкенә генә медицина катышуы да пациент ризалыгыннан башка рөхсәт ителми. Әгәр кешегә 14 яшь тулмаган булса, карарны аның әти-

әнисе яисә аларны алыштыручы кабул итә. Дөрес, нин-
дидер прививкадан баш тартканчы уйларга кирәк: үзеңне организм каршы тора алмаслык нindидер чир белән авыру куркынычына дучар итү кирәкме?

Хәзерге Россиядә кайбер җинаятьчеләргә карата атып үтерү ысулы белән тормышка ашырылучы үлем җәзасын куллану туктатылды. Һәр кеше башка кеше һәм үз гомеренең кадерен белергә, аның бер генә тапкыр бирелүен һәм башка кешегә карата үзеңә кылынуын теләмәгән гамәлне башкармау зарурлыгын аңларга тиеш.

Хәзерге Россиядә юридик кагыйдәләр үтерүләр, авыру кешегә ярдәм күрсәтмәгән өчен җинаять җаваплылыгы билгели. **Юридик җаваплылык** — хокук бозучыларга карата кулланылган тискәре нәтиҗәләр ул. Аларның төп максаты — законны беркайчан да бозмаска мәҗбүр итеп, кешене үзгәртү, үз гаебен йолу, куркынычны кисәтү. Кызганычка каршы, гамәлдә очраклы хәлләрнең бергә туры килүе аркасында, кешенең суд эскәмиясенә эләгү очраклары да бар. Барлык фактлар җинаятьтә аның катнашы барлыгын күрсәтә, һәм ул җавапка тартыла. Тик күп еллардан соң гына аның бернинди хокук бозулар эшләмәгәнлеге билгеле була. Законга хезмәт итүчеләрнең — судья, прокурор, тикшерүчеләрнең — профессионаллар булуы, нәрсә булуын грамоталы ачыклап, дөрес карар кабул итүләре менә шуңа күрә дә бик мөһим. Монда белгечнең нинди белем алуы да зур роль уйный.

Йомгак ясыйбыз

Җәмгыять кече яшьтәге һәм балигъ булмаган гражданнарга үз яшьләренә туры килгән, аларны судта яклау мөмкинлеге булган чын хокуклар бирде. Шул ук вакытта яшүсмер, олы кеше кебек үк, үзенең җәмгыять каршындагы законнар белән билгеләнгән җаваплылыгының күләмен аңларга тиеш.

Белемегезне тикшерегез

1. «Кече яшьтәге», «балигъ булмаган», «хокук», «юридик җаваплылык», «хокукый сәләтлелек» төшенчәләренең асылын аңлатыгыз.

2. «Бер кешенең хокукы икенче кешеләр хокукы башланган урында бетә» дигән гыйбарәне ничек аңлыйсыз? Сез аның белән килешәсезме?

3. Үлем җәзасын куллану турындагы мәсьәлә бик катлаулы һәм бәхәсле. Күп илләрдә ул тыелган. Бу хакта сез ни уйлыйсыз?

4. «16 яшендә үсмер инде түбәндәгеләргә хокуклы...», «14 яшендә инде үсмер түбәндәгеләр өчен закон буенча җавап бирә...» дигән җөмләләрне дәвам итегез.

5. Аңлатып бирегез, ни өчен нәкъ менә 14 һәм 16 яшьтән башлап яшь гражданин нәрсәдер өчен җавап бирә.

Практикум

1. Балигъ булмаган яшүсмерләр тарафыннан закон нигезендә үз хокукларын тормышка ашыру мисалларын китерегез. Матбугат, радио, телевидение материалларыннан, әти-әниегез ярдәменнән файдаланыгыз.

2. «Яшүсмер үз хокукларыннан ничек итеп файдалана ала» дигән темага зур булмаган инша языгыз.

3. Хәзерге заман Россия җәмгыяте тормышыннан кеше хокукларын саклау һәм аларны бозуга анык мисаллар китерегез.

17. Гражданин буларак яшүсмер

Гражданин һәм гражданлык

14 яшьтә илебез гражданнары **паспорт** ала. Ул милициянең җирле бүлекчәсе тарафыннан бирелә. Бу — кешенең шәхесен таныклаучы юридик документ. Анда гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме языла. Аның теркәлгән урыны — ул яшәгән урын күрсәтелә. Әмма кешегә төрле хәлләр белән бәйле рәвештә башка җирләрдә яшәү дә тыелмый. Чит илләргә бару өчен, чит ил паспорты рәсмиләштерелә. Әгәр кеше паспортын югалтса яисә аны урласалар, бу хакта кичекмәстән милициягә хәбәр итәргә кирәк.

Яшүсмер — ул үз әти-әнисенең яраткан улы яки кызы, тырыш укучы, үсмерләр төркемендәге дус, икътисадта кулланучы гына түгел, ул шулай ук үз дәүләтенең гражданины да.

Тумыштан да, үзең теләп тә гражданин булып була. Әгәр сезнең әти-әниегез Россия гражданлыгына ия икән, сез үзеннән-үзе Россия Федерациясе гражданины буласыз.

Гражданлык — затның әлеге дәүләтнеке булуы билгесе — ул нәселдән килә һәм аны алып та була. Үз илең гражданлыгын алыштырырга да мөмкин, ләкин үсеп җиткәч — паспорт алгач, үз язмышыңны мөстәкыйль хәл итәрлек һәм икътисади яктан бәйсез кеше булгач кына. Гражданлык — җәмгыятьтә кешегә бирелгән һәм дәүләт тарафыннан (хокук саклау органнары, закон чыгаручылар, министрлыклар, учреждение, фондлар һ. б.) саклана торган мәгълүм хокуклар да. Әгәр сез илдә яшисез һәм аның гражданлыгына ия түгел икән, күп кенә уңайлыклардан мәхрүм калуыгыз ихтимал. Сезнең даими эшегез һәм даими тору урыныгыз булмый. Сезнең белән бәхетсезлек очрагы килеп чыгарга мөмкин, ләкин дәүләт сезнең проблемаларны хәл итмәячәк, сез аның гражданины түгел бит.

Гражданлык хокуклары алу өчен, кешеләр моннан 2500 еллар элек үк көрәшә башлаган. Антик Грециядә һәм Римда тик ирекле кешеләр генә гражданнар дип саналган. Коллар, чит ил кешеләре, хатын-кызлар һәм ярлылар тавыш бирү хокукыннан мәхрүм ителгән булган.

Хәзер кеше гражданлык хокукларыннан гражданлык алган мизгелдән үк тулы күләмдә файдалана ала. Балалар һәм яшүсмерләр гражданлыкның бөтен статусына ия түгел әле, чөнки сайлауларда тавыш бирү хокуклары юк, өлкәннәргә генә бирелгән башка кайбер хокукларга да ия түгел. Күп кенә илләрдә хөкем ителүчеләр дә гражданлык хокукларын югалталар. Алар тавыш бирә һәм хакимият органнарына сайлана алмыйлар.

Гражданин үз иленең Конституциясен таный, үзенә бирелгән хокуклардан файдалана һәм конституциячел вазифаларын үти. Шулай ук дәүләт тә үз гражданнарының гомерен, мөлкәтен, хезмәт һәм ялын сакларга йөкләмә ала.

Кеше хокукларының гомуми декларациясе, Кеше хокуклары турында халыкара пакт, Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә беркем дә гражданлыктан яисә аны үзгәртү хокукыннан мәхрүм итела алмый. Дәүләт һәр

гражданга, ул кайда гына булса да, хокукый яклау гарантияле.

Менә шуңа да **кеше һәм гражданин хокуклары һәм ирекләре** — язмача цивилизация яшәп килгән соңгы 5—6 мең елда кешелекнең иң зур казанышы. Әлеге гражданлык казанышлары ниндиләр соң?

Кеше хокуклары 1948 елгы Кеше хокукларының гомуми декларациясендә, 1966 елгы Кеше хокуклары турында халыкара пактта, шулай ук дәүләтләрнең *конституцияләрендә* һәм *законнарында* беркетелгән.

Россия Федерациясендә кеше һәм гражданин хокуклары һәм ирекләре гомумтанылган халыкара хокук нормалары һәм РФ Конституциясе нигезендә таныла һәм гарантияләнә.

Закон һәм суд каршында барысы да тигез. Дәүләт кеше һәм гражданин хокуклары һәм ирекләре тигезлеген кешенең җенесенә, раса, милләтенә, теленә, килеп чыгышына, мөлкәти һәм вазифаи хәленә, тору урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, кайсы иҗтимагый берләшмәләргә керүенә бәйсез рәвештә гарантияли. Ирләр һәм хатын-кызлар бердәй хокук һәм ирекләргә, аларны гамәлгә ашыру өчен тигез мөмкинлекләргә ия.

Гражданлык (шәхси) хокуклары һәм ирекләре

Гражданлык хокуклары *кеше шәхесе белән бәйле һәм һәр кешегә тумыштан бирелгән*, шуңа аларны шәхси диләр. Алар кеше тормышын һәм эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк.

Кешенең гражданлык яисә шәхси хокукларына түбәндәгеләрне кертәләр:

- яшәүгә хокук;
- ireккә һәм шәхси кагылгысызлыкка хокук;
- торакның кагылгысызлыгына хокук;
- шәхси тормышның кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, язышу, телефоннан сөйләшү серенә хокук;
- Россия Федерациясе территориясендә законлы рәвештә яшәгән һәркем өчен күченеп йөрү ирегенә һәм яшәү урынын сайлауга хокук.

Һәркемгә фикерләү һәм сүз иреге, вөҗдан иреге, теләсә нинди дин тоту яисә бернинди дин тотмауны да кертеп, дин тоту иреге гарантияләнә.

Сәяси хокуклар

Сәяси хокуклар — *гражданнарның дәүләтнең сәяси тормышында катнашу мөмкинлеген* тәэмин итүче хокуклар.

Россия Федерациясе Конституциясендә гражданнарның сәяси хокукларына түбәндәгеләр керә:

- үз мәнфәгатьләрен яклау өчен берләшүгә хокук;
- тыныч җыелышларга, митингларга, урамда йөрүләргә хокук;
- дәүләт эшләренә идарә итүдә катнашуга хокук;
- сайлау һәм сайлану хокукы;
- дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына шәхсән мөрәҗәгать итү һәм күмәк мөрәҗәгать җибәрү хокукы.

Илебез гражданнары тыныч кына, коралсыз, оешкан төстә, башка кешеләрнең хокукларын бозмыйча җыелышлар, митинглар яисә демонстрацияләр үткәрә алалар. Мондый чараларда кешеләр нинди дә булса мәсьәлә буенча үз мәнфәгатьләрен, позицияләрен яклыйлар, илнең сәяси тормышына актив йогынты ясыйлар.

Мондый чаралар уздыру хокукына фәкать ил гражданнары гына ия. Шулай да чараларны әзерләүнең билгеле бер кагыйдәләре бар. Халык алдында чаралар уздыру турында җирле хакимиятне кимендә 10 көн алдан кисәтеп куярга кирәк. Аларны уздырганда законны үтәү һәм тәртип бозмау шарт. Әгәр дә гражданнарның сәламәтлегенә, аларның гомеренә, әхлагына куркыныч туса, хакимият вәкилләре бу чараны тыярга мөмкин.

Илебез гражданнары дәүләт белән идарә итүдә катнашырга хокуклы. Алар дәүләт хакимияте, җирле үзидарә органнарына сайлый һәм сайлана алалар. Гражданнарның җәмгыять, дәүләт эшләренә идарә итүдә катнашуының иң массакүләм рәвешен *сайлаулар* тәшкил итә. Гражданин Дәүләт Думасы депутатларын, Президентны, хакимиятнең җирле органнары вәкилләрен сайлый ала. Бу хокук аңа 18 яшь тулгач бирелә.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Җыелыш — гражданнар төркеменең билгеле бер урында мәгълүм проблеманы тикшерү яисә хәл итү өчен бергә җыелуы ул.
Митинг — гражданнарның күпләп җыелуы, анык бер мәсьәлә буенча таләпләрне халыкка җиткереп әйтү рәвеше.
Демонстрация — кешеләрнең плакатлар, транспарантлар күтәреп урамнан узуы.

Хәзерге заман җәмгыятендә гражданин дәүләт постына депутатлыкка кандидат сайлауларда, махсус бюллетеньне урнага салып, яшерен *тавыш бирү* юлы белән катнаша.

Иҗтимагый яшьләр оешмаларында катнашу закон буенча 14 яшьтән, ә балалар оешмасы әгъзасы булу 10 яшьтән рөхсәт ителә.

Кызыклы фактлар

Борынгы Грециядә үк инде кешеләр сайлау процедураларының махсус кагыйдәләрен булдырганнар. Урындагы кешеләрне сайлаганда халык җыелышында катнашучылар, әгәр тәкъдим ителгән кандидатура белән килешсәләр, кулларын күтәргәннәр. Башка очракта алар таш салалар (мәсәлән, кемгә дә булса өстенлек бирү турындагы мәсьәлә каралса). Кешене илдән куу турында мәсьәлә хәл ителсә, яшерен тавыш бирүнең аерым төре — чүлмәк ватыгы хөкеме кулланыла. Мәгълүм шагыйрь *Гомер* кешеләрнең үз ихтыярларын кычкырып кына белдерүләре турында да сөйли.

Россия Федерациясе гражданнарының бурычлары

Гражданнарның иң мөһим бурычлары исәбенә Россия Федерациясе Конституциясе түбәндәгеләрне кертә:

1. Гражданин дәүләт законнарын үтәргә бурычлы. Әгәр билгеле бер вазгыятьтә нәкъ менә шулай эшләргә кушкан юридик кагыйдә булса, аңа буйсынырга кирәк.

2. Гражданин салымнар, җыемнар түләргә тиеш. Бу акчалар дәүләт бюджетына керә, аннары гражданнарның үз файдасына ук бүлеп бирелә (балаларны тәэмин итүгә, пенсияләр түләүгә һ. б.).

3. Гражданин Ватанны сакларга тиеш. Бу вазифа илнең һәм анда яшәүче кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өчен бик мөһим.

4. Гражданин табигатьне сакларга тиеш. Әлеге бурыч аның сәламәтлеген саклауга хокукы белән тыгыз бәйле. Кеше зыян салган әйләнә-тирә мохит аның үз организмына ук тискәре йогынты ясый бит.

5. Гражданин балалар һәм хезмәткә сәләтсез ата-анасы турында кайгыртырга тиеш. Гаилә хокукы нормалары мондый мәсьәләләрне җайга сала.

6. Гражданин мәдәният һәйкәлләрен сакларга тиеш.

Әгәр дә гражданинга тагын да өстәмә бурычлар йөкләнә икән — бу аның хокукларын бозу.

Яшүсмернең хокуклары һәм бурычлары турында тагын да җентекләбрәк без алдагы параграфта сөйләшербез.

Йомгак ясыйбыз

Гражданин һәм дәүләтнең үзара мәнфәгатьләре Конституция белән билгеләнә. Балалар һәм яшүсмерләр балигъ булганчы тулы гражданлык статусына ия түгелләр һәм тавыш бирә, дәүләт идарәсе органнарына сайлана алмыйлар. Илебез гражданнары буларак, алар калган бар нәрсәдә үзләренә бирелгән хокуклардан тулысынча файдаланалар һәм конституциячел бурычларын үтиләр. Кеше хокуклары саклана һәм халыкара документларда беркетелә.

Белемегезне тикшерегез

1. «Гражданлык», «кеше һәм гражданлык хокуклары», «җыелыш», «митинг», «демократия» төшенчәләренең мәгънәсен билгеләгез.

2. Кеше илнең сәяси тормышында ничек итеп катнаша ала?

3. Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел бурычларына характеристика бирегез.

4. Гражданинның хокуклары һәм бурычлары үзара ничек бәйләнгән?

Практикум

1. Төрле вакытларда төрле илләрдә хакимият органнарына сайлаулар үзенчәлекле булганнар. Алар гадел узсын өчен, нинди кагыйдәләрне сакларга кирәклеген уйлагыз.

2. «Гражданин — Ватанның лаеклы улы» темасына хәбәр әзерләгез. Сүзлектән «гражданлык хисләре», «гражданлык гамәле» төшенчәләренең мәгънәсен белегез.

3. Элеккеге вакытларда «Минем катнашым юк — берни дә белмим» дигән әйтем була, ул кешенең җәмәгать эшләрендә катнашырга теләмәвен күрсәткән.
Шундый позицияне бәяләгез һәм аның нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин булуын күзаллагыз.

18. Яшүсмер һәм аның хокуклары

Баланың гражданлык (шәхси) хокуклары

Һәр кеше өчен иң мөһим һәм аерылгысыз хокук — аның *яшәүгә хокукы*. Әлбәттә, кеше бу якты дөньяга килергәме, юкмы икәнлеген берәүдән дә сорап тормый. Һәм моны тыярга берәүнең дә хакы юк, шулай ук хатын-кызга бала табуны беркем дә тыя алмый. Хокукны рөхсәт бирү яисә тыю дип аңларга кирәкми. Яшәүгә хокук ул — дәүләт, аның бөтен институтлары, учреждение һәм оешмалары системасы бала гомерен яклауга юнәлтелгән дигән сүз.

Кеше хокукы ул — нәрсә дә булса эшләү, билгеле бер гамәлләр кылу, нәрсәгә дә булса ия булу мөмкинлеге. Һәр бала бәхетле булу өчен туа. Һәм һәр балага яшәүгә, үсүгә, мәхәббәткә һәм кайгыртуга бердәй хокуклар бирелә. Хокук — ул үрнәк тәртип өчен бүләк яки нинди дә булса өстенлек түгел, ә һава һәм кояш кебек үк зарурилык. Яшәүгә хокуктан кала, кешенең, шул исәптән аңлашыла

ки, яшүсмернең дә бик күп башка хокук һәм ирекләре бар, көндәлек тормышта ул аларны исенә дә төшерми. Балага тормышны ата-анасы бирә, ә яшәү хокукын дәүләт гарантияли. Яшүсмергә яшәү өчен бик кирәкле башка хокукларны да дәүләт бирә.

1989 елда БМО кабул иткән Бала хокуклары турында конвенциядә һәр бала *үзенең әти-әнисен белергә хокуклы* диелгән. Алар бала өчен җаваплы һәм аңа нормаль яшәү шартлары тәэмин итәргә бурычлы. Башкача булырга да мөмкин түгел, дип уйласагыз бик яхшы. Ләкин еш кына әлеге хокуклар өлкәннәр, ата-ана тарафыннан бозыла.

Яшәү хокукыннан тыш, һәр кешенең шәхси тормышы да бар. Бу — дәүләтнең катышу хокукы булмаган һәм аның тарафыннан контрольдә тотылмаган өлкә. Ул гына да түгел, әлеге эшчәнлек хокук белән саклана. Кеше кем белән дус булырга, кем белән хат язышырга яисә телефоннан сөйләшергә икәнлеген үзе хәл итә.

Кешенең шәхси тормышы кебек үк торагы да кагылгысыз. Бу — фатирга анда яшәүчеләр ихтыярыннан башка керергә ярамый дигән сүз. Дөрес, кайбер очракларда — янгын чыкканда, җир тетрәгәндә, алдан күрелмәгән хәлләр булганда яки хокук тәртибен саклаганда — бу кагыйдәдән тайпылу рөхсәт ителә. Безнең ил гражданины үзенең *яшәү урынын үзе сайлый, илдә иркенләп йөри ала һәм аннан читкә дә чыгып китәргә мөмкин.*

Баланың социаль-икътисади һәм мәдәни хокуклары

Икътисади һәм социаль хокукларга *хезмәткә* һәм *һөнәрне ирекле сайлауга хокук* кертелә. Бүген күп кенә яшүсмерләр үз ата-аналарына ярдәм итәргә телиләр, гаилә алдында җаваплылык сизәләр. Моннан тыш, кесә чыгымнарына үзең дә эшләп таба алуыңны тоеп тору рәхәт ич. Мондый адымны дәүләт оешмалары булышлыгында һәм алар яклавында ясау тагын да яхшы.

Икътисади эксплуатацияләүдән яклау — яшь гражданинның иң мөһим хокукларының берсе. Дәүләтнең эшкә алу өчен минималь яшь (16) куюы һәм балигъ булмаган хезмәткәрләргә ташламалар бирүе сезгә инде мәгълүм. Законда эшсезлектән яклау чаралары да каралган.

Һәр гражданинның *ял итүгә хокукы* бар. Дәүләт аны барлык эшләүчеләргә отпуск (еллык түләүле ял) бирү юлы белән гарантияли, пансионатлар, ял йортлары булдыруны хуплый. Балачакны һәм ана булуны шулай ук дәүләт яклый. Бала тугач, ата-ананың берсенә ял бирелә, акчалата компенсация түләнә. Гражданнар сәламәтлекләрен саклауга һәм медицина ярдәме алуга хокуклы. Хәзер Россия Федерациясендә иминият медицинасы гамәлдә. Гражданнарны дәвалауны иминият компанияләре түли. Әгәр дә гражданин олы яшькә җиткән яисә хезмәткә сәләтен югалткан икән — *социаль тәэмин ителүгә хокук* үз көченә керә.

Мәдәни хокуклар — белем алу, иҗат һәм укыту иреге, мәдәни тормышта катнашу һәм мәдәни учреждениеләрдән файдалануны тәэмин итәргә тиешле хокуклар. *Белем алуга хокук* гражданин өчен бик әһәмиятле. Белем алуга хокук — бу беренче чиратта тормыш өчен кирәкле белемнәр, күнекмәләр алу мөмкинлеге. Яхшы белемгә ия булмаса кеше үзе өчен кызыклы, мөһим эш таба, уңышка ирешә алмый. Укучы балалар өчен китапханә, театр, музей ишекләре ачык булырга тиеш. Балаларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү — белем бирүдә төп максатларның берсе. Меңләгән балалар инде кече яшьтә үк ачышлар ясый, яңа

нәрсәләр уйлап таба, конкурс, фестиваль лауреатлары һәм дипломантлары була, киң танылу ала.

Хәзерге вакытта илдә «Мәгариф турында» федераль закон гамәлдә. Анда һәм башка документларда илдә белем алу тәртибе билгеләнә, ул төрле рәвешләрдә булырга мөмкин: мәктәптә, өйдә уку, экстернат рәвешендә һ. б.

Өстәмә уку

Баланың хокуклары

Кеше һәм гражданлык хокуклары балага, яшүсмергә дә турыдан-туры кагыла. Бу хакта 1989 елда Бала хокуклары турында конвенцияне кабул иткән Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль Ассамблеясында әйтелде. 1990 елда илебез планетада балаларның гомерен һәм хокукларын яклаучы әлеге халыкара документка башкару өчен имза салды һәм гражданлык, гаилә һәм хезмәт законнарында бала хокукларын беркетте.

Конвенция буенча «18 яше тулганчы һәр кеше заты» бала дип танылa. Димәк, халыкара хокук позициясеннән караганда хәзерге заман яшүсмерләрен бала итеп карарга мөмкин. Ул — кеше һәм үз дәүләтенең яшь гражданины булып тора. Бу — кешенең (өлкән кешенең) төп хокуклары балага да (ләкин төрле күләмдә һәм төрле дәрәҗәдә) кагылырга тиеш дигән сүз.

Бала хокуклары турында конвенциянең төп фикере: бала — тулы кыйммәтле шәхес. Аның үз хокуклары һәм бурычлары бар. «Начар балалар булмый!» Проблемалы балалар була, хаталанган балалар була. Ләкин олылар балаларга карата мәрхәмәтсез булырга тиеш түгел.

Өстәмә уку

Бала хокуклары турында конвенция. *Өземтәләр*

7 нче статья

1. Бала туганнан соң ук теркәлә һәм туу мизгеленнән үк исем һәм гражданлык алу хокукына ия.

9 нчы статья

1. Катнашучы дәүләтләр балаларны үз теләкләреннән башка әти-әниләреннән аерып алмауны тәэмин итәләр, моңа компетентлы органнарның, суд карары нигезендә, баланың иң яхшы ихтыяҗыннан чыгып аеру зарурлыгын билгеләү очраклары керми...

3. Катнашучы дәүләтләр ата-аналарының берсе яисә икесе белән дә аерылган баланың даими нигездә икесе белән дә шәхси һәм турыдан-туры бәйләнешләренә хокукын хөрмәт итә, баланың иң яхшы ихтыяҗыннан чыгып каршы килү очрагы моңа керми.

13 нче статья

1. Бала үз фикерен ирекле белдерү хокукына ия...

19 нчы статья

1. Катнашучы дәүләтләр баланы аңа карата физик яисә психологик көч куллану, мәсхәрәләү яисә явызларча кылану, кайгыртучанлык күрсәтмәү яисә саксыз, тупас мөгамәлә яки эксплуатацияләүнең барлык рәвешләреннән саклау максатында бөтен кирәкле чараларны күрәләр...

Йомгак ясыйбыз

Яшүсмер үз дәүләтенең гражданины булып тора, ул дәүләт Конституциясе һәм халыкара хокукый актлар белән беркетелгән аерылгысыз хокукларга ия. Безнең илдә Бала хокуклары турында халыкара конвенция гражданлык, гаилә һәм хезмәт законнарында беркетелгән.

Белемегезне тикшерегез

1. Бала хокуклары турындагы халыкара документларда бала яшенең нинди чикләре бар?

2. Параграф материалыннан файдаланып, яшүсмернең төп хокуклары исемлеген төзегез. Үз тормышыгызда кайсы законнардан чынлап файдалануыгызны санап үтегез.

Практикум

1. XX гасырда кеше, бала хокукларын яклау турында байтак мөһим документлар (шул исәптән халыкара) барлыкка килде. Сезнеңчә, бу ни белән бәйле? Әлеге хокуклар гамәлгә ашсын өчен, зурларга һәм балаларга ни эшләргә кирәк?

2. Билгеләгез, бала нинди хокукларга туганнан ук, кайсыларына 6 яшьтән 14 яшькәчә, кайсыларына 14 тән 18 яшькәчә ия:

а) ризык белән тәэмин ителүгә хокук;

б) көнкүрештә вак алыш-бирешләр башкаруга (продуктлар сатып алуга) хокук;

в) әти-әнисе белән бергә яшәүгә һәм аралашуга хокук;

г) үзенә бүләк ителгән әйберләр белән эш итүгә хокук;

д) авторлык уйлап табуына хокук;

е) акча кертемнәрен банкка салу хокукы;

ж) укудан азат вакытта эшләп алу хокукы;

з) үз керемнәре белән эш итү (әти-әнисе ризалыгыннан башка) хокукы.



§ 19. Җинаятьчел тормышның куркыныч юлы

Нәрсә ул җинаять?

Яшүсмер чак — кеше тормышындагы иң актив чордыр, мөгаен. Физик көче артуын сизгән җитлегә баручы кешегә ул инде барысын да булдыра ала кебек тоела. Ләкин тормыш тәҗрибәсе җитмәү, җинаять җаваплылыгын, законнарны белмәү, еш кына үзеңне кулда тота алмау да бик аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

Кешенең хокук тәртибен ни өчен бозуы хакында күптән уйланалар инде. Бериш белгечләр кайбер кешеләрнең тумыштан ук зарар китерү теләге була дип саныйлар, шуңа да аларны «бөтен кешедән тәмам аерып» катгый чара күрергә өндиләр. Ләкин кешеләрне җинаятьчел тормышка этәрүче сәбәпләр күптөрле: кемнеңдер ашарына булмый, һәм ул башкалардан урлый, ә икенче берәүләр җиңел генә баеп китмәкче яисә үч алмакчы була.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Җинаять — кешенең башкалар, җәмгыять, дәүләт өчен куркыныч гамәле, һәм ул җәза бирүне билгеләүче Җинаять кодексында язып куелган.

Кешеләрнең бик үк куркыныч булмаган гамәлләре **гаеп эш** дип атала. Алар өчен дә җавап бирергә кирәк.

Сезгә мәгълүм ки, кеше җинаять кылган очракта безнең илдә *җинаять җаваплылыгы*, гомуми кагыйдәләр буенча, *16 яшьтән* башлана, әмма кайбер җинаятьләр өчен *14 яшьтән* үк җавап бирергә туры килә. Соңгыларына түбәндәгеләр керә: үтерү, кеше урлау, сәламәтлеккә зыян китерү, көчләү, урлау, талау, көчләп алу, урлау максатыннан тыш, автомобиль яисә башка транспорт чараларын куып китү, мөлкәтне белә торып юк итү, террорчылык, заложник алу, террорчылык акты турында ялган хәбәр бирү, хулиганлык, вандаллык, корал, хәрби кирәк-ярак, наркотиклар, психотроп әйберләр урлау яисә куркытып алу, транспорт чараларын яраксызга чыгару.

Балигъ булмаганнарга җәза бирү төрләре

Законга мөрәҗәгать итик

РФ Җинаять кодексы. Өземтәләр

Җинаять кылган вакытта 14 яше тулган, ләкин 18 яше әле тулмаган затлар балигъ булмаганнар дип санала.

Балигъ булмаган җинаять кылучыга җәза билгеләнергә мөмкин йә аларга карата тәрбияви йогынтының мәҗбүри чаралары кулланыла ала.

Балигъ булмаганнарга билгеләнүче чаралар түбәндәгеләр:

- штраф;

• билгеле бер эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү;
• мәҗбүри эшләр;
• төзәтү эшләре;
• кулга алу;
• билгеле бер вакытка ирегеннән мәхрүм итү.

Балигъ булмаган үсмергә җәза бирелгәндә... аның тормыш һәм тәрбияләнү шартлары, психик үсеш дәрәҗәсе, шәхеснең башка үзенчәлекләре, шулай ук яшь буенча өлкән затларның аңа йогынтысы исәпкә алына.

Зур булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаятьне беренче тапкыр кылган балигъ булмаган үсмер, әгәр тәрбияви йогынтының мәҗбүри чараларын куллану юлы белән аның төзәлүенә ирешерлек булса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителергә мөмкин.

Балигъ булмаган үсмергә тәрбияви йогынтының түбәндәге мәҗбүри чаралары билгеләнергә мөмкин:
• кисәтү;
• әти-әнисе яисә аларны алыштыручы, яки махсуслашкан дәүләт органы күзәтүе астына тапшыру;
• китерелгән зыянны киметү вазифасы йөкләү;
• буш вакытын чикләү һәм балигъ булмаганның тәртибенә аерым таләпләр урнаштыру...

Кылынган җинаять өчен кеше генә җаваплылык тота. Димәк, бернинди хайван яисә җансыз әйберләр, шулай ук фирма яисә оешмалар җинаять җаваплылыгына тартылмый. Шул ук вакытта кеше ни кылганын аңларлык булырга тиеш. Кешенең гаебе җинаятьнең бер билгесе булып тора. Мәсәлән, кемдер автомашина урлап китәргә җыена. Ул әлеге гамәлнең куркыныч һәм хокукка каршы икәнен аңларга тиеш.

Тормышта күп нәрсә саксызлык аркасында да эшләнә. Тиз йөрергә өйрәнгән автомобиль йөртүче урам аркылы чыгып өлгермәгән җәяүлене таптатырга мөмкин. Бу очракта да җинаять инде кылынган һәм аның өчен җавап бирергә туры киләчәк. Кайчакта гадәти генә шаярту да куркыныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин, шуңа да, ни дә

булса эшләргә карар кылганда, моннан нәрсә килеп чыгачагын ныклап уйларга кирәк. Кемдер шаяртып, мәктәп бинасына бомба куелу турында милициягә хәбәр итә. Мондый гамәлләр кешеләргә ярдәмгә ашыгучы махсус хезмәтләрнең акчалата чыгымнар тотуына китерә. «Шаян» кешенең үзен болай тотуы җинаять ул, һәм аның өчен җавап бирергә туры киләчәк. Суд карары белән кеше ирегеннән мәхрүм ителергә мөмкин, җитмәсә ул матди зыянны да капларга бурычлы.

Гаеп эшләр алай ук куркынычлы булмаска да мөмкин, ләкин аларны кылу шулай ук тыелган, бу хакта законда да әйтелгән. Мәсәлән, җәмәгать транспортында билетсыз йөрү, урамдагы телефон-автоматларны бозу, милиционерның законлы таләбенә явызларча буйсынмау, исерек килеш җәмәгать урынында булу һ. б. Бу очракта *административ җаваплылык* барлыкка килә: штраф, махсус хокуктан (мәсәлән, автомобиль йөртү хокукыннан) мәхрүм итү һ. б.

Күп кенә җинаятьләр кешеләр төркеме тарафыннан кылына. Оешкан җинаятьчелек әнә шулай барлыкка килә. Оешкан төркем ясаган җинаять өчен катырак җәза бирелә. Җинаятьтә катнашучылар барысы да җавапка тартыла: җинаятьне оештыручы да, аны турыдан-туры башкаручы да.

Милиция хезмәткәрләре кулга алганда балигъ булмаган үсмер үз-үзен ничек тотарга тиеш

Илнең хокук саклау органнары хокук, тәртип һәм иминлек саклауны тәэмин итәргә тиеш. Шуңа бәйле рәвештә һәр кеше, шул исәптән бала да, милиция хезмәткәрләре тарафыннан аларның шәхесен ачыклау өчен кулга алынырга мөмкин. Әмма бу тоткарлау өч сәгатьтән артырга тиеш түгел. Юристлар гражданнарга үзләре белән шәхесләрен ачыклаучы документ йөртергә киңәш итә. Мәсәлән, паспорт, туу турында таныклык (әгәр әлегә паспорт алынмаган булса) яисә хәтта иминият полисы да ярый. Аларда кешенең исеме, әтисенең исеме һәм фамилиясе, ә паспортта аның тору урыны да язылган. Кешене җинаять кылу белән бәйле рәвештә яисә җинаять

кылган дип уйлап та тоткарларга мөмкиннәр. Бу хәлдә паникага бирелергә ярамый, дәүләт органнары тәртип сакларга һәм куркыныч гамәлләрне кисәтергә тиешләр. Балигъ булмаган үсмерне мондый очракларда 72 сәгатькә кадәр тоткарлау рөхсәт ителә. Законның кагыйдәләре шундый. Милиция белән очрашулар булмаска да мөмкин, шулай да түбәндәгеләрне белеп тору комачауламый:

• ни булуы хакында шунда ук әти-әниеңә, туганнарыңа хәбәр итәргә кирәк (моның өчен телефон номерлары язылган кесә кенәгәсе булу шарт);

• һәр кеше, шул исәптән бала да, яклауга хокуклы, шуңа тоткарланган вакыттан ук адвокат (үз клиентының мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклауны тормышка ашыручы юрист) чакырырга мөмкин;

• балигъ булмаганнар үзләренең законлы вәкилләре (мәсәлән, әти-әнисе) булганда гына аңлатма бирә, шуңа алар килеп җиткәнче дәшмәскә һәм үзләре турындагы мәгълүматлардан (фамилия, исем, атасының исеме, яшәү урыны) тыш берни дә сөйләмәскә була;

• кулга алганда шәхси тентү булырга мөмкин, ул чакта чит кешеләр — *пүнәтәйләр* катнашырга тиеш. Хокук саклау органнары ягыннан фальсификация, алдау булмасын өчен, кесәләрнең эчен тышка әйләндерү хәерле. Шәхси тентү вакытында беркетмә төзелә;

Рәсемдәге хәлне аңлатыгыз. Мондый чакта яшүсмергә үз-үзен ничек тотарга киңәш бирер идегез.

• тутырылмаган беркетмәгә кул куярга ярамый, соңрак аңа дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар язарга мөмкиннәр. Гомумән, аерым бер документ белән танышканда һәм милиция хезмәткәре белән сөйләшкәндә бик игътибарлы булырга кирәк. Әгәр кулга алынучы беркетмәдә язылганнар белән килешмәсә, бу хакта язып кую зарур. Документка имза салганчы, кәгазьдә язылганнар белән җентекләп танышыгыз. Россия Федерациясе Конституциясенең 51 нче статьясында: «...беркем дә үзенә каршы, тормыш иптәшенә һәм якын туганнарына каршы таныкларга бурычлы түгел...» — диелгән. Шуңа күрә бу очракта аңлатма бирмәскә дә була.

Кулга алынучы үзен тоткарлаган хезмәткәрләрнең хәрәкәтләренә шикаять белдерергә хокуклы. Әгәр бу очракта көч кулланылса, моның турында ата-анага, адвокатка әйтергә кирәк.

Юристлар, кулга алганда, үзеңне әдәпле тотарга, хокук саклау органнары хезмәткәрләренең законлы таләпләренә буйсынырга киңәш итәләр. Кешенең тыныч торышы каршы якның карашын йомшартырга сәләтле булуын истә тоту мөһим.

Балигъ булмаганнарның җинаять эшләре буенча юридик ярдәм түләүсез күрсәтелергә мөмкин.

Һәр кеше үз язмышын үзе яза һәм, җинаятьчел юлга басып, ул рухи яктан хәерчеләнә, тирә-юньдәгеләргә зыян сала һәм даими курку, нәфрәт шартларында яшәргә мәҗбүр була. Аның көченә каршы һәрвакыт башка көч табыла, ә криминал дөньясында аяусыз кагыйдәләр хөкем сөрә. Җәмгыятьтә яшәп, аның кагыйдәләрен хөрмәт итеп һәм законнарны бозмыйча, кешеләр элек-электән уңышка ирешкәннәр. «Закон катгый, ләкин ул закон»,— дигәннәр борынгы римлылар һәм закон кушканны үтәгәннәр.

Йомгак ясыйбыз

Яшүсмернең артык зур амбицияләре, үз-үзен контрольдә тотмавы аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Хокук тәртибен бозганда җавап бирергә туры киләчәк. Нинди хәл булуга да карамастан, балигъ булмаган үсмер тоткарланганда (кулга алынганда) тиешле хокуклардан файдалана.

Чит кеше хокукларын хөрмәт итсә, кеше җинаять юлына басмаячак.

Белемегезне тикшерегез

1. Кешеләр ни өчен җинаять кыла? Җинаять гаеп эштән нәрсәсе белән аерыла?

2. Балигъ булмаган үсмер кылган җинаять өчен нинди җәза каралган?

3. Аңлатып бирегез, беренче тапкыр җинаять кылган өчен яшүсмерне ни өчен җинаять җаваплылыгыннан азат итәргә мөмкиннәр?

4. «Законны белмәү җаваплылыктан азат итми» дигән фикерне ничек аңлыйсыз? Сезнеңчә, бу гаделме?

Практикум

Милиция белән очрашырга туры килсә, нинди кагыйдәләрне үтәргә кирәк?



IV бүлек

§ 20. Яшүсмер хәвефле җәмгыятьтә

Хәзерге заман җәмгыяте – яшүсмер өчен хәвефле җәмгыять

Галимнәр, хәзерге заман җәмгыятендә яшүсмергә элеккеге дәверләргә караганда зуррак куркыныч яный, дигән нәтиҗәгә килделәр. Элегрәк аның яшьтәшләренә андый куркыныч янамаган. Заманча технологияләрнең үсеше, гаять тиз йөрешле магистральләр, атом-төш электростанцияләре төзелү, техноген һәлакәтләр, экологиянең начараюы, наркомания һәм җинаятьчелекнең киң таралуы аның гомеренә адым саен куркыныч тудыра. Ләкин үсмер өчен җәмгыять кенә куркыныч чыганагы булып тормый, аның еш кына импульсив, идарәгә начар бирелүче тәртибе дә үзе һәм тирә-юньдәге кешеләр өчен хәвеф-хәтәр тудыра. Өстәвенә малайлар һәм яшь егетләр кызларга караганда

үзләрен тәвәккәлрәк тоталар. Шулай итеп, хәзерге үсмер үзенең элгәрләренә караганда куркынычларга ешрак дучар ителә.

Балаларга һәм яшүсмерләргә олыларга караганда күбрәк куркыныч яный.

Балалар һәм өлкәннәр күп төрле билгеләр белән бер-берсеннән аерылып торалар: буй, физик көч, акыл, куркыныч очракларга һәм хәвеф-хәтәргә караш, белемнәр күләме, үз хаталарыннан сабак алу сәләте, катлаулы хәлләрдә дөрес карар кабул итү осталыгы, үзләренә өстәмә җаваплылык алу омтылышы. Бу исемлекне дәвам итәргә дә мөмкин.

Яшүсмер чакта кешегә янәшәдә генә аның йорты, әти-әнисе, дуслары һәм танышлары булуын белеп тору бик мөһим. Әгәр алар булмаса, яшүсмернең даимилек, тотрыклылык тойгысы юкка чыга. Аның төп ихтыяҗларының берсе — куркынычсызлык ихтыяҗы канәгатьләндерелми. Җитлегү чорында үсмерләр олыларга караганда күбрәк куркыныч хәлләрдә кала. Бу хәлләр аларга үзләре юлыккан проблемаларны хәл итәргә сәләтлеме, юкмы икәнлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирә. Тинейджер үз тәртибен, бигрәк тә ул олы кешеләрнең үз-үзен тотышына ошаса, ялгышып, бернинди куркыныч янамаслык дип санарга мөмкин. Кайчакта алар, өлкәннәр статусына ирешү өчен, мөмкин кадәр иртәрәк җенси тормыш белән яши башларга, тәмәке тартырга, алкоголь һәм наркотиклар кулланырга гына кирәк дип саныйлар. Галимнәр болар барысы да нигезле карарлар кабул итү сәләтен кимөтә дип раслыйлар. Нәтиҗәдә яшүсмернең тәртибе тагын да куркынычрак була бара. Гаиләдәге ызгыш-талашлар, социаль үзгәрешләр, илдәге тәртипсезлекләр яисә сугышлар аркасында туганлык җепләре өзелгәндә, ул гына да түгел, дәүләттә социаль тәэминат системасы җимерелгән очракларда яшүсмерләрнең хәле тагын да начарая.

Яшүсмер чакта кеше дөньяны танып белү, шәхес формалашуның авыр юлын уза, тышкы тоткарлыклар, үзенең активлыгын чикләргә маташулар, үзенең чарасызлыгы, үз хисләрен һәм омтылышларын әйтеп бирә белмәү очракларына юлыга. Җәмгыятьтә үсмерләрнең хәле олыларны-

кыннан аерыла. Бала үз хокукларын яклау, үз мәнфәгатьләре өчен көрәшү мөмкинлекләреннән мәхрүм. Кагыйдә буларак, аның тормышы һәм үсешенә кагылган мөһим карарларны олылар кабул итә. Тинейджерлар социаль яклауга һәм өлкәннәр кайгыртучанлыгына мохтаҗ. Эшсезләр, мигрантлар, инвалидлар, картлар, ятимнәр белән бергә алар да үзләре турында мөстәкыйль кайгыртырга, тулы канлы тормыш өчен шартлар булдырырга сәләтсез төркемнәр составына керәләр.

Шулай итеп, яшүсмер күп санлы һәм еш кына аның өчен көтелмәгән куркынычлар чолганышында яши.

Хәзерге заман яшүсмерләре тормышындагы куркынычларның чыганаклары

Куркыныч чыганакларның берсе *шау-шу* белән бәйле. Ул тирә-юньдәге дөньядан да, яшүсмерләрнең үзләреннән дә чыга. Рок-музыка мөһим, ләкин бердәнбер югары тавыш чыганагы түгел. Образлы әйткәндә, тинейджерлар — халыкның иң шау-шулы яшьтәгеләр төркеме. Алар карамагына заманча электроника биргән хәзерге җәмгыять — кешелек тарихында иң тавышлысы. Хәзерге заманда тавыш безне иртәдән кичкә кадәр озата бара.

Стадионда булу куркыныч чарага әверелмәсен өчен, үз-үзеңне тоту кагыйдәләренең кайсыларын үтәргә кирәк?

Тавыш фоны — шәһәр тормышы билгесе. Өйдә тузан суырткыч, сок сыккыч гүелди, урамда моторлар үкерә, кибет һәм кафеларда музыка яңгырый. Хәзерге заман яшьләрен музыкадан башка күз алдына да китереп булмый. Музыка тулы миниатюр плеерларны сәгать урынына беләккә тагып йөреп була. Ләкин каты тавыш безнең исәнлеккә нинди йогынты ясавы хакында уйланабызмы соң без? Табиблар кисәткәнчә, теләсә нинди озакка сузылган тавыш ишетү сәләтенең югала баруына китерә. Тавышның кешеләрнең вакытыннан элек картаюына китерүен раслаучы тикшеренүләр дә бар. Барлык медицина казанышларына һәм профилактика чараларына карамастан, ишетү сәләтен өлешчә югалткан пациентлар саны арта бара. Дискотекада, рок-концертларда яисә өйдә яшь кеше шундый күләмдә децибеллар ала ки, аларда вакытыннан алда картлык саңгыраулыгы билгеләре пәйда була. Әлбәттә, ишетү проблемасы алар өстенлек биргән музыка стиленә түгел, тавышның көченә бәйле.

Югары тавыш стресс халәтенә китерә, канга артык күләмдә адреналин керә, ә ул исә аңга наркотиктай тәэсир итә. Шуңа да публика рок-концерт һәм дискотекада үз-үзенә контрольне югалта. Гомумән, тәм сизүгә караганда ишетү сәләте күпкә сизгеррәк, чөнки колак белән баш мие арасында турыдан-туры элемтә бар. 20—30 яшьтә шундый проблемалар булсын дисәң, дискотекада еш булу һәм мотор тавышын киметү җайланмасы булмаган мотоциклда йөрү дә җитә.

Табиблар дискотекада яисә рок-концертта көчәйткечләрдән ераграк торырга, колакны тавыштан саклау өчен, махсус бөкеләр кулланырга киңәш итәләр. Сүз арасында әйткәндә, күпчелек рок-музыкантларның колагында шундый бөкеләр.

Шәһәр юллары — шулай ук куркыныч чыганаклары. Ел саен яшүсмерләр дачаларда һәм лагерьларда җәйге ялдан кызынып һәм ял итеп кенә түгел, гомумән, шәһәр тормышыннан, аерым алганда, юллардагы интенсив хәрәкәттән бизеп кайталар. Аларның игътибары кими — яңа тормыш ритмына ияләшергә өлгермиләр. Статистика

Истә калдырырга киңәш итәбез

Алкоголизм — авыр хроник авыру, кешенең алкогольгә бәйлелеге.
Наркомания — авыру, кешенең наркотикларга бәйлелеге.
Сәламәтлек — организмның нормаль эшчәнлеге, аның тулы физик һәм психик иминлеге.

буенча юл-транспорт һәлакәтләренең нәкъ менә шушы чорга туры килүе очраклы түгел. Зарар күрүчеләрнең якынча өчтән икесе — урта һәм өлкән сыйныф укучылары. 10—15 яшьлек үсмерләр үзләрен, светофорга һәм юл тамгаларына игътибар итү өчен, артык өлкән дип саныйлар. Хәзер модадагы скейтборд һәм роликлы конькилар шулай ук юлдагы вазгыятьне яхшыртмый. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, юлларда иң зур куркынычны нәкъ менә тинейджерлар тудыра.

Төрле илләрдә балалар (алардан яклау зарур булган) төрле куркынычларга дучар булалар — болар *телевидение тапшырулары карауның* тискәре нәтиҗәләре (соңгы 20 елда АКШта уздырылган меңнән артык җитди тикшеренү күрсәткәнчә, балалар экрандагы рәхимсез гамәлләрне тормышта да кабатларга яраталар). Япониядә төп куркынычны тәрбиянең традицион ысуллары җимерелүдә һәм Көнбатыш гадәтләре һәм үз-үзеңне тоту рәвеше һаман күбрәк үтеп керүдә күрәләр.

Яшүсмер гомере өчен *наркотиклар* чиксез зур куркыныч тудыра. Бала хокуклары турында конвенциядә балигъ булмаганнарны наркоманиядән яклауга аеруча зур әһәмият бирелә. Иң куркынычы — җүләрләндерә торган агуга балачактан ук күнегә башлыйлар.

Редакциягә хат

Полихимик төшләр

Наркотиклар — бары тик химик матдәләр генә ул. Күп тә түгел, аз да түгел, мәгълүм бер молекула һәм атомнар җыелмасы. Минемчә, проблема аларда түгел, ә кешенең үзендә. Әфьюн, гашиш, марихуана, экстази, героин һәм башкалар... Проблема шунда ки, аларны кулланалар, наркотиклардан бәйле балалар һәм үсмерләр бар.

Наркоман үзен үзе аңламый. Артык зур доза иң куркынычы түгел. Минем өчен иң куркынычы — котылгысыз рәвештә әкрен-әкрен, ихтыярның, акылның, тәннең түбәнсетелүе, шәхес бөтенлегенең җимерелүе. Һәм тагын җимерү-ватуга сусау, авырттыру, барлык кешеләр һәм дөнья өстеннән хакимлек тою теләге.

Наркотиклар — үлем түгел, ә мәгънәсез ялган. Тынычлык эзлисең, ә неврастения, психопатологияләр аласың. Ирек эзлисең — коллык табасың! Үзеңне эзлисең — үзеңне югалтасың. Наркотик — баштан ук ихтыярсыз, зәгыйфь кешеләр юлы. Алдау, аттракцион, ул син гөнаһлыны һаман көчлерәк суырып ала бара. Химик төшләр, алар тиз арада коточкыч бастырылуга әверелә...

Мин уяндым. Син дә уян: нигә дөньяны химик ысул белән үлчәргә?

Ира Вернанская, Глазов шәһәре, «Авось-КА» газетасы

Йомгак ясыйбыз

Хәзерге заманда кеше гомере һәм сәламәтлегенә даими куркыныч янап тора. Яшүсмер техник прогресс казанышлары йогынтысында үсә, ә алар һәрвакытта да уңай түгел. Телевидение, юллардагы куркынычлар, тавыш, шау-шу йогынтысында стресслар һәм иң куркынычы — балаларны да аямаучы наркомания һәм алкоголизм. Һәр олы кешенең бурычы — яшүсмер өчен хәвеф-хәтәрләрне мөмкин кадәр булдырмау.

Белемегезне тикшерегез

1. Хәзерге заман җәмгыятен ни өчен хәвефле җәмгыять дип атарга була?

2. Хәзерге җәмгыятьтә булган төп куркынычлардан котылу өчен нинди тәртип кагыйдәләрен сакларга кирәк?

3. «Тәвәккәллек — игелекле эш» дигән әйтемне ничек аңлыйсыз? Теләсә нинди тәвәккәллекне дә аклап буламы, әллә юкмы? Мисаллар китерегез.

4. Ни өчен нәкъ менә яшүсмерләр җәмгыятьтә «иң югары дәрәҗәдә куркыныч янаган төркем» булып санала? Яшүсмерне тәмәке, алкоголь, наркотиклар куллана башлауга нәрсә этәрә?

Практикум

1. Педагоглар яшүсмер чакта үз проблемаларын хәл итәргә өйрәнгән балага алдагы тормышында, мондый сынауларны узмаган балага караганда, куркынычлар азрак яный дип саныйлар. Шуңа да алар ата-аналарга яшүсмерләрне нинди кыенлыкларга күнектерү зарурлыгы турында киңәшләр бирәләр, моны ничек эшләргә икәнен өйрәтәләр.
Яшүсмерләр үзләре дә хәл итә алырдай кыенлыклар исемлеген төзеп карагыз.

2. «Безнең шәһәрдә куркыныч чыганаклары», «Безнең шәһәрдә, районда, авылда законлылыкның һәм хокук тәртибенең торышы» дигән темаларның берсенә хәбәр әзерләгез.

21. Ялгызлык проблемасы

Ялгызлык

Яшүсмерләрнең тиз үзгәрүчәнлеге, нерв авырулары, ярсучанлык еш кына алар организмында барган көчле үзгәрешләр нәтиҗәсе булып тора. Бу яшьтә кеше бик сизгер һәм нечкә күңелле. Яшүсмерләр үз гаиләләрендәге проблемаларны чит кешеләрдән яшерергә тырышалар, шуның нәтиҗәсе буларак үзләренә сыенып урын таба алмыйлар, олыларга кирәксезлекләрен тоялар һәм «үз тормышлары» белән яши башлыйлар.

Мәктәптәге психологларга хәзер үзләренең инде беркемгә дә: мәктәпкә дә, әти-әниләренә дә, җәмгыятькә дә кирәк булмавына инанган үсмерләр мөрәҗәгать итә. Барлык гадәттәге үлчәмнәр буенча хәтта шактый уңышлы яшәүчеләр дә үзләрен ташланган итеп тоялар.

Психологлар күзәтүе буенча малайларда курку һәм

шуннан саклану агрессивлыгы, ә кызларда ялгызлык, читләшкәнлек хисе ешрак күзәтелә.

Ялгызлык — кайвакыт дуслык мөнәсәбәте булдыруга омтылыш белән бәйле көчле тынгысызлык һәм киеренкелек хисе. Ялгыз кешеләр үзләрен кирәксез, кызыксыз, бернәрсә дә белмәүче һәм мәхәббәтсез итеп тоя. Ялгызлык шәхесне бик нык какшатырга һәм тирән үзгәрешләргә китерергә мөмкин. Кайбер яшүсмерләрдә ялгызлык хисе гаиләсез калу яисә дуслыкка, мәхәббәткә ышанычны югалту белән ассоциацияләнә. Сезне иң якын дустыгыз саткан яисә яраткан кешегез хыянәт иткән халәттә кайчакта дуслыктан, гомумән, мәхәббәттән читләшү башлана, ә барлык кызлар һәм егетләр потенциаль хыянәтче буларак кабул ителә. Сез ирләрчә дуслыкка һәм хатын-кыз мәхәббәтенә башка ышанмыйсыз. Күпмедер вакыт сез яңа кешеләр белән дуслашмыйсыз. Үзегезне бөтен бер төркемнән һәм хисләр даирәсеннән мәхрүм итәсез.

Ялгызлыкны өйрәнүнең тарихи эволюциясен чагыштырып, беркадәр көтелмәгәнрәк нәтиҗә ясарга мөмкин. Планетабызда кеше күбрәк була барган саен, без дөнья җәмгыяте һәм планета бергәлеге турында ешрак сөйләгән саен, кеше үзенең ялгызлыгын кискенрәк тоя, шәхеснең җәмгыятьтән аерылып чыгу һәм үзенең берәүгә дә охшамаганлыгын төшенү ихтыяҗы зуррак була. Бу нәрсә — төркем эчендәге ялгызлыкмы, үзе кебекләр арасында югалып калмау теләгеме яисә шәхси әһәмиятлелекнең, үз-үзеңә бәя бирүнең һәм үз мөмкинлекләреңне эшкә ашыру ихтыяҗының котылгысыз үсешеме?

Без үзебезне очсыз-кырыйсыз Галәмдә һаман саен ешрак тузан бөртеге итеп сизәбез. Шундый бөртекләр күбрәк булган саен, ялгызлык хисе көчлерәк. Төркемдә, вокзалда яисә синең тирәңдә таныш булмаган кешеләрнең биниһая зур массасы кучеп йөргән шәһәр урамында бер үк вакытта үзеңнең югалганлыгыңны һәм ялгызлыгыңны тоясың. Ялгызлык бит ул — безне башкаларның аңламавы, дусларга бәйләнешләр булмау, ятсыну һәм читсенү халәте. Хәзерге заман мегаполислары мәңге ашыгучы, бар нәрсәгә битараф, ни белән булса да мәшгуль тере затларның гигант кырмыска оясын гына хәтерләтеп калмый, ялгыз төркем

дә булып тора. Әгәр сезнең күпмедер вакытка ялгыз каласыгыз килә икән, төркемгә барыгыз, дигән кемдер.

Тәүге ялгызлык яшь чагында килә. Балигъ булган кешенең шәхси «мине» ныгыган була, психикасын башка кичерешләргә күчерү һәм чынбарлыкка көчлерәк берегү мөмкинлекләре зуррак була. Үсеп җиткәч, кеше эш белән шөгыльләнә: аның бәйләнешләре күп һәм ул башка кешеләр белән үзара актив хезмәттәшлек итә, һәм шуның нәтиҗәсе буларак элемтәләре тирән түгел һәм эмоциональ бәйлелеге кимрәк.

Кызыклы фактлар

Кем үзен ялгыз хис итә

- шифаханәдә ятучы авыруларның 50 % ы чамасы ялгызлыктан интегүләрен әйттеләр;
- өйләнмәгәннәр өйләнгәннәргә караганда ялгызлыкны ешрак кичерәләр, ә элек өйләнеп хәзер үзләре генә калганнар тагын да ялгызрак;
- үзләрен ялгыз дип санаучылар ир-атка караганда хатын-кызлар арасында күбрәк;
- матди мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында ялгызлык дәрәҗәсе югарырак;
- ялгызлык өлкәнрәк яшьтәгеләргә караганда яшь чакта киңрәк тарала һәм яшьләр арасында көчлерәк сизелә;
- өлкән яшьтә аерылышкан һәм тол калган кешеләр шундый ук хәлгә калган яшьләргә караганда үзләрен ялгыз дип азрак саныйлар;
- якыннарын югалткан кешеләрнең ялгызлыкны тою куркынычы көчлерәк.

Сүз арасында әйтеп китик, ялгызлыкның уңай яклары да бар, ул — үзең генә калуга омтылыш. Яшүсмернең берүзе генә калу, эчендә ниләр бару турында утырып уйлау

мөмкинлеге булмаса, ул уңайсызлык сизә. Шуңа күрә ялгызлыкка сак карашта булырга һәм мәгълүм бер дәрәҗәдә үзеңне аның белән тәэмин итәргә дә кирәк. Ялгызлык — катлаулы күренеш, төрле кешеләр арасында төрлечә кабул ителә. Берәү өчен ул — югалган мәхәббәт яисә якын дусны сагыну, икенчесе өчен — аралашу булмау аркасында туган күңелсезлек хисе, өченчеләр өчен ул гомуми читләшүнең бер өлешен, үзеңнең заманага туры килмәвеңне тоюны тәшкил итә.

Ялгызлык хисе — күчү яшенең мәңгелек кичерешләре категориясеннән. Л. Толстой китапларын, аның кызы Т. Сухотина-Толстая көндәлекләрен генә кулга алу да җитә. Кеше җанын тирән белүче әдипнең яраткан кызы үзенең үсмерлек чорын авыр кичерә. «Әле утырып та җитмәгән аңыма,— дип яза ул үзенең истәлекләрендә,— бер ялгызым калып яшәү һәм үлем мәсьәләләрен, дингә, Ватанга, ир һәм кыз туганнарыма, хезмәтчеләргә мөнәсәбәтне, акча, сәнгать мәсьәләләрен, төрле җенестәге кешеләр мөнәсәбәтен... ачыкларга туры килде. Башкалар тәҗрибәсе миңа кирәк түгел иде...»

Яшүсмерләргә башка кешеләр белән кайчандыр булган хәлләр аларга кагылмый, үз кичерешләре уникаль булып тоела. Ялгызлык еш кына кеше үзен беркемгә дә кирәкми яисә ул кайгыртырлык кеше юк дип санаганда барлыкка килә. Башкаларга кирәкле булу, кем турындадыр кайгырту, аның язмышында катнашу һәм кайгысын уртаклашу — ялгызлыктан чыгуның иң яхшы юлы. Үзеңнең горурлык хисеңне, иминлек тойгысын, кемгәдер бәйлелекне һ. б.ны көчәйтү ялгызлык хисен киметүнең көчле чарасы булырга мөмкин. Ялгызлык һәм депрессия (төшенкелек, изелгәнлек) — мәсьәләнең ике ягы. Тегесе дә, бусы да яшүсмерне сагалап кына тора. Озакка сузылган ялгызлык яисә аралашуда кабат уңышсызлыкка дучар булу үзеңне үзең гаепләүгә һәм, ниһаять, депрессиягә илтә.

Яшүсмерләр депрессиясе ничек була соң? Аңа начар йоклау, аппетит булмау, даими төстә физик яктан сәламәт булмауны сизеп тору, сүнгән күзләр, салынган канатлар юлдаш. Башкача да булырга мөмкин, әйтик, ярсучанлык, кычкырыну, тик торганнан кызып китү. Әгәр яшүсмер

берничә атна дәвамында тотрыклы рәвештә сагышлы (яисә ярсулы, елак) халәттә була, һаман үзеннән-үзе риза түгел, берничек тә аралашырга теләми, укуда элек булмаган кыенлыкларга юлыга һәм тиз арый, аңа башка вакытта канәгатьләнү биргән нәрсәгә шатланмый, нормаль йоклау һәм ашау сәләтен югалта, тәнендә гадәттә булмаган җайсыз үзгәрешләр тоя икән — бу, мөгаен, депрессиядер.

Мондый халәт нидән барлыкка килүен уйларга һәм, һичшиксез, аннан чыгу юлын табарга кирәк.

Яшүсмерләр депрессиясе проблемаларын хәл итү өчен берничә гади киңәш

1. Булган нәрсәңне бәяли һәм аның тәмен таба белергә өйрәнү зарур.

2. Һаман саен проблемалар турында уйлап йөрмә, бүгенге көннең гади генә сөенечләрен күрә бел. Бәхет — чынбарлык ул. Ул без хәзер булган җирдә. Бу табигать, якыннарыбыз һәм дусларыбыз. «Яшә генә, күкрәгең тутырып сула, бу мизгелнең рәхәтен монда һәм хәзер күреп кал!»

3. Көзгегә карап лимон аша. Кыяфәтеңне күреп көлми кала алмассың дип уйлыйбыз.

4. Ешрак елмай. Мимик мускуллар баш миенә сиңа күңелле булуы хакында сигналлар җибәрә башлар һәм ми күңелле халәткә җайлашыр дип санала.

5. Тормышчан итеп киен һәм исеңдә тот: кара кием кимә.

6. Спорт. Физик яктан актив булсаң, сагышланырга вакыт калмый. Спорт белән төркемдә йә видеокассета ярдәмендә өйдә шөгыльләнергә мөмкин.

7. Йокы. Аны, кәеф кебек үк, якларга һәм сакларга кирәк. Һәр көнне 22.00 сәгатьтә ятсаң, режим бик нык ярдәм итә. Йокының дошманы — тынгысызлык. Йоклар алдыннан җылы сулы ваннада ятып торсаң, начар булмас.

8. Оптимистик рухтагы китаплар, фильмнар, музыка.

9. Туклану. «Ризык» дигән сүз генә дә оптимизм бирергә тиеш.

10. Йорт хайваннары — аеруча нәтиҗәле чара. Бу җан ияләре тормышка аерым мәгънә бирә, аны ярату хисе

тудыра, җаваплылык хисе тәрбияли, режимга өйрәтә, уйларыңны били.

11. Хезмәт терапиясе. Гомумән алганда әлеге ысул иң яхшысы булыр иде, чөнки ул кешене били һәм аның проблемаларын хәл итә. Тормышта авыр хәлдә калган кешеләрнең бөтен көчләрен эшкә бирүләре һәм, нәтиҗәдә матди байлыклар гына туплап калмыйча, үз-үзләренә һәм иртәгәсе көнгә ышаныч та табуларын күрергә мөмкин. Еш кына рухи газаплар иҗат өчен бай материал бирәләр. Кызыклы китап язу яисә... һичюгы берәр рәсем ясау мөмкинлеге бар.

«Бәхетле булырга теләсәң — бул». «Тормышны ничек ясасаң, ул шулай була да».

Күңел тынычлыгы, позитив, рухи ныклык, шатлыклар һәм тормыш авырлыкларын җиңүнең гармонияле берлеге, тормышчан башлангычка йөз тоту — бәхетле яшәү рецепты менә шулдыр.

Йомгак ясыйбыз

Хәзерге дөньяда төрле төркемнәрдә даими рәвештә мәҗбүри аралашу барганда ялгыз булу ихтималы аз. Еш кына уй-фикерләрне туплау, хәлне анализлау, аралашудан ял итү һ. б. өчен үзең генә калу да таләп ителә. Әгәр дә яшүсмер үзен ялгыз хис итә икән, мондый халәт төрле сәбәпләр: депрессия, якын кешене югалту, гаиләдәге каршылыклар, яшьтәшләр даирәсендә аңлашмау һ. б. аркасында килеп чыгарга мөмкин. Бу вакытлы хәл, аның белән көрәшергә мөмкин һәм кирәк.

Белемегезне тикшерегез

1. Ялгызлыкның нәрсә икәнлеген сез ничек билгеләр идегез?

2. Коллективта, компаниядә ялгыз булырга мөмкинме?

3. «Яшүсмер үзен шул чакта ялгыз итеп тоя, кайчан...» дигән фразаны дәвам итегез.

Практикум

Бер җырда мондый юллар бар: «...Ялгызлык ул гүзәл нәрсә...» Сез ничек уйлыйсыз, нинди ялгызлыкны кеше өчен кирәкле дип санарга була? Ни өчен? Яисә андый очраклар булмыйммы?

Яшүсмер ялгызлыгы сәбәпләрен санап үтегез. Бу халәттән ничек чыгарга?



§ 22. Яшүсмерләр культурасы

Яшүсмерләр культурасы үзенчәлекләре

Яшүсмерләр җәмгыяте — барлык яшь кешеләрне үз эченә алган бердәм, бар нәрсәне колачлаучы, монолит структура түгел ул. Яше, җенесе, матди яктан тәэмин ителеше, милли составы буенча аерылып торган байтак яшүсмерләр җәмгыятьләре булуы мәгълүм. Яшүсмерләр җәмгыятьләрен *формаль* (нигездә мәктәптәге) һәм *формаль булмаган* (мәктәптән тыш) *төркемнәргә* бүлеп карарга мөмкин.

Күп кенә бергәлекләр, кагыйдә буларак, озак яшәмиләр, алар беркайда да теркәлмәгән, аларның уставы һәм формаль хакимият органнары юк, шуңа аларны формаль булмаган җәмгыять дип атыйлар. Мәсәлән, торак урыны буенча компанияләр шундыйлардан.

Башкалары, ниндидер мөһим иҗтимагый максатка ирешү өчен, өлкәннәр катнашында төзелгән, теркәлгән,

аларның уставлары бар, үзләре нинди дә булса учреждениеләр яисә оешмалар структурасына кертелгән. Формаль җәмгыятьләр — бу, мәсәлән, клублар, спорт секцияләре, театр һәм предметлар буенча түгәрәкләр.

Формаль яшүсмер җәмгыятьләренә нигездә бер сыйныф яисә бер мәктәп укучылары төркемнәре кертелә. Мондый җәмгыятьләрдә яшьтәшләр арасындагы элемтәләр үсмерләрнең мәктәпкә йөрү-йөрмәүләре белән билгеләнә (әгәр йөрсәләр, ниндигә). Мәктәпне тәмамлагач та, алар үз мәктәпләре һәм сыйныфлары патриоты булып калалар. Җирле (мәктәп, сыйныф) патриотлык бигрәк тә мәктәбара һәм сыйныфара конкурсларда, ярышларда (олимпиадаларда), мәктәп концертларында һәм кичәләрендә аеруча көчле чагылыш таба һәм үсә, аларда яшүсмерләр үзләренекеләрнең уңышын телиләр. Мәктәптәге дуслар арасында бик күп нәрсә: дин, әти-әниләренең һөнәре һәм белеме, үзләре өчен кызыклы ял, укуга мөнәсәбәт уртак булырга мөмкин.

Өлкәннәрнең бер ишесе яшүсмерләрнең үз культурасы бар дип саный, ә икенчеләре яшүсмерләр культурасы өлкәннәр культурасының чагылышы гына дип уйлый. Чынлыкта исә тегеләре дә, болары да хаклы.

Яшүсмерләр *үз телләрендә, үз модалары белән* һәм, иң мөһиме, *үз кыйммәтләр системасы булган культура* булдыралар, ул өлкәннәрнең кыйммәтләр системасыннан аерылып торырга мөмкин. Бу культура яшьтәшләрнең үзләре арасында хуплана, ә менә олылар аны һәрчакта да хупламый. Яшьләр культурасын формалаштыруга үсмерләрнең яшь үзенчәлекләре: яңалыкка, иҗатка тартылу, бәйсезлеккә омтылу, башкаларга охшамаска тырышу да йогынты ясый. Бер-берсеннән үз мәнфәгатьләре, ка-

Истә калдырырга киңәш итәбез

Яшьләр культурасы — бу милләт культурасының яшьләр кебек социаль төркемгә хас бер өлеше.

рашлары, тормыш рәвешләре, ялны үткәрү формалары, киемнәре һәм төрле символикалары белән аерылып торган күп санлы яшүсмер берләшмәләре әлеге культураны иҗат итүчеләр булып торалар.

Яшүсмерләр культурасын әлеге яшьтәгеләрне характерлаган кыйммәтләр, карашлар һәм үз-үзеңне тоту типлары аша чагылдырырга мөмкин, шулай ук яшьләр сатып алган яисә үз куллары белән ясаган әйберләрне көндәлек тормышта кулланып карарга да була.

Психологлар фикере...

Өлкәннәр, үз яшьтәшләре, кинофильм геройлары гамәлләрен кабатларга тырышу мәктәп балаларының мөһим үзенчәлеге булып тора. Бу сыйфат балаларга укуда нык ярдәм итә һәм осталыкны, күнекмәләрне тиз үзләштерергә булыша.

Яшүсмердә абстракт фикер йөртү сәләте елданел арта бара. Шул ук вакытта күрсәтмәле, образлы фикерләү дә юкка чыкмый, ә саклана һәм үсә (мәсәлән, аныклау сәләте, сурәтләү, төшенчәләрнең асылын анык образларда һәм күзаллауларда ачып бирү сәләте үсә бара).

Яшьләр киеме

Яшүсмерләр культурасының төп матди үзенчәлеген тәшкил иткән яшьләр киемен карап узыйк. Болай эшләү аның яшүсмерләр тормышындагы әһәмияте белән билгеләнә. Яшьләрне халыкның башка төркемнәреннән аерып торган сыйфат күзгә ташлана. Бу — киемгә, чәч йөртүгә һәм үз-үзеңне карап, тәрбияләп йөртүгә бик зур игътибар бирү. Күзгә ташланган һәм еш кына каршылыклы хисләр тудырган кием яшүсмерләргә үз характерларын, дөньяга карашларын ачарга һәм чагылдырырга, индивидуаль сыйфатларын ачык күрсәтергә ярдәм итә.

Тышкы кыяфәт белән эксперимент — кызлар һәм егетләр үзләрен уңайлы хис иткән образны эзләү процессының бер өлеше. Кызыктырырлык яисә, киресенчә, тыйнак кием аша үсмерләр әйләнә-тирәдәгеләргә ясаган тәэсирләр белән

идарә итәргә омтылалар. Кием ярдәмендә янәшәдәгеләргә яшүсмернең тормышта нинди роль уйнарга теләве хакында хәбәр итәргә мөмкин. Кием-салым сатып алганда, үсмер танылырга яисә яшьтәшләре компаниясенә керергә мөмкинлек бирә торганын сайлый.

Яшүсмерләрдә һәм өлкәннәрдә кием төрле функцияләр үти. Олы кеше бөтенләй модадан чыккан пальто кияргә мөмкин, ул җылы һәм уңайлы гына булсын. Өлкәннәр башлыча гамәлгә ярашлы кием кияләр, ул, әлбәттә, җәмгыятьтә кабул ителгән критерийларга җавап бирергә тиеш. Ләкин яшүсмернең нәфасәте башка: әгәр дә модасы килсә, ул өр-яңа джинсыны кискәләргә, буярга, таушалдырырга мөмкин, җылылык ягы да аның өчен беренче урында тормый. Әлбәттә, өлкәннәрне дә киемнәренә карап бәялиләр. Профессор, әгәр абруен җуярга теләмәсә, студентлар аудиториясенә эш комбинезоны киеп керми. Шулай да өлкәннәр өчен кием үзмаксат түгел. Үз төркемнәрендә кабул итсеннәр өчен, аларга модалы һәм күзгә ташланырлык итеп киенү мәҗбүри түгел. Бөек физик А. Эйнштейн Принстонда лекция укырга шәрә тәнгә күн куртка, йомарланып беткән чалбар киеп килгән. Ләкин ул бит бөек Эйнштейн булган. Аудитория сәер профессорны изгедәй кабул иткән. Бүген дә МДУның күп кенә профессорлары студентларына караганда күпкә гади киенәләр. Ләкин профессор статусы аның белеме һәм һөнәри осталыгы белән билгеләнә.

Яшьләр музыкасы

Музыка яшүсмерләр культурасының икенче бер мөһим өлеше булып тора. Популяр музыканың күп төрле стильләре бар: поп, ритм-энд-блюз, рэп, фолк, регги, техно, джаз һәм рок. Мәхәббәт турында баллада иң киң таралганнардан санала, җырларда көнкүреш һәм социаль тормыш проблемалары күтәрелә. Хәзерге заман музыкасында иң каршылыклы һәм бәхәсле жанр — авыр рок яисә хеви-метал. Бу юнәлеш тыңлаучыларны эчтәлеге һәм музыкаль формасы белән шаккатыра. Олыларның күбесе балаларның мондый музыка тыңлавына каршы. Хәзерге вакытта яшьләр музыкасы замана җәмгыятенә протест һәм аңа чакыру ташлау булып яңгырый.

Роллерлар

Роликларда йөрүне америкалылар уйлап таба, ә соңрак эстафетаны Россия укучылары кабул итә. 10 еллар элек зур шәһәр урамында очраган «тимераяклы» сәер кеше беркадәр гаҗәпсенү тудыра иде. Мәскәү һәм Санкт-Петербургта азмы-күпме оешкан роллерларның саны ул вакытта йөздән артмагандыр. Бүген алар меңәрләп. Үз традицияләре һәм культуралары белән роллерлар хәрәкәте барлыкка килде, һәм ул киңәя бара.

1992 елда «Кока-кола» компаниясе ярдәме белән Россиядә беренче ролик спорты федерациясе төзелде: роликларда йөрү һаман саен модалы һәм абруйлы була бара. Ә массакүләм мавыгу 1996 елдан башлана.

Роллеризм бу сыдырылган терсәк һәм тезләр генә түгел, аларга иялəшеп була. Ул әле бик зур дозалы адреналин, трюкларны башкару шатлыгы, осталык, горурлык та. Моннан тыш, кызыклы кешеләр белән очрашу. Кеше ишегалдында йөренеп туйса, аны Интернет турындагы виртуаль сөйләшүләр ялыктырса, ул роликларын кия һәм күңелле очрашуга китә. Монда дусларча атмосфера, уртак мәнфәгатьләр, киеренкелектән котылу мөмкинлеге. Акрын һәм күңелсез ритмлы бер үк төрле көндәлек тормыш тинейджерның хәрәкәтчән натурасын канәгатьләндерми. Ә роликлар — ул тизлек, романтика, көчле хистойгылар. Роликта кеше җәяүледән биш тапкыр тизрәк хәрәкәтләнә.

Кызганычка каршы, роликлар белән артык мавыгу күңелсез нәтиҗәләргә дә китерергә мөмкин. Сүз аның тормыш өчен куркынычлы булуы, аяк-кулны сындыру мөмкинлеге турында гына бармый. Роликлар белән чамадан тыш мавыгу укуны артта калдыра, соңрак исә һөнәр алуга да комачаулый.

Роллеризм — ул үзенең теле (сленг), киеме, йөрү техникасы, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, кушаматы (әйтик, Таблетыч, Кайф яисә Экстремало-Психо-Камикадзе), бөтенроссия һәм халыкара ярышлары, бәйрәмнәре, роллер-вакыйгалары, роллер-баллары, тусовкалары (мәсәлән, Липецк роллерлар тусовкасы), роллердромнары, скейт-парклары, роллер-командалары, оешмалары һәм ассоциацияләре,

Интернетта сайтлары, журналлары һәм видеожурналлары (аерым алганда, Los Cretinos) һ. б. булган аерым яшәү рәвеше һәм аерым субкультура ул.

Роллерның шактый киң таралган киеме — торбасыман джинсы, хәрби ыштан, гаҗәеп чобар футболка, баш түбәсенә каплап куйган велосипед шлемы. Башка вариант — калфак, киң ыштан яисә шорты, шулар аркасында роллерларны рэпперлар дип беләләр. Киемнән тыш, яхшы саклагычлар -- терсәккә, тезгә бәйли торган әйберләр һәм шлем булдырырга кирәк.

Психологлар фикере...

Яшүсмергә тәнкыйди фикер йөртү хас. Ул укытучы яисә дәреслек абруена гына ышанып тормый, үз фикерен, үз карашларын булдырырга һәм үзенчә уйларга тырыша. Аны актив рәвештә, бәйсез, иҗади фикер йөртергә омтылыш аерып тора. Шуңа яшүсмергә күп төрле объектларны мөстәкыйль чагыштыру, аларда охшашлыклар һәм аерымлыклар табу, гомумиләштерү һәм нәтиҗә ясау мөмкинлеге бирергә кирәк.

Йомгак ясыйбыз

Тәҗрибә һәм хаталар тулы күчеш чорында яшүсмер эзләнү процессы кичерә. Музыкада, киемдә, үз-үзен тоту манерасында оригинальлеккә, яңага омтылу аның үз-үзен табу ихтыяҗы белән билгеләнә. Вакытлар узу белән, кыйммәтләр яңадан карала. Анык факторлар, социаль хәл һәм җитлегә бару йогынтысы астында мәгълүм бер өстенлекләр, үз-үзеңне тоту рәвеше, зәвык һ. б. эшләнә.

Белемегезне тикшерегез

1. Яшүсмерләр җәмгыяте һәм культурасы уникаль һәм өлкәннәр җәмгыятеннән һәм культурасыннан аерылып тора дип расларга мөмкинме? Җавабыгызны аңлатыгыз.

2. Яшүсмерләр һәм өлкәннәр культурасын чагыштырыгыз. Чагыштыру критерийларын билгеләгез.

3. Кием-салым яшүсмерләр өчен, чыннан да, бу параграфта расланганча зур әһәмияткә ияме? Җавабыгызны дәлилләгез.

4. Яшүсмер культурасында музыка нинди урын тота? Ни өчен?

Практикум

1. Хәзерге заман яшүсмерләре культурасын чагылдырган символ-әйберләр исемлеген төзергә тырышыгыз.

2. Классташларыгыз арасында сорашып-белешү үткәрегез: «Хәзерге заман музыкасында нәрсә ошый һәм нәрсә ошамый?»

3. Кайбер Америка социологлары белдергәнчә, рус яшүсмерләренең холкы ныклырак һәм аларга эчке тотнаклык хас. Америка яшүсмерләре — матди яктан бозылган социаль төркем.
Ләкин барлык галимнәр дә алар белән килешми. Кайбер рус социологлары, киресенчә, американыларның холкы нык һәм аларда эчке тотнаклык бар, ә Россия яшүсмерләрендә андый нәрсәләр юк дип саный. Алар авыр матди шартлар чыныктырмый, ә характерны изә, ә Америка культурасына элек-электән уңышка ирешү, индивидуализм, өстен калырга тырышу һәм теләсә нинди шартларда җиңүгә ирешү, ныклы әхлакый принципларга йөз тоту традицияләре салынган дип уйлыйлар.

Бу хакта сез ни уйлыйсыз? Уй-фикерләрегезне языгыз.



23. Яшәү рәвеше

Нәрсә ул яшәү рәвеше

Гаилә тормышы фатир, эш, дача, ял итү урыны белән бәйле. Халыкның тормышы аерым бер ил территориясендә уза. Дөрес, европалылар һәм америкалылар бөтен дөнья буенча йөрергә яраталар. Бу — аларның яшәү рәвешенә хас үзенчәлек. Ә урта гасырлар крестьянының тормышы үз авылы эчендә узган, ул, башка илләргә бару турында әйтергә дә юк, шәһәрдә дә бик сирәк булган. Кайбер халыклар, мәсәлән, чегәннәр бер урында гына яшәмиләр, һәрвакыт күченеп йөриләр.

Үз тормышыгыздагы гадәти бер көнне алып карагыз, аны анализлагыз һәм сезнең яшәү рәвеше структурасы ачыкланыр. Хәтта бер генә кешенең яшәү рәвеше дә вакытлар узу белән үзгәреп тора. Балачакта тормыш тәртибе бертөрле, ә яшьлектә, өлкән яшьтә һәм картлыкта ул бөтенләй башка. Яшәү рәвеше күп нәрсә турында сөйли: төрле илләрдә кешеләр ни белән туклана һәм нәрсә кия; алар ничек эшли һәм ял итә; аларның көн тәртибе нинди;

алар нәрсә турында уйлый һәм нәрсәгә ышаналар. Без шулай ук дөньяда вельможалар һәм гади гражданнарның, шахтерлар һәм адвокатларның, хатын-кызлар һәм ир-атларның, олылар, балалар һәм картларның ничек яшәүләрен белә алабыз. Яшәү рәвеше үз-үзеңне тоту манераларында, традицияләрдә, тормыш стилендә, гореф-гадәтләрдә, зәвыкта чагыла. Ул элеге социаль төркем өчен типик һәм шул ук вакытта аны башка төркемнәрдән аерып торган культура элементларын гәүдәләндерә.

Яшәү рәвешенә кешенең милләте, яше, җенесе, һөнәре йогынты ясый. Аерым кешенең яшәү рәвешендә аның халкының типик мәдәни сыйфатлары чагыла. Бер кеше белән генә очрашып та еш кына тулаем бер халык турында нәтиҗә ясыйлар һәм, әйтик, немецлар бик пөхтә һәм төгәл, ашыкмас һәм төпле, ә руслардан — теләсә нәрсә көтеп була, алар киң күңелле һәм сабыр, диләр. Бу безнең һәркайсыбызда культураның үзенчәлекле яклары гына түгел, ә гомуммилли сыйфатлары да чагылудан килеп чыга, ләкин индивидуаль һәм милли сыйфатлар һәрвакытта да бергә кушылмый.

Яшәү рәвеше үз-үзеңне тотуның характерлы якларын да, аерымлыкларын да үз эченә ала. Әйтик, тешләрне махсус щетка ярдәмендә чистарту — культура, төгәлрәк әйткәндә, шәхси гигиена үзенчәлеге.

Теш щеткасы уйлап чыгарылганчы кешеләр аны алыштыручы күп төрле предметлардан файдаланганнар. Ләкин уйлап табылгач һәм киң таралгач, ул яшәү рәвеше үзенчәлегенә әверелгән. Аңардан планетабызның барлык кешеләре файдаланган өчен түгел. Нәкъ менә киресенчә. Теш щеткасы аңардан барлык халыклар файдаланмаганга күрә яшәү рәвеше үзенчәлеге булып тора.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Яшәү рәвеше — мәгълүм пространствода һәм мәгълүм бер вакытта кешенең, гаиләнең, халыкның яшәешен һәм эшчәнлеген оештыру ысулы ул.

ТӨРЛЕ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ЯШӘҮ РӘВЕШЕ

Борынгы римлыларның яшәү рәвеше

Мисал өчен, б. э. к. 105 ел тирәсендә римлының эш көне кояш чыккач, ә кайчак иртәрәк тә башланган. Ясалма яктылык бик тонык, кыйммәт булган һәм шуңа гражданнар тәүлекнең якты вакытыннан файдаланып калырга тырышканнар. Һәр ирекле римлы иртүк үз патроны янына ашыккан. Шул рәвешле, үзенең аны хөрмәт итүен күрсәткән һәм әдәплелек визиты ясаган. Ирекка җибәрелгән коллар үз хуҗаларына бәйле булып калганнар, ә патрицийларның йогынты көче клиентлар саны белән билгеләнгән. Иртәнге әдәплелек визитлары вакытында патрицийлар үтенеч һәм шикаятьләрне тыңлаганнар.

Алар көн саен клиентлар кабул итәргә һәм кирәк булганда булышырга тиеш булганнар. Һәр визит барышында клиентка алты сестерций бүләк итү, ә аерым очракларда кыйммәтлерәк бүләк, мәсәлән, яңа тога бирү гадәткә кергән. Ярлылар үз яклаучылары янына ешрак килгәннәр. Чөнки еш килсәң — күбрәк тама бит.

Иртәнге кабул итүдән соң, хуҗа үзе дә, кирәкле визитлар ясау өчен, йортыннан чыгып китә, ә клиентлар эшкә юнәлә. Ир-атларга гына иртәнге әдәплелек визитлары ясарга рөхсәт ителгән; кайчакта тол хатыннар да үтенеч белән мөрәҗәгать итә алганнар. Хатыннар тормышы (алар аталары опекунлыгыннан үзләре сайлаган ирләр хакимлегенә күчсәләр дә) йорт эчендә узган. Алар хәзер мирас калдыру хокукына ия булганнар, ә элегрәк бу тыелган.

Бушменнарның яшәү рәвеше

Африканың көньягында урнашкан Калахари чүлендә бушмен кабиләләре яши. Аларның тормыш тәртибен һәм стилен түбәндәгечә тасвирларга була. Иртән бушменнар гаиләләре — балалар, ата-аналар һәм картлар —бергә җыела. Кияүгә чыкмаган яисә тол калган туган апа һәм абыйлары да иртәнге ашны шунда ашыйлар. Аннары балалар күрше алачыкларга таралалар яисә үз яшьтәшләре белән кечкенә төркемнәргә җыелалар. Бер үк яшьтәге туганнан-туган кызлар һәм малайлар аеруча тату.

Кайчакта барлык балалар, ничә яшьтә булуларына карамастан, бергә уйныйлар. Ләкин еш кына малайлар һәм кызлар аерым уйныйлар. Уен буенча партнер сайлау уенның характерына бәйле: малайлар аучы булып уйнарга, ә кызлар алачыклар төзергә, үзләре ясаган курчаклар белән мәш килергә яраталар.

Өлкәннәр төркем-төркем булып аучылык һәм азык җыю белән шөгыльләнәләр. Хатын-кызлар ризык эзләүгә көн саен өч сәгать чамасы вакытларын сарыф итәләр. Аларның авылда үзара аралашу өчен дә вакыты байтак кала, ирләрнең исә буш вакытлары күбрәк тә: алар ауга һәр көнне бармыйлар ич. Буш вакыт шулай ук шөгыль белән тулы: төрле-төрле кәсеп итү (тире эшкәртү, ук өчен очлыклар әзерләү, муенса тезү һ. б.), сөйләшеп утыру, бер-береңне тәрбияләү һәм балалар карау, төрле ярышларда катнашу, трубка тарту. Төп шөгыльләр күмәк рәвештә башкарыла. Ирләрнең иң яраткан уены аучы һәм җанвар арасындагы көрәшне гәүдәләндерә.

Авыл уртасындагы ачык мәйданчык барлык чараларны үткәрү урыны булып хезмәт итә. Дини церемонияләр дә шунда уза. Кешеләр кайда гына очрашмасын (агач күләгәсендәме яисә нинди дә булса алачыктамы) төркемнәр арасында үзара иркен сөйләшерлек ара кала. Олылар да, балалар да компанияне үз теләкләре белән сайлыйлар. Киеренке мөнәсәбәттәге кешеләрдән читтә булырга тырышалар.

Рус сәүдәгәрләренең яшәү рәвеше

Ә революциягә кадәрге Россиядә сәүдәгәр гаиләсенең яшәү рәвеше менә нинди була. Галим П. Николаев моны үз заманы өчен шактый мул тормышлы, XIX гасыр урталарында Мәскәүнең Кече Якиманка дигән җирендә яшәгән Вишняковлар гаиләсе үрнәгендә күрсәтә. Сәүдәгәр йорты үзара тоташкан ике таш бинадан тора. Алдагы йорт ике катлы, мезонинлы була, Якиманкага чыга, арттагысы (өч катлы) ишегалдында, шактый зур бакча түрендә урнаша. Гаиләдә көн тәртибе төгәл үтәлә. Иртәнге тугызларда чәй эчәләр. Аннан соң кече Вишняковлар кибеткә ашыгалар, өлкәннәре бераз соңрак кузгалалар. Алар төшке

Рәсемдә кайсы чор кешеләренең яшәү рәвеше сурәтләнүен ачыклагыз. Кайсы өлкә (эш, ял) яшәү рәвеше турында тулырак күзаллау булдырырга ярдәм итә?

ашны шәһәрдә ашыйлар, ә өйдә калучылар — сәгать икедә. Сәгать биштә — кичке чәй, ә тугызда — кичке аш. Өстәлдә беркайчан да аракы һәм шәраб булмый. Бәйрәмнәрдә бөтен гаилә белән чиркәүгә баралар.

Вишняковлар әллә ни аралашып яшәмиләр. Күп санлы туганнарыннан иң якыннары белән генә йөрешәләр. Сирәк-мирәк карта уены кичәләре була. Кунак бүлмәләренең берсендә ломбер өстәлләр җәелә, аның артына кунаклар һәм хуҗалар (бары ирләр генә) утыра. Бостон, ламуш һәм ул чакта модага кереп барган преферанс уйнала. Кунакларны зур хөрмәт белән каршылыйлар. Варенье һәм как белән чәй эчерәләр. Чит ил сәүдәгәрләре белән дәрәҗәле сөйләшүләр тәрҗемәче аша алып барыла. Кабул итү сәгать ярымнарга сузыла.

Раштуа һәм Пасхада рәсми визитлар ясала. Моннан тыш, бу йортка төрле мәхәлләләрдән руханилар килә, гаилә алар белән ничектер бәйләнгән була. Шулай ук Вишняковларның туганнары күмелгән, алар үзләре дә дога кылырга йөргән монастырьлардан монахлар килә. Күп санлы руханиларны кабул итү Мәскәү сәүдәгәрләре арасында күркәм гамәл санала.

Масленицада — Новинск тыкрыгында, 1 майда — Сокольникида, җәй көннәрендә (ике-өч тапкыр) Күңелле

(Нескучный) бакчада атта йөрү гаиләдә электән килгән күңел ачу дип санала. XIX гасыр уртасында Новинск тыкрыгы янында озын гына буш җир була, анда ярминкәләр һәм күңел ачулар уздырыла: товар ташучылар йөгерешә, шарманкада уйныйлар, карусель әйләнә. Балаганда пантомималар уйнала, анда чуар киенгән кәмитчеләр, арлекиннар һәм коломбиннар катнаша. Спектакль сюжетлары еш кына хәрби-патриотик характер ала.

Сәүдәгәрләр арасында гадәттән тыш популяр булган атта йөрүләр, асылда, иң яхшы экипажлар, меңәр сум торган юртаклар һәм бик бай җигү кирәк-яраклары күргәзмәсен хәтерләтә. Хуҗалар бәйрәмчә киенгән хатыннары һәм балалары, җиткән кызлары белән йөриләр: монда бай каләшләр күргәзмәсе дә бара бит. Барьерлар янында берничә рәт булып яшь ир-атлар басып тора: барысы да атта йөрүчеләрне кызыксынып күзәтә, баш ия.

Инглизчә яшәү стиле

Инглизчә яшәү стиле — ул зифа буйлы һавалы леди һәм джентльменнар гына түгел, бу әле аның аерылгысыз атрибутлары — роза чәчәкләре, бульдог этләре, ат чабышлары да. Инглиз стиле — бу, барыннан да элек, классика, ә ул, мәгълүм булганча, модадан өстен. Бу гадилек, ләкин максималь уңайлыктан һәм гамәлгә ярашлыктан, шулай ук инглиз характерының катгыйлыгыннан һәм тотнаклыгыннан чыккан кыйммәтле гадилек.

Джентльмен беркайчан да очраклы танышы белән чын күңелдән әңгәмә кормас, чуар күлмәк кимәс һәм тутый кошлы галстук такмас. Иң популяр һәм яраткан кием — ирләр өчен дә, хатын-кызлар өчен дә гади костюм.

Күп кенә типик инглиз әйберләре баштан ук спорт белән шөгыльләнү өчен уйланылган. Британиядә спорт традиция генә түгел, ул инде үзенә күрә бер дин дияргә була. Крикет, гольф, теннис, атка атланып йөрү һәм футбол — табигатьтә уйнауны инглизләр элек-электән салонда сөйләшеп утырудан өстен күргәннәр. Спорт ялының һәр төренә аерым костюм булдырылган. Инглиз киеменең демократияле, элитар һәм элегантлы булу сыйфатлары шуннан килә. Инглиз стиленең асылы — шушы бер-берсенә юл калдырмаган башлангычларның үрелеп баруында.

Чын джентльмен баш киемен сирәк кия, ләкин шарф һәм перчатка — мәҗбүри атрибутлар. Чын леди беркайчан да өеннән аякларына оек яисә колготка кимичә чыкмый. Леди да, джентльмен да салкыннан курыкмыйлар һәм һәрвакыт җиңел киенәләр. Алар туалетында иң мөһим нәрсә — зонтик. Британиялеләрнең үз-үзләрен тотышларында төп канун — костюмың белән аерылып тору оят.

Солы боткасы белән мул иртәнге аш, тыйнак кына төшке ленч, һичшиксез чәй эчү (16 һәм 17 сәгатьләр арасында кайда гына булсалар да, ни генә эшләсәләр дә, инглизләр бергәләп чәй эчәләр), иртә яту, иртә тору, уикэндны гаиләдә һәм чиркәүдә үткәрү — шундый тәртип культ дәрәҗәсенә күтәрелгән.

Американча яшәү рәвеше

Мул тормышлы американың йорты, кагыйдә буларак, «күркәм» районнарның берсендә урнашкан. АКШның барлык эре шәһәрләрендә күркәм район — үзәктә түгел, ә шәһәр читендә. Ике катлы йорт, өстәге катта — 3—4 йокы бүлмәсе, аста — кунак бүлмәсе, ашханә һәм кухня. Йорт 20×40 м зурлыктагы җир кишәрлегендә урнашкан. Йортта — ике машиналык гараж. Ике машина тоту —ул зарурилык, чөнки ирле-хатынлы икесе дә эшли (берсе генә эшләүче гаилә хәзер бик сирәк), ә алар яшәгән җирдән эш урыннарына җәмәгать транспорты нигездә йөрми.

Машинада һәм аның ярдәмендә американлылар, мөгаен, бөтен нәрсәне эшлиләрдер: аннан чыкмый гына үзләренә сандвич һәм кофе алалар, машинада супермаркетка керәләр, машинада утырып кино карыйлар һ. б. Кайбер шәһәрләрдә көндез җәяүлеләрне күрмисең дә — бөтенесе көпчәкләр өстендә.

Иртәнге алтыда торып, америкалы телевизор каршында җиңел генә ашап ала һәм яңалыклар белән таныша.

«Иркен тормышлы» америкалы өеннән 15—20 км ераклыкта эшли һәм юлга бер сәгать чамасы вакытын сарыф итә. Сәбәбе — юлдагы «бөкеләр».

Кичке сәгать 5—6 да америкалы эшеннән кайтырга чыга. Тагын берәр сәгать «бөке»дә утырып, өенә кайтып җитә. Хатыны да кайткан инде, ә балалары көндездән үк

өйдә. Аларның барлык буш вакытлары телевизор каршында уза. Кичке сәгать 7 белән 8 арасында, яхшы гына ашап, ир белән хатын телевизор каршына утыралар (балалар үзләренекен карый). Америкалы нинди дә булса фильмны бик сирәк карый, моның урынына ул бер үк затлар уйнаган, үзе яраткан шоуны күзәтә. Эпизодлар коймак урынына коелып кына тора һәм кирәк урыннарда тамашачыларның тасмага язылган көлгән авазлары да тапшырыла.

Бай һәм урта хәлле америкалылар ресторанда туклануны кулай күрәләр. 5—10 өстәлле бу кечкенә рестораннарда Америкада яшәүче барлык халыкларның милли кухняларын очратырга була. Ашап бетерелмәгән ризыкларны (ә порцияләр бик зур), кагыйдә буларак, үзләре белән алалар.

Фәкыйрь районнарда яшәүчеләрнең фатирлары дистәләрчә еллар буе төзекләндерелмәгән күп катлы йортларда урнаша. Буяулары күптән купкан, штукатурка коела, канализация тыгыла, торбалар ага. Фатирда суыткыч һәм телевизор тузып беткән, ләкин әлегә эшли. Ризык җитәрлек. Күп кенә ярлыларның үз машиналары — ярым-җимерек иске автомобильләре бар.

Фәкыйрь районда яшәүче эшкә метрода йөри. Метро, мәсәлән, Бостонда, Америка күзлегеннән караганда — ярыйсы, ә Мәскәү белән чагыштырганда —коточкыч.

Америка ковбойлары һәм «хәлле» америкалының (текстта шул турыда сөйләнә) яшәү рәвешләре бертөрлеме?

Пычрак, тоныкъ кына яктыртылган станцияләрдә, җәен эссе, ә кышын өстәгегә караганда күпкә суык. Поездлар пычрак булса да, йөрерлек: аларның күбесендә кондиционерлар да бар. Ярлыларның байтагы савыт-саба юучы яисә эшче ярдәмчесе булып хезмәт итә.

Көндез ярлы кварталлар әле ярыйсы күренә. Урамнарда гадәти тормыш бара — кеше күп йөри, адым саен вак-төяк кибет һәм рестораннар. Әмма караңгылану белән хәл кискен үзгәрә: бу районнар «хәрби хәрәкәт зонасына» әверелә. Урамнарда башлыча наркотик сатучылар һәм йолкыш, тормыш төбенә тәгәрәгән наркоманнар гына кала.

Американлыларның яшәү рәвеше киңлекләрдә һәм вакытта иркен күчеп йөрүче, җиңел генә һәм бик тиз дуслар табучы кешеләр тудыра, алар үз гомерләрендә бик күп багланышлар урнаштырырга, шундый мөнәсәбәтләргә башка илләр белән чагыштырганда күбрәк кешене җәлеп итеп эшләргә һәм хезмәттәшлек итәргә сәләтле.

Шулай итеп, без халыкның яшәү рәвешендә милли характерның чагылуына ышандык. Алар бер-берсенә йогынты ясый һәм үзара тыгыз бәйләнгән. Билгеле бер яшәү рәвеше милләтнең нәкъ менә шундый характерын формалаштыра, ә соңгысы халыкның бөтен яшәү рәвешендә чагыла.

Йомгак ясыйбыз

Социаль, финанс хәленең, тору урынының һ. б.ның үзгәрүе нәтиҗәсендә, вакытлар узу белән, яшәү рәвеше үзгәрергә дә мөмкин. Кагыйдә буларак, яшәү рәвеше анык бер җәмгыятьнең гореф-гадәтләре кысалары белән чикләнә. Шәхес стандарттан аерылып торган тормыш манерасын сайлап алырга, шуның белән үзен җәмгыятьтән беркадәр аерып куярга хокуклы. Мондый карарга килүгә гайре табигый фикер йөртү, характер үзенчәлекләре һәм яңага омтылыш этәргеч бирә ала.

Белемегезне тикшерегез

1. «Яшәү рәвеше» төшенчәсенең мәгънәсен ачыклагыз.

2. Тормышны оештыруга нинди факторлар йогынты ясый?

3. Төрле халыкларның яшәү рәвешен чагыштырыгыз. Уртаклыкларны һәм аерымлыкларны күрсәтегез.

Практикум

1. Сезнең тормышыгызның гадәти бер көне, әйтик, чәршәмбе яисә пәнҗешәмбе ничек оештырылган? Көн тәртибен, эшчәнлек төрләрен, үз-үзегезне тоту рәвешен, шөгылегезне һәм ялыгызны тасвирлагыз.

2. Матбугат, радио, телевидение, Интернет материаллары буенча «Хәзерге заман Россия яшүсмеренең яшәү рәвеше» дигән хәбәр әзерләгез.

3. Дөньяның төрле тарихи чорларда яшәгән биш халкын атагыз. Сезгә аларның яшәү рәвешен — шөгыльләрен, күңел ачуларын, көнкүрешләрен характерлаган предметларны сайлап күрсәтергә кирәк.

24. Буш вакыт һәм ял

Буш вакыт

Буш вакыт һәм ял кешеләрнең көндәлек яшәү рәвешләренең состав өлешен тәшкил итә.

Буш вакыт — кеше эштән азат вакытның үз карамагындагы бер өлеше. Буш вакытның төп үзенчәлекләре — дәвамлылык, уздыру урыны һәм ысулы, структурасы.

Эштән азат вакыт эштән тыш вакытның бер өлеше булып тора, өй эшләрен, үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, йокы һәм ашауны, эшкә бару вакытын, балалар тәрбияләүне, ял, иҗтимагый эшчәнлек һ. б.ны үз эченә ала. Буш вакыт һәм ял — бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән төшенчәләр. Эштән азат вакытта кешеләр ял итәргә тели. Дөрес, ялны һәркем төрлечә аңлый. Берәүләр бию, музыкаль инструментларда уйнауны ялга саныйлар, икенчеләре ялны кунакка йөрүдә, дуслар белән очрашуда күрә.

Элек тә төрлечә ял иткәннәр: берәүләр сәнгатькә бирелгән — африкалыларның ритмик һәм музыкага бай биюләре, икенчеләр — башкача, әйтик, куакиутлак кабиләсенең рәхимсез сугышлары, ә Төньяк һәм Үзәк Америкада — индеецларның лапта һәм туплы уеннары.

Борынгы греклар һәм римлылар башкача ял иткән һәм күңел ачкан. Рим империясе ул — 100 миллионлы халкы булган ил һәм 2 миллионлы башкала. Барлык уеннар һәм күңел ачулар массакүләм төстә уздырылган. Максим циркы — 400 мең, Колизей 90 мең тамашачыны сыйдырган. Халык икмәк һәм тамаша таләп иткән. Гладиатор уеннары, ясалма күлләрдә диңгез сугышлары, ике көпчәкле арбаларда узышулар,— хәзерге заманча әйткәндә, болар массакүләм шоу-тамаша инде. Дөрес, алар канкойгыч, тупас һәм рәхимсез булып күренгәннәр.

Урта гасырларда ял функциясен үтәгән массакүләм тамашалар булмый. Алар XIX гасырда гына иң элек АКШта барлыкка килә. Ч. Диккенс китаплары буенча без XIX йөздәге Англия турында фикер йөртә алабыз. Кешеләрнең гомер озынлыгы кыска була, тәүлеккә 12—14 сәгать эшлиләр, балаларның авыр хезмәте гадәти хәл булып санала. Хезмәттән калган вакыт башлыча: йокы, ашау-эчүише биологик ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә тотыла.

Элек буш вакыт азчылыкның өстенлеге булып тора, ә бүген ул һәркемгә бирелгән. Буш вакыт — ул кеше эштән яисә үзенең гаилә йөкләмәләреннән азат булганда оныттылып тору, иҗтимагый тормышта катнашу, яңа белем һәм күнекмәләр алу өчен үзе теләп башкарган гамәлләр. Мондый билгеләмә аны ял белән кушарга да мөмкинлек бирәдер, мөгаен.

Төрле халыкларда буш вакыт

Төрле илләрдә буш вакытны төрлечә үткәрәләр. Бу — җәмгыятьнең икътисади үсеш дәрәҗәсенә һәм анда яшәп килгән гореф-гадәтләргә бәйле.

Индустриаль җәмгыятьтә эштән калган вакытны төрле шөгыль белән тутырырга мөмкин: бакча карарга, өйдә вак-төяк төзекләндерү эшләре башкарырга, балык тотарга, балалар белән уйнарга, спорт белән шөгыльләнергә, китап

укырга, театр яисә кинога барырга. Эштән азат вакытта радио тыңларга һәм телевидение тапшырулары карарга, экскурсиягә яисә сәяхәткә китәргә, туганнарга яисә дусларга барырга һ. б. мөмкин.

Ә үсеп килүче Африка, Азия һәм Латин Америкасы илләрендә ниләр бара?

Мәсәлән, Дагомеяда хезмәт һәм культ йолалары бергә кушылган. Ритуал иң зур канәгатьләнү биргән эшчәнлекне тәшкил итә. Ул үтеп кермәгән эш төре юк. Хезмәт — төркемнең муллыгын саклау өчен кирәкле гамәл, ә аны ирекле башкару матурлык, игелеклелек, дөнья белән тулысынча берләшү һәм өлкәннәргә хөрмәт чагылышы буларак карала.

Борынгы чорлардан ук Африка байтак кына кабилә һәм халыкларның хезмәте генә түгел, бөтен тормышы да өйдән читтә — ачык һавада узган урын булды һәм булып кала. Кешеләрнең шәхси ихтыяҗлары минимумга калганда һәм җиңел канәгатьләндерелгәндә, буш вакыт төшенчәсе юк һәм аны оештыру таләп ителми. Традицион җәмгыятьтә эш, ял һәм буш вакыт берлеге тормыш ритмын билгели, аның агышы фәкать көннең төнгә һәм ел фасыллары алышыну белән генә төрләнә.

Африка, Азия, Латин Америкасы илләрендә ритуал һәм йолаларның ни өчен зур роль уйнавын аңлатып бирегез.

Буш вакытны эшчәнлек төрен алыштыру итеп тә карарга мөмкин. Африка җәмгыятендә ул төрле сәнгать промыселлары белән шөгыльләнүне үз эченә ала. Бу — кәрзин үрү, эшләпәләр ясау, иске ятьмәләрне төзәтү һәм яңаларын үрү, торак диварларын яңарту, түбә ябу, храм төзү яисә ремонтлау. Еш кына алар тамтам һәм үзләре ясаган музыка кораллары авазы астында башкарыла. Дагомеялылар көндәлек эштән ял иткәндә, буш вакытларын багышлаган барлык шөгыль төрләрен санап бетерерлек тә түгел. Хатын-кызларда аларның диапазоны гаять киң: муенса әзерләүдән алып Африкада чын сәнгать булып әверелгән бер-берсенең чәч толымнарын үрүгә кадәр.

Шулай да африкалыларның мәдәни үзенчәлегендә төп элементны тамтам көенә җыр һәм биюләр тәшкил итә. Африка авылы тамтам авазларыннан, җырдан, биюләрдән, балалар тавышыннан, олылар көлүеннән гөр килеп тора. Авылның даими тавыш фонын булдыручы һәм еракларга таралучы тамтам авазлары берәүләргә, шул ритмга кушылып, ашлык төяргә, икенчеләргә, кулына себерке тоткан килеш биеп, торакны җыештырырга ярдәм итә.

Ниһаять, культуралы ял итү дә бар. Кичләрен африкалылар төрле тарихи хикәяләр сөйләргә яраталар. Ай яисә учак яктысында гаилә башлыгы яки өлкән туган гаилә тарихын искә ала яисә миф каһарманнарының батырлыклары турында сөйли. Бу — хәтерне ныгыта, белем чыганагы һәм әхлак тәрбиясе чарасы булып тора.

Россиялеләрнең буш вакыты

Россия социологлары тикшеренү үткәрәләр һәм халыкның төрле төркемнәренә шундый сорау бирәләр: «Нинди шөгыль сезгә шатлык китерә?» Нәтиҗәдә менә нәрсә килеп чыга. Бөтен халык ике шөгыльне — вакытны балалар белән үткәрү һәм кызыклы китап (57 %), журнал (39 %) укуны яратып башкарган: 20 яшькә кадәрге яшьләрнең яраткан шөгыльләре: музыка тыңлау (57 %), сәяхәт итү (39 %), телевизор карау (29 %), спорт белән шөгыльләнү (25 %). Ә өлкән яшьтәге кешеләр вакытларын гаиләдә (40—65 %), бакчада эшләп (48 %), укып (46 %), урманда

йөреп (25 %), балык тотып яки җәнлек, кош-корт аулап (17 %) үткәрергә телиләр.

Безнең заман өчен характерлы күренеш — буш вакытны актив үткәрүдән пассив ялга күчү.

Театрга, консерваториягә яисә стадионга бару өчен көч түгәргә дә, вакыт үткәрергә дә кирәкми. Бүген барлык күңел ачулар каналларны алыштыру төймәсенә басу белән алдыңа килеп баса. Күргәзмәгә, симфоник концертка, театрга барганда кеше актив гамәлгә кушылып кына калмый. Ул «кеше арасына» чыга, шуңа тиешле кием сайлый. Телевизорны өйдә йөри торган башмаклар киеп тә карыйлар, рухны эшләтү һәм мәдәнилеккә ирешү турында уйлап та карамыйлар. Ләкин хәзерге заманның техник могҗизалары музыка башкару яисә актерлар уенының сыйфатын төшерә. Консерваториядә тере музыка тыңлау бер нәрсә, телевизордан тапшырылган авазлар — бөтенләй башка. Байтак кеше хәзер телевидениенең физик яктан да, рухи яктан да кеше активлыгын киметүгә китерүен аңлады.

Ирекле вакытны төрлечә уздырырга мөмкин: театрга барырга, паркта йөрергә, балык тотарга, музейлар һәм күргәзмәләр карарга, спорт белән шөгыльләнергә. Буш вакытның кешенең рухи дөньясын үстерүгә юнәлтелмәгән формалары мәдәни булып санала алмый.

Культуралы ял белем алуга, кешенең рухи һәм нәфасәти үсешенә юнәлтелергә тиеш. Ә китапханә һәм музейлардан башка без тагын кайда дөньяга карашыбызны киңәйтә, гүзәл сәнгать әсәрләрен күреп белә алабыз? Алга таба сүз шулар турында барачак. Китапханә һәм музейлар кешелек җәмгыяте һәм мәдәниятен үстерүдә, буш вакытны оештыруда мөһим роль уйный.

Китапханәләр

Язма истәлекләрне бик борынгы заманнарда ук җыя һәм саклый башлыйлар (Ассириядә, Борынгы Мисырда, Грециядә һәм Римда). Беренче китапханәләр б. э. к. II меңьеллыкта барлыкка килә. Халык өчен беренче китапханә Афинада б. э. к. V гасырда ук эшли. Урта гасырлар башында монастырьлар каршындагы китапханәләр киң үсеш

ала, ә XV йөздә, китап басу уйлап табылгач, китапханәләр сыйфат ягыннан яңа баскычка күтәрелә. XIX гасырда китапханәләр массакүләм төс ала. Россиядә монастырь китапханәләре XI—XII гасырларда, ә беренче дөньяви китапханәләр XVIII гасырда Петр I идарә иткән заманда Фәннәр академиясе һәм Мәскәү университеты каршында барлыкка килә.

Бүген **китапханәләр** (*грек.* bibliotheke, biblion — китап, theke — саклау урыны) — басма продукция фондлары җыелган һәм саклаңган, аны махсус эшкәртү (фәнни һәм реставрация) башкарылган һәм аннан укучыларның файдалануын оештырган учреждениеләр алар. Китапханәләр фәнни-мәгълүмати һәм мәдәни-агарту учреждениеләре дә булып торалар. Аларның мәдәни функцияләре шуның белән билгеләнә.

Китапханәләр *массакүләм* (публика өчен) һәм *махсуслашкан* (фәнни һәм техник) төрләргә бүленә. Мәктәп, район, шәһәр, республика китапханәләре массакүләм китапханәләргә керә. Алга таба алар һәркем йөри алган, яшьләр, балалар китапханәләре дип классификацияләнә. Массакүләм китапханәләр өчен иң мөһиме — укучыларның китаплардан файдалана алулары. Махсуслашкан китапханәләргә керү чикләнгән. Кайбер махсуслашкан китапханәләр басма продукциянең мәҗбүри нөсхәләрен, төп һәм уникаль документларны саклый.

Ни өчен төрле чорларда кешеләргә китапханәләр кирәк булган?

Эре китапханәләр бер үк вакытта массакүләм һәм махсуслашкан режимнарда эшли. Мәскәүдәге Россия дәүләт китапханәсе шундый китапханәләрнең бер үрнәге булып тора, анда барлык мәҗбүри нөсхәләр саклана һәм киң фәнни-тикшеренү эшчәнлеге алып барыла.

«Китапханә» терминын учреждениеләргә карата гына түгел, шәхси (өйдәге) басма әсәрләр тупланмаларына карата да кулланып була. Илебездә өй китапханәләре XX гасырның 70—80 нче елларында халыкның күпчелеге урта, ә шактый өлеше югары белем алгач, массакүләм күренешкә әверелде. Укучы публика формалашты, шәхси китапханә булдыру модага керде. Ул билгеле бер мәдәнилек дәрәҗәсе күрсәткече булып хезмәт итте.

Музейлар

Музей (*грек.* museion — музалар храмы) — бу фәнни, тикшеренү һәм агарту учреждениеләре. Алар матди һәм рухи мәдәният истәлекләрен булдыралар, саклыйлар, өйрәнәләр.

«Муза храмнары» буларак, беренче музейлар антик Грециядә барлыкка килә. Алар әйләнә-тирә дөньяны танып белү, уйлану һәм фәлсәфи фикер йөртү урыны булып санала. Музейларда шулай ук борынгы философлар, шагыйрьләр, музыкантлар һәм актерлар җыела, алар анда үзара осталыкта ярыша. Монда сәнгать әсәрләре һәм культ әйберләре саклана.

Музейлар храмнарда һәм изге урыннарда гына түгел, атаклы аксөяк йортларында да була. Анда гасырлар буена, буыннан-буынга сәнгать әйберләре, көнкүрештә кулланылган кыйммәтле әйберләр, аристократларга, үзләренең тугрылыкларын раслап, подданныйлары китергән бүләкләр туплана. Афинадагы Акропольдә, Дельфия храмында, Олимпиядә статуялар, вазалар, тукымалар, ювелир әйберләр саны шулкадәр нык арта ки, алар инде храмнарга гына сыймыйлар һәм аларны саклау өчен өстәмә биналар төзелә.

Афинада б. э. к. 335 елда Аристотель нигез салган Ликеяда белем бирү максатларында файдаланылган табигый-фәнни һәйкәлләр коллекциясе туплана. Афинадагы

Акрополь пинакотекасы эллинизм чоры картиналарын иң мөһим саклау урыны булып тора. Александрия музее (б. э. к. 290 еллар тирәсендә нигез салынган) һәм Пергам китапханәсе (б. э. к. III гасыр) — Антик чорда китаплар һәм сәнгать җәүһәрләре сакланган иң зур урыннар — шулай ук киң билгеле.

Ренессанс чоры өчен үткәндәге мираска югары кызыксыну белән карау хас, бу бигрәк тә XIV—XV гасырларда Флоренциядә (Италия) ачык чагыла. Күп кенә Флоренция сәүдәгәрләре һәм аристократларының сәүдә йортлары тәңкә, мөһер, кабарынкы сурәтле асылташ (камея), медаль, гобелен, икона, скульптура, рәсем сәнгате әсәрләре, сирәк китаплар һәм сугыш коралларыннан коллекция төзү белән мавыгалар. Флоренция коллекционерлары арасында Медичилар нәселе беренче урында тора. Европада иң карт музейларның берсе — Флоренциядәге Уффици галереясы — XV—XVI гасырларда төзелә. Системасыз әйбер җыюдан мәдәни һәм фәнни юнәлешле җыелмалар барлыкка килүгә беренче адым әнә шулай ясала. Кунсткамера, сирәк очрый торган әйбер кабинетлары, галереялар төзелә башлый. XVI гасырда Венециядә, Англиядә, Франция һәм Швейцариядә халык өчен беренче музейлар барлыкка килә.

Уйлагыз, сез нинди музейларда булыр идегез. Ә нинди музейларда булганыгыз бар?

Россиядә беренче музейлар Көнбатыш Европа белән чагыштырганда соңрак барлыкка килә. Кыйммәтләрне саклауның традицион урыны булып соборлар һәм монастырьлар хезмәт итә. XVI—XVII гасырларда рус патшалары һәм боярларыныкы булган коллекцияләр мәгълүм. Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы җыелмаларын туплау да шул чорга карый. 1719 елда Петр I ярдәме белән Россиядә беренче иҗтимагый табигый-фәнни музей — Кунсткамера ачыла. Сәнгать музейлары булдыруда Екатерина II нең роле зур. Ул Көнбатыш Европада хәзер иң зур музейларның берсенә әверелгән Эрмитажның нигезенә яткан классик рәсем сәнгате коллекциясен сатып ала.

Бүген белгечләр музейларның өч тибын аерып карыйлар — *фәнни-агарту, тикшерену, өйрәну* музейлары. Аларның түбәндәге профильдәгеләре була: тарихи, сәнгать, техника, авыл хуҗалыгы, табигый-фәнни, сәнгатьне өйрәнү, әдәби, мемориаль, музыкаль, туган якны өйрәнү музейлары һ. б.

Музейларның төп вазифасы — электән калган йә әле дә исән буыннарның кыйммәтләрен җентекләп җыю, фәнни тасвирлау. Музей һәм коллекция фондлары даими тулылана, реставрацияләнә, өйрәнелә һәм күргәзмәгә куела.

Йомгак ясыйбыз

Һәрбер кеше төп вазифаларыннан (эш, уку) буш вакыты белән үзе теләгәнчә эш итә. Бу пассив ял, сәламәтлекне ныгыту, мәдәни дәрәҗәне күтәрү, шулай ук гаилә белән аралашу, хобби, йорттагы проблемаларны хәл итү һ. б. булырга мөмкин.

Белемегезне тикшерегез

1. «Буш вакыт», «ял», «эштән азат вакыт», «мәдәни ял вакыты» төшенчәләренең мәгънәләрен билгеләгез. Уртак сыйфатларны һәм аерымлыкларны табыгыз.

2. Кешене аның ялы ничек характерлый? Җавабыгызны мисаллар белән раслагыз.

3. Кешеләр борынгы заманнарда үз ялларын ничек уздырганнар? Уртаклык һәм аерымлыкларны сез нидә күрәсез?

4. Аңлатыгыз, китапханә һәм музейлар нигә кирәк.

5. Хәзерге заманда телевизор һәм компьютер укуны кысрыклый. Сез ничек уйлыйсыз, фильмнар карау һәм компьютерда эшләү китапны алыштыра аламы? Ни өчен?

Практикум

1. «Мин яраткан музей экспонаты», «Китап минем тормышта» дигән темаларның берсенә хәбәр әзерләгез.

2. «Мәгънәсез ял эштән дә битәр арыта» дигән мәкальнең асылын аңлатыгыз.

3. «Эштән азат вакытны мин...», «Безнең гаилә өчен иң яхшы ял...», «Түбәндәгеләр эштән азат вакытны ничек файдаланудан тора: ...» дигән фразаларны тәмамлагыз.

25. Спорт

Спорт тарихыннан

Sport термины урта гасырларда инглизчә *disport* сүзеннән килеп чыккан, соңгысы күңел ачу, уеннар дигәнне аңлата. Бу сүзнең килеп чыгышы хәзерге заман спорты белән уен, буш вакытны үткәрү, күңел ачу арасында тыгыз элемтә барлыкны күрсәтә. Хәзерге сүзлекләр **спортны** организмны ныгыту максатында физик күнегүләр ясау, махсус әзерлек һәм физик көч таләп иткән атлетик эшчәнлек дип билгели. Бүген спорт үзенең борынгы башлангычыннан нык аерыла. Антик һәм урта гасырлар җәмгыятендә спорт, чыннан да, күңел ачуга, гадел ярышуга, дини ритуалга якынрак торган. Грекча *athletikos* җитезлек һәм көчне арттыручы физик күнегүләр системасын белдергән. Бүген спорт һәм атлетика синонимнар булып санала.

Тарихи яктан спорт башта уен белән дини ритуал катнашмасыннан гыйбарәт булган. Борынгы грекларда гына спорт (ярышлар аллалар хөрмәтенә үткәрелсә дә) хәзерге заманча спорт ярышлары мәгънәсен алган. Зевска багышланган беренче Олимпия уеннары б. э. к. 776 елда узган. Аларның үзенчәлекле роле, теләсә нинди бәхәсләргә карамастан, грекларга халыкның мәдәни бердәмлеген саклап калырга һәм үстерергә мөмкинлек бирүендә.

Олимпиадада тулы хокуклы гражданин статусы булган һәм тапланмаган репутациягә ия һәвәскәрләр генә катнашкан (18 яшькә кадәрле үсмерләр өлкәннәрдән соң ярышканнар, ә хатын-кызлар өчен аерым ярышлар оештырганнар). Һәр Олимпиадага әзерлек алдан ук башланган. Әзерлек уеннар ачылуга ун ай кала, 10 кешедән торган судьялар советы сайлангач, хәлиткеч стадиягә кергән. Судьялар ярышларда катнашачак атлетларның өйрәнүләрен (тренировкаларын) күзәтеп торганнар. Уеннар программасы 13—15 спорт төрен үз эченә алган. Кояш чыгуга ук, кыска һәм озын дистанцияләргә йөгерүдә ярышлар башланып киткән. Аннары көрәш, йодрык сугышы, панкратион — йодрык сугышы һәм көрәш комбинациясе; сөңге, тәлинкә ыргыту, йөгерү, сикерү, көрәшне үз эченә алган бишле ярыш; ике көпчәкле арбаларда узыш һәм ат чабышлары. Бер генә гражданинны да ярышлардан төшереп калдырмаганнар, күпчелек, ниндидер бер спорт төре белән генә чикләнеп калмыйча, күп төрләрдә катнашырга тырышкан. Бүгенге бишле ярышлар безгә антик эпоханы хәтерләтә.

Грециядә Искәндәр Зөлкарнәйн (Александр Македонский) заманында спортчылар аерым төрләргә бүленә. Спортның хәзерге системасы формалаша, профессиональ спортчылар бик матур спектакль куялар, ә меңәрләгән җанатарлар аларны трибунадан күзәтә. Искәндәр заманында популяр булган ике көпчәкле арбаларда ярышлар өчен стадионнар һәм ат чабышлары өчен гигант ипподромнар төзелә.

Римлылар борынгы греклар нигез салган традицияләрне дәвам итәләр, спорт ярышларын спектакльгә әверелдерәләр. Гладиаторлар сугышы бинибая зур циркларда уза.

Анда пассив тамашачылар трибунадан канлы тамашаны күзәтә. Башкару сәнгате, музыка, театр һәм спорт иң түбән дәрәҗәгә төшерелә. Тора-бара Рим календареның яртысын бәйрәмнәр алып тора башлый. Эшсез шәһәр халкына Рим хакимияте уеннарга һәм тамашаларга багышланган 200 каникул көне бирә. Буш вакыт пассив күзәтүгә әверелә. Мунча, атлетика клублары, гимнастика заллары, туп уеннары өчен мәйданчыклар модага керә. Әмма үзара ярышу гына түгел, бер-берсен имгәткән акробатларны, атлет һәм көрәшчеләрне күзәтү тагын да зуррак популярлык казана. Атлетлар, чын мәгънәсендә профессионалга әверелеп, бар вакытларын фәкать спортка багышлыйлар. Спорт мәктәпләре, тренерлар җитәкчелегендәге командалар барлыкка килә. Спорт үзенә күрә бер сәясәткә әверелә, сенат спорт парадлары уздыра, аны карарга шәһәрләрнең барча халкы чыга.

Урта гасырларда Рим империясе таркалганнан соң, Европада уеннар һәм спорт, халыкның бөтен категорияләре шөгыльләнә алырлык эшчәнлек төрләре буларак, Католик чиркәве аларны югары сыйныфлар өчен тыймаса да юкка чыга. Лачын белән аулау дворяннар һәм руханиларның иң яраткан шөгыле була. XII гасырда рыцарьлар культурасы формалаша башлый, броня кидерелгән атларга утырган тимер киемле сугышчылар турниры аның иң мөһим элементы булып тора. Турнирлар хәрби чаралардан күрсәтмә чыгышларга, спорт-тамаша ярышларына әверелә.

Тикшеренүчеләр билгеләп үткәнчә, крестьяннарның үз турнирлары була, анда кылыч урынына күсәк кулланыла. Ул вакытларда шулай ук туп уены, көрәш һәм әтәч сугышлары киң тарала. Англия, Франция, Төньяк Италиядә һәм Европаның башка илләрендә җәядән ату һәм хәзерге замандагы теннис, футбол, бильярд уеннарының аналоглары популярлаша. XVI йөздә теннис инглиз дворяннарының, ә футбол итальян дворяннарының үзенчәлекле билгесе була, соңрак Бөекбританиянең бөтен халкы футбол уйный башлый, әтәч сугышлары һәм җәядән ату бик күп илләрдә тарала. Кайбер мәгълүм корольләр (мәсәлән, Англия короле Генрих VIII һәм Франция

Спорт уеннары тарихи эпоха һәм илнең культурасы белән ничек бәйләнгән?

короле Франциск I) спортны яраталар һәм пропагандалыйлар. Алар дворяннар өчен спорт клублары булдыралар, мәйданчыклар җиһазлыйлар. Фехтованиегә, атта йөрергә өйрәнергә, сикерергә, йөгерергә мөмкин булган спорт мәктәпләре һәм курслар ачыла. Иң популяр тренерлар һәм фехтование осталары булып итальяннар санала. Акрынлап спортны, югары әхлаклылык тәрбияләүче, гадел кагыйдәләр урнаштыручы гаҗәеп гүзәл тамаша буларак, яңача аңлау формалаша.

Ренессанс сәнгатьне генә түгел, спортны да яңарта. Яңарыш чоры язучылары, рәссамнары, скульпторлары антик идеалларны торгызуны алга сөрәләр: «Сәламәт тәндә сәламәт рух булырга тиеш». Димәк, физик шөгыль үзмаксат түгел, ул кешедә әхлакый сыйфатлар тәрбияләргә тиеш.

Һәвәскәр спорт XIX гасыр башында Европада һәм АКШта яңарыш кичерә. Ишү, көрәш, җилкәнле спорт, спорт адымнары белән йөрү, ату һ. б. төрләр барлыкка килә. Шәһәрләрдә спортның уен төрләре үсеш ала. 1896 елда Олимпия уеннары яңадан уздырыла башлый. XX гасыр башында университетлар һәм көллиятләр каршында яшүсмерләр спорты бик тиз үсеп китә.

Хәзерге заман спорты

XX гасырда спортчыларга, югары нәтиҗәләргә ирешү өчен, спортның бер генә төрендә махсуслашырга, озаклап әзерләнергә, һәр көнне тренировка ясарга туры килә. Профессиональ спорт зур көч куюны таләп итә.

Ләкин профессиональ спорт һәвәскәрләрне бөтенләй кысрыклап чыгара алмады. Киресенчә, бүген соңгысы үсә бара. Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм спорт мәйданчыклары төзү кешеләрне һәвәскәр спортка кайтарды. Күпләр сәяхәт һәм туризм белән мавыга. Велосипед, байдаркалар ерак араларны үтәргә, табигать кочагында булырга сәламәтлекне ныгытырга мөмкинлек бирә.

XX гасыр ахырында яшьләр спортның иң җитез төрләренә (тимераяк, чаңгыда шуу, мотоцикл) тартыла башлады. Тау чаңгысы һаман саен популярлаша бара. Соңгы вакытта яшьләр роликлы конькида шуу белән мавыгалар. Спортның теннис, хоккей, футбол, волейбол, фигуралы шуу һәм башка күп төрләре үсеш кичерә.

Хәзерге яшүсмерләр спортның техник һәм хәрби төрләренә зур кызыксыну белән карыйлар. Кул сугышы алымнарын өйрәнүдән, парашютта сикерүдән, дельтапланда очып йөрүдән кем баш тартсын инде!

Техник ялның бер төре — тау велосипедларында йөрү (тау велосипеды гади велосипед һәм мопед арасында тора.

Сезнең шәһәрдә (авылда) яшүсмерләр арасында спортның кайсы төрләре иң популяр? Яшьләрдә алар нинди сыйфатлар тәрбияли?

Аның моторы юк, ләкин шиннарының калын һәм киң, шулай ук тормозының нык булуы, аңарда урман сукмакларында һәм сикәлтәләрдә куып йөрергә мөмкинлек бирә. Андый велосипедларның тизлеге — 18 дән алып 24 кә кадәр, шул карьерларда һәм таулы урыннарда узышырга мөмкинлек бирә).

Су спорты төрләреннән виндсерфинг — суда җилкәнле кечкенә тактада йөзү популярлаша. Виндсерфинг кешегә су стихиясе белән бернинди чагыштыргысыз берләшү тойгысы бирә. Серфер (ягъни такта) белән идарә итү тулысынча рулевой кулында, әмма күп нәрсә җилнең юнәлешенә бәйле. Виндсерфинг рулевое яхшы вестибуляр аппаратка ия, нык куллы һәм «салкын башлы» булырга тиеш.

Кызганычка каршы, барлык яшүсмерләр дә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнми, бу аларның сәламәтлегендә чагыла.

Хәзерге заман яшүсмерләре мәктәптән кайтуга диванга авалар, кагыйдә буларак, дәрес әзерләргә теләмиләр, телевизор кабызалар. Ә кайберләре, бусагадан керә-керешкә үк, әнисеннән яки әбисеннән: «Кая миңа ашарга?» — дип сорыйлар, аннары йорттагы иң яраткан нәрсә — компьютер артына утыралар һәм көчләп йокларга яткырганчы уен уйныйлар. Икенче көнне барысы да яңадан башлана. Нәтиҗәдә яңа буын вәкиле көзгедә үзенең берничә килограммга симерүен күрә яисә, парта артында утырганда, күз табибына барырга вакыт җиткәнлеген аңлый.

26 илдә үткәрелгән чагыштырып тикшерү галимнәргә яшүсмерләрне нәрсә күбрәк җәлеп итүен ачыкларга мөмкинлек бирде. Беренче урында күңел ачу индустриясе тора. Бу рәттә телетапшырулар карау алда бара (93%). Күпчелек яшьләр музыкаль видеофильмнарга, шулай ук спорт программаларына өстенлек бирә. Яраткан шөгыльләр арасында икенче урынны музыкаль язмалар тыңлау алып тора, аннары — өйдә фильмнар карау һәм киногa бару.

Тикшеренү барышында вакытны яратып үткәрүне очрашу кичәләре, спорт белән шөгыльләнү, телефоннан сөйләшү, кибеткә йөрү һәм өйдә утыру тәшкил итүе ачыкланды. Көн тәртибе шундый булганда күп вакытны спорт белән шөгыльләнүгә, һавада йөрүгә бирергә кирәк.

Кызыклы фактлар

Россия Фәннәр академиясе Социология институты хезмәткәрләре төркеме Мәскәү мәктәпләрендә 6—11 сыйныфларда укучы яшүсмерләр арасында сорау алу үткәрде. Укучыларның 5% ы үзенең сәламәтлек торышы — начар, 46% ы яхшы дип бәяли. Һәр дүртенче укучы җитди хроник авыруга ия булуы хакында әйтте. 80% баланың күрүе яхшы, 17% ы даими булмаса да күзлек кия (дөрес, өлкәнрәкләр категориясендә ул 22%), 3% ы даими рәвештә күзлектән йөри.

Режимны тотасызмы дигән сорауга сорашуда катнашучыларның чама белән 60% ы тискәре җавап бирде. Мәктәп балаларының өчтән бере режимны саклый, ләкин әллә ни төгәл үтәми. Ныклы режим буенча яшәүчеләр берән-сәрән генә, алары да түбән сыйныфларда. Уртача биш укучының берсе генә азмы-күпме эзлекле төстә зарядка ясый, 6—7 нче сыйныфларда алар 33%, ә өлкән сыйныфларда — нибары 12% кына. Сорашуда катнашучыларның өчтән ике өлеше зарядканы бик сирәк ясый яки бөтенләй ясамый.

Йомгак ясыйбыз

Спорт — буш вакытны уздыруның бер варианты. Һәвәскәр спорт белән шөгыльләнү үз-үзеңә куйган бәяне арттырырга, хәзерге мәктәп балаларының бик үк нык булмаган сәламәтлеген ныгытырга менә дигән мөмкинлек бирә. Хәзерге вакытта спортның бик күп төрләре популяр: традиционнары да (тимераякта, чаңгыда шуу, велосипедта йөрү), экстремальләре дә (парашютта сикерү, виндсерфинг).

Яшүсмерләрнең аралашу даирәсе сизелерлек киңәя, күп кенә уңай сыйфатлар барлыкка килә, характер ныгый.

Белемегезне тикшерегез

1. Борынгы вакытлардан алып безнең көннәргә кадәр спорт ничек үскән?

2. Кешеләр спорт белән нигә шөгыльләнә? Ул ни өчен бөтен заманнарда да популяр?

3. «Сәламәт тәндә сәламәт рух» дигән гыйбарәне ничек аңлыйсыз?

4. Профессиональ спорт һәвәскәр спорттан нәрсә белән аерыла?

5. Безнең заманда яшүсмерләр арасында нинди спорт төрләре популяр? Ни өчен?

Практикум

1. «Яшүсмерләрнең (малай һәм кызларның) спортка мөнәсәбәте» дигән тема буенча яшүсмерләр арасында сорашу үткәрегез. Аның буенча нинди нәтиҗә ясарга була?

2. Илебезнең (шәһәр, район, авылыгызның) иң күренекле спортчылары, халыкара олимпиадаларда җиңүчеләр турында хәбәр әзерләгез.



V бүлек

Яшүсмер һәм аның яшәү тирәлеге

§ 26–27. Шәһәр һәм авыл

Россиянең яшь гражданнары, бу китапны укучыларның 70% ы өчен яшәү тирәлеге булып шәһәр, ә 30% өчен поселок, авыл тора дисәк, мөгаен, ялгышмабыз. Статистика шундый. Шуңа күрә без хәзер шәһәр һәм авыл, аларның үсеше, архитектурасы, шәһәрләрнең кешелек тарихындагы роле, ә аннан соң иң якын яшәү тирәлеге — шәһәрдәге район, урам, йорт, фатир һәм әлеге төшенчәләр белән бәйле бар нәрсә турында сөйләшербез.

Шәһәр — ул гаять үзенчәлекле яшәү урыны. Шәһәр кешеләренең тормыш дәрәҗәсе һәм яшәү рәвеше авыл халкыныкына охшамаган, аларның үз манералары һәм гадәтләре, социаль мөнәсәбәтләр системасы да башка.

Шәһәр эволюциясе

Безнең планетада кешеләр инде 2 млн елга якын яши. Һәм шушы вакыт дәвамында алар авыл җирләрендә зур булмаган төркемнәр булып гомер кичергәннәр. Фәкать 5—6 мең еллар элек кенә эре авылларны (поселениеләрне) тәшкил иткән шәһәрләр барлыкка килгән. Шәһәр турында беренче тапкыр б. э. к. IV—III меңьеллыкларда искә алына. Түбәндәге борынгы сәүдә, кәсепчелек үзәкләре аеруча билгеле: Месопотамиядә — Ур, Вавилон; Мисырда — Мемфис, Фива; Һиндстанда — Мохенджо-Даро, Хараппа; Грециядә — Спарта, Афина. Шәһәр башлыгы булып йә шәһәрдәге төп храмның иң югары каһине, йә шәһәр ополчениесе җитәкчесе торган. XI—XII гасырларда Европаның иң эре шәһәрләре — Венеция, Флоренция, Рим, Париж, Лондон, Кельн, Новгород h. б.

Көнчыгыш һәм грек шәһәрләре

Борынгы Елгаара өлкәдә Ур, Лагаш яисә Вавилон кебек шәһәрләрдә зиккурат (күп баскычлы пирамида) рәвешендәге храмнарда һәм административ учреждениеләре булган патша сараенда тормыш кайнап торган.

Көнчыгыш шәһәрләреннән аермалы буларак, грек шәһәрләре үзәктән периферияга таба төзелгән. Анда төп элемент булып мәйдан — агора торган. Башта агора урыны, аннан соң шуннан китүче урам юнәлешләре һәм, ниһаять, шәһәрнең тышкы периметры билгеләнгән. Шәһәрне планлаштырганда агорага берләштерүче элемент роле бирелгән. Ул 300×150 м чамасы зурлыктагы мәйданны биләгән, берничә өлешкә бүленгән; көньяк өлеше һәр яктан биек колонналы галереялар белән уратып алынган, анда сәүдәгәрләр мәгълүмат алмашкан, судьялар хөкем иткән, чиновниклар эшләгән, укытучылар дәрес уздырган, гайбәтчеләр пышылдашкан.

Афинада баш храмнар, барлык суд һәм административ учреждениеләр, төп һөнәрчелек һәм сәүдә районнары, барлык шәһәр кварталлары һәм спорт белән шөгыльләнү урыннары, шулай ук һәйкәлләр агорада булган яисә аңа тоташып торган.



Элеккеге мәдәни мирасны саклап калу нигә кирәк? Сез фотода нинди борынгы шәһәр хәрабәләрен күрәсез?

Рим форумы

Грек агорасына хас дин һәм сәясәт, тарих һәм заманчалык катнашмасы Рим форумына да күчерелә.

Рим форумының барлыкка килүе тамашалар белән бәйле. Иң алдан алар гладиаторлар сугышы, күптән түгел вафат булган җәмәгать эшлеклеләре һәм башка мәгълүм шәхесләр хөрмәтенә ритуаль уеннар уздыру өчен төзелә.

Б. э. к. 46 елда Юлий Цезарь форумда берничә йөз пар — башлыча хөкем ителгән хокук бозучылардан, коллар һәм профессионаллардан торган — гладиаторларны күрсәтә. Алар Цезарьның үлгән кызы Юлия хөрмәтенә сугышалар. Уеннар дәүләт тарафыннан оештырыла һәм финанслана.

Урта гасырлар шәһәре

Шәһәр сәяси һәм дини хакимият тупланган, король, граф яисә епископ резиденциясе, монументаль корылмалар урнашкан, төп хәзинәләр тупланган бердәнбер урын була.

Авыл әле һаман шәһәр тормышына актив үтеп керә: шәһәрдә яшәүчеләр ярымкрестьян тормышы алып бара, шәһәр диварлары эчендә йөзем куаклары үсә, бакчалар, болын һәм кырлар яшелләнеп утыра. Терлек йөри, тирес өемнәре күренә. XIV гасыр башында шәһәрләрнең бик

азында, әйтик, Венеция һәм Миланда гына яшәүчеләр саны йөз меңгә җитә. Париж халкы 80 меңнән артмый. Беренче ранглы башка шәһәрләрдәге кебек үк, Брюгге, Гент, Тулуза, Лондон, Гамбург, Любекта 20 дән 40 меңгә кадәр кеше яши. Мәскәүдә XIV—XV гасырлар чигендә 30—40 мең кеше яшәгән.

Урта гасырлар шәһәре бары базар мәйданын гына белгән. Ул чорда базар мәйданына шәһәрнең эш үзәге итеп караганнар — ул товар алмашу гына түгел, мәгълүмат уртаклашу урыны да булган. Аның символы булып изге зат — шәһәр һәм монда даими уздырылган ярминкәнең яклаучысы хөрмәтенә корылган чиркәү (сирәк кенә собор) торган. Соңгысы — епископ үзе гәүдәләндергән рухи хакимлек символы, ә шәһәр чиркәве җирле феодал белән көрәштә үзидарәгә ирешкән шәһәрлеләрнең җиңүен чагылдырган.

Урта гасырлар башында мәйдан дөньяви (һәм, иң элек, сәяси) һәм дини тормыш үзәгенә әверелә. Мәсәлән, Флоренциядәге Изге Мария соборы һәм епископ сарае урнашкан собор мәйданы шәһәрнең бердәнбер үзәген тәшкил итә. Собор дин таянычы гына түгел, сәяси карарлар кабул итү урыны да булган, анда шәһәр Советы утырышлары узган.

Кеше торагы иң гади куыштан алып урта гасыр замогына, ә аннан шәһәр читендәге коттеджга һәм күпкатлы йортларга кадәр озын эволюция уза. Торак белән бергә шәһәрләрнең йөзе дә үзгәрә.

Хәзерге заман шәһәрләре

Хәзерге заман шәһәрләре кече (яшәүчеләр саны 50 меңгә кадәр), урта (50—100 мең), эре (250—500 мең), бик эре (500 мең — 1 млн) һәм миллионер (1 млн нан күбрәк) шәһәрләргә бүленә. Хәзер 25 млн кеше яшәгән Мехико иң зур шәһәр санала. Күп кенә эре шәһәрләрнең юлдашлары барлыкка килә. Еш кына шәһәрләр һәм аларның юлдашлары берләшә һәм **мегаполис** үсеп чыга. Бүген нык үскән илләрнең күпчелек халкы шәһәрләрдә һәм мегаполисларда яши.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Шәһәр яны зоналары — шәһәрләргә тоташкан һәм алар белән тыгыз функциональ, мәдәни-көнкүреш һәм башка бәйләнештә торган территорияләр. Шәһәр яны зоналары эре шәһәрләр тирәсендә аеруча нык үскән. Эре шәһәрләр янындагы зоналарда шәһәр яны, шәһәр юлдашлары, ял зоналары, авыл хуҗалыгы җирләре урнашкан.

Шәһәр яны — шәһәргә якын гына торган, аның белән тыгыз элемтәсе булган торак пунктлар. Еш кына шәһәр яны — рәсми төстә шәһәр чикләренә кертелмәгән периферия өлеше.

Юлдаш шәһәр — эре шәһәр янында үскән һәм аның белән бердәм система тәшкил иткән шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок.

Россия Федерациясендә 1109 шәһәр бар, аларда халыкның 74% ы яши. Аларның бер өлеше күптән түгел барлыкка килгән, икенчеләре XI—XII гасырлар елъязмаларында ук искә алына. Россиядә халык саны 12 меңнән ким булмаган һәм 85% кешесе авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнмәгән поселение шәһәр статусы алырга мөмкин. Рәсми хөкүмәт күрсәтмәләре белән 383 шәһәр поселениесе тарихи разрядка кертелгән. Элек-электән кече һәм урта шәһәрләр, илнең рухи, мәдәни һәм административ үзәкләре генә булып калмыйча, авыл, төрле һөнәрләр һәм сәүдә арасында элемтәче ролен дә үтәгән. Хәзер шәһәрләрдә, гадәттә, сәнәгать предприятиеләре күп һәм алар мәдәни үзәкләр булып тора.

Шәһәрләр, кешелек цивилизациясе кебек үк, катгый законнар буенча үсә. Зур шәһәр кайчандыр ныгытылган лагерь, су яисә коры юллар чатында яткан товар алмашу үзәге буларак барлыкка килгән. Соңрак ул зур бер төбәкнең сәнәгать үзәгенә, тимер юл һәм шоссе магистральләренең күптармаклы челтәре узелына әверелә.

Шәһәрнең урнашуын һәм планын, барыннан да бигрәк, табигать шартлары һәм әлеге урынның рельефы билгеләгән. Табигать факторлары арасында иң мөһиме — елга. Елга борылмасындагы яхшы якланган биек яр, елга һәм аның кушылдыгы арасындагы таулы өчпочмак беренче төзелеш мәйданчыгы — шәһәр үсешенең башлангыч ноктасы булып хезмәт иткән. Субүләрләр, текә сөзәк ярлар, уйсулыклар һәм кечкенә елга кушылдыклары урам челтәрен формалаштырган.

Европа шәһәрендә урамнар йә хөкемдар сарае, йә гражданлык хакимияте үзәге булган шәһәр ратушасы урнашкан төп мәйдан тирәсендә планлаштырылган. Тора-бара шәһәрне проспектлар кисеп үткән. Көнбатыш шәһәренең ачык урамнары ислам мәдәниятенең бормалы, тыгыз, аулак тыкрыклы урамнарына охшамаган.

Көнбатыш шәһәре урамының тышкы күренешен анда йөрүче халык кына түгел, корылмалар архитектурасының төрлелеге (тәрәзәләре урамга караган зур йортлар, фасадлар) дә җанландыра. Киресенчә, ислам мәдәниятенә фасад төшенчәсе хас түгел. Аның урынында безнең алдыбызда тип-тигез дивар, ә йорт үзе эчкә карап тора. Хәтта өстәге берд әнбер тәрәзәгә дә рәшәткә куелган. Соңрак аның урынына чак кына чыгып торган кечкенә генә балконнар ясый башлыйлар, аларны агач планкалар белән шулай итеп томалыйлар, урамда ни булганын күзәтеп була, ә үзең күренмисең.

Һәр шәһәрнең үз бизәге бар. Ул манаралы һәм киң диварлы борынгы кремль дә, гаҗәеп матурлыгы белән

Сез әлеге рәсемдә тасвирланган шәһәрдә яшәргә теләр идегезме? Үз фикерегезне нигезләгез.

күзләрне иркәләүче иске монастырь да, антик хәрабәләр яисә оригиналь заманча планировка да булырга мөмкин.

Кызыклы фактлар

Троядан мең яшькә өлкән

Көньяк Уралда, галимнәр фикеренчә, 3 мең 700 ел элек яшәгән үзенчәлекле «шәһәрләр илен» (алар барлыгы 30 лап) ачу дөньядагы археологик сенсацияләрнең берсе булды. Әлегә бер *Аркаим* шәһәре казып чыгарылды. Әлеге урын аша сузылган тау сыртына карап ул шулай аталды. Шунысы кызык: бу шәһәр кешеләре төзелеш материалы итеп кызыл балчыктан, комнан һәм үлән компонентларыннан торган, аерым бер ысул белән кысылган табигый «бетон»нан киң файдаланганнар.

Аркаимлылар шулай ук менә дигән металлурглар булганнар. Алар югары сыйфатлы бронза кою серләрен белгән, моңа белгечләр реконструкцияләнгән мичләрнең берсендә эксперименталь кою үткәреп ышандылар. Металл хезмәт кораллары, сугыш коралы, ике көпчәкле арбалар ясауга киткән.

Шәһәр һәм урбанизация

Җир шарында шәһәр халкының саны һаман арта, ә авыл халкыныкы кими бара. Бу процесс **урбанизация** дип атала. Сез бу сүз белән радио һәм телевидение тапшырулары, газета һәм китаплар аша таныш инде.

Урбанизация йөзләрчә километрга сузылган шәһәрләр һәм шәһәр яны гына түгел. Ул халык белән шыгрым тулы электричкалар яисә күктә үкереп очучы авиалайнерлар гына да түгел.

Урбанизация традицион җәмгыятьтән хәзерге заман җәмгыятенә күчүне аңлата. Ул яңа төр шөгыльләр тудыра. Элеккеге извозчиклар урынына таксистлар килде. Тегеләре дә, болары да — шәһәр цивилизациясе билгесе, ләкин төрле цивилизацияләрнеке. Извозчик — иске шәһәрнең типик фигурасы, таксист — хәзерге заманныкы.

Истә калдырырга киңәш итәбез

Урбанизация (*лат.* urbanus — шәһәрнеке) — җәмгыять үсешендә шәһәрләрнең роле күтәрелү һәм шәһәр халкының өлеше арту процессы, ул шәһәрчә яшәү рәвешенең халыкның барлык катлауларына таралуына китерә.

Урбанизация шәһәрчә яшәү рәвеше, халыкның грамоталык дәрәҗәсе күтәрелү, аның үз-үзен тотышы һәм урамда үзара мөнәсәбәтләр яхшыру белән бәйле. Шәһәр һәрвакыт йортларны, урамнарны һәм скверларны дөрес планлаштыруда лидер булды.

Россиядә иң беренче эре шәһәр төзелеше реформасын XVIII гасырда Бөек Екатерина уздыра. Аның указы нигезендә шәһәрләр план буенча төзелергә һәм үсәргә тиеш булалар. Патшабикә җирле губерна һәм өяз хакимиятләренә шундый планнар булдыруны йөкли һәм Россия шәһәрләренең стихияле үсешен дәүләт җайга салуы кысаларына кертү мөмкинлеген таба. Һәр шәһәр үзенең үсеш перспективаларын яхшы күрә. Ул гына да түгел, һәр катлау өчен торак йорт типлары билгеләнә. Һәр урамга — аерым таләпләр. Шәһәр өчен теге яки бу урамның һәм мәйданның әһәмиятеннән чыгып катгый таләп куела: бу урамда бер катлы йортлар төзелә, ә икенчесендә — икешәр катлы. Казна корылмалары аерым үрнәкләр буенча төзелергә тиеш була.

Шәһәр тормышы сыйфаты

Тормыш сыйфаты — ул шәһәрдә көн күрү шартларының уңайлылыгы, яшәү иминлеге. Кайсы шәһәрдә яисә илдә кешеләрнең яхшырак, ә кайсы илдә начаррак яшәвен күрсәтә. Аны билгеләгәндә галимнәр сәламәтлеккә, мөлкәткә, керемнәргә, мәдәнияткә, куркынычсызлыкка, әйләнә-тирә мохиткә игътибар итәләр.

Галимнәр, төрле шәһәрләрне чагыштырганда, тормыш сыйфатын бәяләү өчен, төрле күрсәткечләрдән файдаланалар: азык-төлекнең бәясе, торак шартлары (бер бүлмәдә яшәүчеләр саны), торакның сыйфаты (суүткәргечле һәм электрлы йортлар һәм фатирлар саны), элемтә (100 кешегә телефоннар саны), мәгариф (мәктәптә укучы балаларның өлеше), сәламәтлек саклау (яңа туган 1000 баладан үлүчеләр саны), җәмәгать куркынычсызлыгы (100 мең кешегә бер елга туры килгән үтерүләр саны), тынлык (тыштагы тавыш дәрәҗәсе), урам хәрәкәте (пик сәгатьләрендә уртача тизлек километрларда), һаваның чисталыгы.

Шәһәр тормышының уңай һәм тискәре яклары

Шәһәр тормышына хас сыйфат — ерак араларга көн саен йөрү һәм автобус, метрода кысанлык аркасында транспорттан ару. Авылдагыга караганда киеренкерәк хезмәт ритмы, чиратта тору, даими рәвештә төркемдә (урамда, транспортта, кибеттә) булу шулай ук нервларга артык йөк булырга мөмкин.

Эре шәһәрдә яшәүчеләр юлга 1 сәгатьтән артык вакыт сарыф итәләр. Шул ук вакытта галимнәр санап чыгарганнар: 1 сәгать — кешенең шәһәр транспортында йөрү вакытының ахыргы чиге. Аннан соң транспорттан ару синдромы: йокысызлык, ярсучанлык, игътибарсызлык башлана.

Хәзерге шәһәр кешесе цивилизация уңайлыкларыннан башка яши алмый, әмма шул ук вакытта табигатьтән бирелгән бар нәрсәсен югалта. Ул аз йөгерә, аз йөри, аңа физик күнекмәләр җитми. Аның адреналины аз бүленеп чыга, шуңа кан әйләнеше зәгыйфьләнә, йөрәге начаррак тибә. Аңа саф һава җитми.

Шәһәрлеләрнең аз хәрәкәтле яшәү рәвеше кешенең тышкы кыяфәтендә дә чагыла. Тулы гәүдәле кешеләрнең күбесе — шәһәр халкы. Симерүдән интеккән кешеләрнең актив тормыш белән яшәмәве ачыкланган. Әгәр дә күбрәк хәрәкәтләнсәң, спорт белән шөгыльләнсәң, организмда матдәләр алмашы арта, ә май катламы кими.

Яшүсмерләрнең 10—15% ы, чыннан да, симерүдән зыян күрә. Симерү еш кына йөрәк-кан тамырлары авыруына,

кан басымының күтәрелүенә китерә, тирә-юньдәгеләр белән мөнәсәбәтләрдә тискәре чагылыш таба.

Шәһәр цивилизациясе безнең туклану гадәтенә көчле үзгәрешләр алып килде.

Яшүсмерләр иртән ашамыйлар, йокыны өстенрәк күрәләр, аннары «аннан-моннан» гына капкалыйлар.

Көндезге рационның якынча дүрттән бер өлеше капкалаудан тора: майга, углеводларга, шикәргә бай конфет, печенье, бутербродларны бара-барышка кабып җибәрү. Алар сыйфаты буенча да, күләме буенча да нормаль туклануны алыштыра алмый.

Ризыкта яшелчә, сөт, сыр һәм ит җитми.

Сәламәт туклану турындагы белемнәр җитмәү дөрес булмаган туклану гадәте формалашуга китерә.

Вакыт әхлакны гына түгел, кешеләрнең авыруларын да үзгәртә. Кайчандыр беренче урында җәрәхәтләр һәм яралар торган, гасырлар узуга, эпидемия һәм йогышлы авырулар үлемнең беренче сәбәпчеләренә әверелгән. Вакытлар узу белән, фәнгә таянып кеше йогышлы авыруларны да чагыштырмача җиңел кичерә башлаган. Ләкин цивилизация бик тиз үсә...

Кешене авыр физик хезмәт белән бәйле авырулардан арындырып, хәзерге цивилизация аңа яңа авырулар алып килә. Шуларның берсе — кулларның компьютер авыруы, ул әле «туннель синдромы» дип тә атала. Баксаң, клавишлар, аларга басканда панель төбеннән сикереп китеп, бармак очларына чак кына сизелерлек итеп сугып алалар икән. Компьютерда һәр көнне озаклап эшләгәндә бу очлык тукымаларының дистрофик үзгәрешләренә китерә. Мускуллар зәгыйфьләнә, сыгылмалылыгын югалта, тиз арыйлар. Бу нервлар һәм кан тамырлары кысылганлыктан килеп чыга.

Шәһәр һәм авыл

Шәһәр авылдан биналарның кысанлыгы, ишегалларының, проспект, паркларның күп, шулай ук шосселар, вокзаллар булу белән аерыла. Монда сууткәргечләр, үзәктән җылыту эшләп тора...

Шәһәр тирәлеге зарарлы һәм канцероген матдәләр белән авылга караганда күбрәк пычранган. Чишмә суы урынына

хлорлы су, автомашиналар һәм заводларның бик күп булуы аркасында, шәһәр һавасы газлы, тавыш күп һәм атмосфера тузанлы. Мондый мохит кеше организмы өчен, авылдагы традицион тирәлек белән чагыштырганда, ясалма һәм гайре табигый. Эш шунда ки, ул әле соңгы йөзьеллыкта гына барлыкка килде һәм биологик яктан кеше аңа ярашырга өлгермәде. Сәламәтлекнең какшавы һәм шәһәр кешеләренең барлык чаралар белән аны ныгытырга омтылуы әнә шуннан килә.

Әгәр авыл кешесе бер үк урында яшәсә, эшләсә һәм ял итсә, шәһәрдә — киресенчә. Мәдәни һәм бизнес учреждениеләренең күбесе шәһәр үзәгендә, ә күпчелек кеше йокы районнары дип аталган урында, шәһәрнең читендәрәк яши. Шуңа да шәһәрлеләргә җәмәгать яисә шәхси транспортта ешрак һәм озаграк йөрергә туры килә. Шәһәр кешесе башка шәһәр һәм чит илләргә дә ешрак бара.

Шәһәрләр барлыкка килү — кешелек үсешендә гаять зур адым. Шәһәр — прогрессны этәрүче көч ул. Шәһәрләр

үсү белән, җинаятьчелек, хәерчелек кебек тискәре күренешләр арта барса да, аның кеше һәм мәдәният үсешендәге әһәмиятен бәяләп бетерү мөмкин түгел. Шәһәр тормышының төп үзенчәлеге эшчәнлекнең зур булмаган территориядә тупланышыннан гыйбарәт.

Авылда кеше күп түгел, булганнарының күбесе — якын һәм ерак туганнар. Шәһәр турында шуны ук әйтеп буламы?

Авыл тар, тарихи барлыкка килгән мәгънәдә — ул зур булмаган җирлек (аннан да кечерәкләре выселка, пүчинкә, хутор, тарлау һ. б. дип аталган).

Авыл (село) — славяннарда торак җирләрнең иң борынгы атамаларының берсе. Киев Русенда ул — кенәзнең шәһәр яны утары. Соңрак русларда — крестьяннарның чиркәве дә булган эре торак җире. Украиннарда һәм белорусларда, гомумән, авылга (деревня) тиң торак җир.

Авыл һәм шәһәр кешенең тору урыны үсешендә башлангыч һәм ахыргы ике ноктаны тәшкил итә. Кешелек җәмгыятенең тарихы авыл җирлегеннән башлана, шәһәр белән тәгәлләнә.

Шәһәр зуррак булган саен, иҗтимагый тормышта авылда булмаган иҗади берләшмәләр, сәнгать студияләре, иҗади интеллигенция йортлары зуррак роль уйный.

Авыл хезмәтенең бер үзенчәлеге — ел әйләнәсендә эш күләменең тигезсез бүленеше: җәен һәм язын — бик киеренке хезмәт (кыр эшләре), кышын — тыныч тормыш.

Крестьянның бөтен тормышы: аның хезмәте, буш вакыты, гаилә тормышы, мәдәни мавыгулары бөтен авыл күз алдында үтә. Акрынлап анда тупланган ябык община рухы формалаша. Ягъни бөтен кеше бер кеше өчен һәм бер кеше бөтенесе өчен.

Авылдашлар үзара тыгыз бәйләнештә торалар һәм берберсенә булышалар. Әти-әнисе кырда, печәндә яисә фермада булганда баланы эшләми торган күршеләр карап тора. Бала тәрбияләү, кәләш яисә кияү сайлау һәм башка мөһим мәсьәләләр дә күмәк тикшерелә. Алар буенча җәмәгать фикере барлыкка килә, кеше аның белән санашырга тиеш.

Соңгы вакытта авыллар эреләнде, шәһәр тибындагы авыллар барлыкка килде.

Шәһәр: кешеләрнең читләшүе һәм тиз үзгәрешләрнең йогынтысы

Шәһәрләрдә яшәүче хәзерге заман кешеләрендә әйләнә-тирәдәгеләр белән дистанция тоту манерасы да тәрбияләнә. Һәм хәзерге кешеләрдә генәме икән? Мәсәлән, японнарның бигрәк тә җәмгыятьтә үзеннән өстенрәк торган кешегә карата нәзакәтлелеге бу аны шәхсән рәнҗетүдән курку, һәм ул кешеләрне аеруча әдәпле булырга мәҗбүр итә. Балаларда зарури дистанция тәрбияләүнең тагын бер ысулы — чит кешеләр белән бәйләнешкә керүдән качарга өндәү, алар белән белмәгән урыннарга бармаска, ят кешегә ишекне ачмаска һ. б. өйрәтү. Таныш булмаган, ят нәрсәләрдән куркып хәвефләнү, барыннан да бигрәк, җәмгыятьтә җинаятьчелеккә каршы көрәшнең начар булуы нәтиҗәседер ул, мөгаен.

Көндәлек тормышта хисләрне яшерү икенче натурага әверелергә мөмкин. Ул чагында бик күп бәлаләрнең сәбәбе әнә шул гадәттән котыла алмауга нигезләнәчәк.

XX гасырның беренче яртысында Европа илләренең күпчелегендә һәм АКШта авыл халкы зур шәһәрләргә күченә башлый. Күченүче фермерлар һәм крестьяннар ташкыны арта бара һәм 60 нчы еллар уртасына ул үзенең иң биек ноктасына җитә. СССРда иң күп күченүләр 70 нче еллар ахырына туры килә. Аннары бу процесс кими бара. Европа илләрендә ул туктала, ә 70—80 нче елларда шәһәрлеләр кабат шәһәр янына һәм авыл җирләренә кайта башлый. Ләкин анда эшләү һәм яшәү өчен түгел, бары тик ял итү өчен генә.

Шәһәргә күченү кешеләр тормышын тамырдан үзгәртте. Шәһәрләрдә халыкның артык күп булуы кешеләрнең якын мөнәсәбәтләренә киртә куя, аларны аера төшә. Бер йортта яшәгән күршеләр дә кайчакта бер-берсен бөтенләй белми. Бер-беренә якынаю ихтыяҗы сизелми диярлек. Миллион кешесе булган шәһәрдә кеше үзен ялгыз итеп тоя.

Шәһәр бик күп социаль проблемалар китереп чыгара: кысанлык, ярлылык, җинаятьчелек. Шәһәрдә тормыш бик катлаулы, ул стресслар, шик-шөбһә һәм коткылар тулы. Ләкин шәһәр фәкать тискәре йогынты гына ясый дип булмый. Шәһәрдә авылдагыга караганда яхшы белем алу,

әйбәт ял итү, мәдәни кыйммәтләр белән аралашу мөмкинлеге зуррак.

Авыл җәмгыятеннән шәһәргә күченү, ягъни барысы да бер-берсе белән таныш булган бердәм общинадан үзара элемтәләр шунда ук югалган зур шәһәргә күчеп килү читләшүгә бигрәк тә көчле этәргеч бирә дип санала. Шәһәрлеләр, танышларның тар бер даирәсеннән гайре, беркем белән дә чын йөрәктән аралашмыйлар һәм дуслашмыйлар. Чыннан да, шәһәрдә яшәүче йөзләгән мең кеше белән дуслашып та булмый инде. Авылда кешеләр бер-берсен танып белә һәм даими аралаша.

Читләшү бер яктан — яхшы, икенче яктан — начар. Аның яхшы ягы шунда: синең шәхси эшләреңә берәү дә тыгылмый. Ничек яшисең килсә, шулай яшисең. Шәхси тормыш иреге — цивилизациянең бик зур казанышы ул. Авылда исә бөтенесе бар нәрсә турында белеп тора һәм контрольдә тотыла. Ни генә кылсаң да, күршеңә ни генә әйтсәң дә, имеш-мимеш бөтен авылга тарала. Аның киресе авылда үзара ярдәм итешү көчле, кешеләр бер-берсенә битараф түгел.

Бүгенге яшьләр көчле техник прогресс шартларында яши. Мөгаен, бер генә җәмгыятьтә дә яңалыкларны хәзергедәй югары бәяләмәгәннәрдер. Узган йөзьеллык башыннан яңадан-яңа ачышлар ясала: электр, радио, телевидение, автомобиль, самолет, атом-төш энергиясе, ракета төзелеше, компьютер, лазер техникасы һәм роботлар. Һәр яңа ачыш үз чиратында техниканың тагын да камил буынын булдыруга китерә. Техник прогресс миллионлаган кешенең тормышын үзгәртте. Әйтик, автомобиль барлыкка килү кешегә үзенең эш урыныннан шактый еракта яшәргә мөмкинлек бирде. Алар бер урыннан икенчесенә җиңелрәк күчеп йөри башладылар, шул исәптән яшүсмерләр дә еракта яшәүче яшьтәшләре белән аралаша. Илебезнең бөтен территориясен шоссе һәм тимер юллар челтәре чолгап алды. Ул төрле илләр, төрле шәһәрләр, шулай ук шәһәр һәм авыллардагы кешеләрнең үзара аралашуын киңәйтте. Күп миллионлы пассажирлар агымнары минут саен илебезнең гаять зур киңлекләре буйлап төрле юнәлешләрдә хәрәкәт итә. Хәзерге заман

яшәү рәвешен «көпчәк өстендәге тормыш» дип атарга мөмкиндер.

Шәһәр халкының артуы мегаполислар — тоташ шәһәр кварталлары һәм сәнәгать объектлары барлыкка килүгә этәргеч бирде. Күп кенә шәһәрләр, авылларны юкка чыгарып һәм әйләнә-тирә мохитне пычратып, гамәлдә кушылып беттеләр инде. Табигать мохите генә түгел, социаль климат та нык үзгәрде һәм алдан фаразлап булмаслыкка әверелде. Шәһәрләр тизрәк үскән саен, анда торучылар өчен җәмәгать тәртибен һәм экологияне саклауны күзәтү катлаулана бара.

Кискен үзгәрешләр яшь буынга тирән йогынты ясый. Яшьтәшләреннән калышмас һәм киләчәктә үзләрен ышанычлырак хис итү өчен, хәзерге яшүсмерләр яңа технологияләрне үзләштерүгә күбрәк вакыт бирергә тиеш.

Тормышыбыздагы зур үзгәрешләргә яшь буын, гадәттә, өлкәннәргә караганда күпкә тизрәк җайлаша. Алар вакыйгалар калейдоскобына күнегәләр, аннары үзләре дә аңа тартылалар. Әгәр нәрсәдер озак кына үзгәрми торса, искегә алмашка шунда ук яңа нәрсә килмәсә, алар үзләрен уңайсыз хис итә башлый. Бөтен нәрсәдә — хөкүмәт алышынуда, әйберләр, шартлар, дуслар, тойгылар, ә кайчакта инанулар үзгәрүдә дә шулай. Шөбһәләнү хисе барлыкка килә. Яшүсмерләр бүгенге көн белән яшәүне өстен күрә.

Йомгак ясыйбыз

Һәр торак пунктның, эре шәһәрме ул яисә зур булмаган авылмы, үз үзенчәлеге бар.

Шәһәрдә яшәүчеләр саны арта, авыл халкы кими.

Шәһәрнең дә, авылның да уңай һәм тискәре яклары бар.

Шәһәр һәм авыл кешеләренең аерым яшәү рәвеше, үз манералары һәм гадәтләре, үз аралашу системасы.

Белемегезне тикшерегез

1. «Шәһәр», «шәһәр яны зонасы», «юлдаш шәһәр», «урбанизация» төшенчәләрен аңлатыгыз.

2. «Минем шәһәрем» («Минем авылым») дигән темага зур булмаган хәбәр әзерләгез.

3. «Мин шәһәрдә яшәргә телим, чөнки...», « Мин авылда яшәргә телим, чөнки...» җөмләләрен дәвам итегез.

4. Шәһәргә күченеп килгән авыл кешесен нинди кыенлыклар көтә? Ә авылга килгән шәһәр кешесен?

5. Шәһәр һәм авыл кешесенең җыелма портретын төзегез.

6. «Шәһәр — патшалык, ә авыл — җәннәт», «Шәһәр хикмәтле: адым саен ризык һәм эчемлек», «Авылда күңелле яшәп булмас» дигән гыйбарәләрне ничек аңлатып була?

Практикум

1. «Борынгы Рим буйлап сәяхәтем», «Борынгы Афина буйлап сәяхәтем», «Урта гасырлар шәһәре буйлап сәяхәтем», «Хәзерге заман шәһәре буйлап сәяхәтем» дигән темаларның берсенә кечкенә хикәя языгыз.

2. Ни өчен хәзерге шәһәрләрдә тарихи өлешне (урам, бина, храмнарны) сакларга тырышалар?

3. Сез еш һәм озаклап җәяү йөрисезме? Ә сезнең әти-әниегез, туганнарыгыз, дусларыгыз? Сезгә төшкән физик йөкләнеш (нагрузка) җитәрлек дип раслый аласызмы? Әгәр юк икән, сәбәп нәрсәдә?

4. Берәүләр шәһәрне җинаятьчелек оясы һәм XX гасыр чумасы дип саный. Икенчеләр шәһәрләрдә архитектура һәйкәлләре һәм авылдагыдан уңайлырак шартлар күрә. Ә сезнең өчен, гомумән, шәһәр һәм үзегез яшәгән шәһәр нәрсә ул?

5. Хәзерге заман тормышында нинди үзгәрешләр күрергә мөмкин? «XXI гасыр авылы» дигән проект өстендә эшләгез.

6. «Киләчәк шәһәре» проектын эшләгез.

28–29. Минем йортым, минем торагым

Шәһәрдәге кебек үк, авылда да торак гаять мөһим роль уйный. «Минем йортым — минем ныгытмам» дип, тикмәгә генә әйтмиләр шул. Әлеге ныгытмада (крепостьта) без вакытыбызның 70% ын уздырабыз. Микрорайон һәм тирә-юньдәге мәйданнар торакның дәвамы булып хезмәт итә. Бу нәрсә һәм без анда үзебезне ничек хис итәбез?

Без нинди киңлектә яшибез

Урамнар һәм мәйданнар белән бүлгәләнгән күзгә күренеп торган мәйданнар гына түгел, күренмәгәннәре дә шәһәрне тәшкил итә. Соңгысын күреп, аңа орынып яисә аны бер урыннан икенче урынга күчереп булмый. Аны **социаль мәйдан** дип атыйлар, ул, физик мәйдан кебек үк, төгәл чикләр белән бүленгән, аларны бозу гаепләнә яисә

бозган өчен җәза бирелә. Кешегә булырга туры килгән өч территорияне аерып карарга мөмкин:

- иҗтимагый;
- өй;
- шәхси территорияләрне.

Иҗтимагый территория — бу шәһәр мохитендә яшәгән барлык кешеләргә керергә рөхсәт ителгән урын: шәһәр урамнары һәм почмаклары, скверлар һәм мәйданнар, тимер юл һәм аэровокзаллар, торак йортлар һәм ишегаллары, баскычлар, лифтлар, подъездлар. Иҗтимагый территория — бу шулай ук йорт эчендәге мәйдан, клуб, түгәрәкләр, спорт бинасы.

Монда кеше үз тәртибен гомуми кабул ителгән нормалар һәм кагыйдәләр белән килештерә, башка кешеләрнең ныклы күзәтүендә була. Мондый кагыйдәләр билгеле бер гамәлләрне (тәмәке тарту, спиртлы эчемлекләр куллану, этләрне чыгарып йөртү) йә җәмәгать урыннарында мәгълүм бер категория затларның (мәсәлән, исерекләрнең) булуын чикли яисә бөтенләй тыя. Кичен шәһәр урамнарын милиция патруле саклый. Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре шикле кешеләрнең паспортын тикшерә, тәртипкә чакыра һәм тәртип бозучыларны бүлекчәгә китерә, шәһәр паркының теләсә кайсы яшерен почмакларына кереп карый ала.

Өй территориясе — бу гаилә мәнфәгатьләре белән һәм шәхси ихтыяҗларны канәгатьләндереп яши торган урын. Монда кеше үзен иреклерәк итеп тоя. Өйдә без физик һәм әхлакый көчебезне торгызабыз, шәһәр ыгы-зыгысыннан ял итәбез, укыйбыз, телевизор карыйбыз, сөйләшәбез, көләбез, сикерәбез, дәрес әзерлибез һәм иҗтимагый территориядә эшләргә мөмкин булмаган башка бик күп үзебезгә кирәкле гамәлләрне башкарабыз.

Шәхси пространство кешене чолгап алган һәм беркем дә бәреп керә алмаган, күзгә күренмәс чикләр белән аерылган өлкә буларак билгеләнә. Безнең һәркайсыбыз кеше иң күп йөргән урыннарда шәхси пространство саклауның тормышчан мисалларын искә төшерә ала: скверда йөрүчеләр, кагыйдә буларак, бер-берсеннән ераккарак утырырга тырыша. Метро һәм автобус пассажирлары да

Параграфтагы рәсемнәрне карагыз. Элеккеге һәм хәзерге заман торакларындагы охшаш һәм аерым якларны табыгыз.

нәкъ шулай эшли. Фатирда шәхси пространство — эти кабинеты, балалар бүлмәсе, әти-әнинең йокы бүлмәсе.

Гаиләнең иң абруйлы әгъзасы — аның башлыгы. Еш кына ул әти кеше була. Ул гаилә эчендәге тормыш эшчәнлеген контрольдә тота, «яшәү пространствосын» бүлә. Ә кайчакта бу рольне әни кеше дә башкара. Элеккеге вакытларда гаилә башлыгы йортта иң зур шәхси пространствога ия була. Кагыйдә буларак, балаларга һәм картларга иң кечкенә пространстволар элэгэ.

Иҗтимагый, өй һәм шәхси пространстволарга бүленеш шартлыча гына, еш кына алар урыннарын алмашалар.

Иҗтимагый, өй яисә шәхси пространство җитмәгәндә, бик күп өстәмә проблемалар барлыкка килә. Шулардан иң мөһиме — артык тыгыз урнашу. Хәзерге заман шәһәр фатирында, яраткан эшең белән шөгыльләнү өчен, мәйдан җитмәү кешеләрнең артык күплегенә мисал булып хезмәт итә ала. Шуңа бәйле рәвештә тормыштан яшертен яисә ачыктан-ачык канәгатьсезлек килеп чыга. Ул шулай

яшерелгән булырга мөмкин, кешенең нидән канәгать булмавын кинәт кенә аңлый да алмыйсың.

Гаилә составы да мөһим урын тота. Әйтик, күп балалы гаиләдә кешеләр тормышын контрольдә тоту һәм оештыру, балалар инде зур үскән яисә бөтенләй булмаган гаиләдәгедән күпкә катлаулырак. Йортта кеше күп булган саен, балалар тәртибенең идарә ителмәве турындагы хис көчәя бара. Нәтиҗәдә торакның артык тыгызлыгы өстәмә ярсыткыч булып хезмәт итә.

Һәркемнең үз шәхси пространствосы булырга тиеш. Кеше артык күп яшәгән фатирда бу сакланмый. Шул вакытта бала үзенә уңайлырак урнашу җаен эзли. Нәтиҗәдә барлык торак мәйдан уен мәйданчыгына әверелә.

Без яшәгән йорт

Без яшәгән йорт — дүрт дивар һәм баш өстендәге түбә генә түгел ул. Барыннан да элек, ул — кешенең яшәү мохите, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр һәм элементләрнең үрелеп баруы. Кешеләр яңа йортка күчкәндә, аларны фатир өчен түләү күләме, гомуми метраж, санузелның бергәме, аерыммы булуы, лоджиянең зурлыгы һ. б. гына түгел, шәһәрнең тарихи үзәгеннән ераклыгы, районда медицина һәм көнкүреш хезмәте күрсәтүнең уңайлыгы, ә хәзер экология, җинаятьчелекнең торышы да кызыксындыра. Тору урынының уңышсыз булуы кәефне бозып кына калмый, физик көчне торгызуда, ял һәм буш вакытны уздыруда да чагыла.

Торак эволюциясе

Вакытлар узу белән, торакның планировкасы да катлаулана: көнкүрештә кулланылган биналар (йокы бүлмәләре, кухнялар, ирләр һәм хатын-кызлар яклары) аерылып тора.

Шәһәр халкының артуы һәм җир кишәрлекләренең кыйммәтләнүе нәтиҗәсендә тар гына коесыман ишегалдысы булган йортлар корыла башлый. Йортларда торак бүлмәләр кояш нурларыннан һәм җилләтүдән мәхрүм

Кызыклы фактлар

Утрак тормышлы кешеләрнең беренче йортлары аучылар һәм ризык җыючыларның вакытлы торагын хәтерләткән түгәрәк корылмалардан гыйбарәт була. Түгәрәк рәвешендәге фундаментта таяклардан нигез куялар һәм аны тире яисә салам белән томалыйлар. Утрак тормышта яшәүчеләр тиздән балчык йортлар төзи, ә соңрак ныклы таш фундамент сала башлыйлар. Җимерелгән яисә янган йорт урынында яңа торак төзегәндә, фундамент астындагы мәйданчыкны кызыл балчык белән сылап тигезлиләр.

Соңрак түгәрәк корылмалар урынына турыпочмаклы йортлар барлыкка килә, аларга янкорма өстәп, торак мәйданны киңәйтергә мөмкин була. Кагыйдә буларак, ишекләр җир тигезлегеннән өстәрәк тора. Кайчакта керү юлы яссы түбәдә урнаша, шуңа йортка агач баскыч буйлап кына керергә мөмкин була. Идәнне тыгызланган кызыл балчыктан ясыйлар, ә диварларны гипс белән агарталар. Мондый йортта яшәүчеләр чыптада яисә эскәмиядә йоклыйлар, ризыкны махсус билгеләнгән урында әзерлиләр. Борынгы вакытларда ук авыллар ныгытыла. Гадәттә, авыл тирәли канау казыйлар һәм вал күтәрәләр.

була, фатирларның бер өлеше дымлы ярымподвалларда урнаша.

Борынгы Римдагы Табиб йорты дип аталган корылма — моның типик мисалы. Аның бүлмәләре эчке ишегалдына (атриумга) чыга. Түбәдә яктылык коесы урнашкан, аның аша яңгыр суы ишегалды уртасындагы кечерәк кенә бассейнга агып төшә.

Б. э. к. I гасырда Римда ярлылар өчен күп катлы йортлар төзи башлыйлар. Сарайларда байлык эчендә коенган Рим аристократларыннан аермалы буларак, ярлылар уңайлыклары бик аз булган нәни генә бүлмәләрдә көн күргән. Бер типтагы күп фатирлы керем китерүче йортларның биеклеге 20 метрга җиткән.

Урта гасырларда шәһәр патрицийлары манара рәвешендәге таш йортлар төзиләр, алар, саклану чарасы һәм кирәк-ярак склады урынына хезмәт итсәләр дә, барыннан да элек, феодалларныкы кебек үк дәрәҗә символы булып торганнар.

Авыл җирләрендә феодаллар шулай ук ныгытылган йорт-хуҗалыклар торгызганнар. Аларны замок дип атаганнар. Алар яхшы сакланган урыннарда төзелгән; вал, канау һәм диварлар белән әйләндереп алынган. XI—XII гасырлардагы куәтле замоклар матуррак, планировкалары буенча иркенрәк була бара, ә XII—XIV гасырлардан башлап алар корылмаларның катлаулы комплексына һәм, ниһаять, сарай ансамбльләренә әверелә. Ныгытылган замоклар куркынычсызлык, куәт һәм дәрәҗә символы була.

Урта гасырларда крестьян йорты саманнан (кызыл балчыкка ком һәм салам кушып ясалган, һавада кипterелгән кирпеч) яисә агачтан төзелә (таш кулланылса да, фундаменттан өстә түгел). Гадәттә, ул бер бүлмәдән тора һәм төтен чыгу өчен түшәмдәге тишектән гайре башка юл булмый. Урта гасырлар шәһәрләре башлыча агач йортлардан тора. Алар янгыннарга бик тиз бирешә. Урта гасырларда ут иң куркыныч бәла-каза була. 1200—1225 елларда Руан шәһәре (Франция) алты тапкыр яна.

Төзелеш техникасының һаман камилләшә баруы торак сыйфатын яхшырта, бөтен уңайлыклары булган күп фатирлы һәм күп катлы йортлар төзелә. Ә иң мөһиме — шәһәр йортларында кеше яшәү өчен кирәкле санитария-гигиена шартлары — санузел, җылыту, яктырту һ. б. була.

Кешенең тормыш шартлары, гореф-гадәтләре, шуның белән бергә, үз йортының нинди булырга тиешлеге турында күзаллавы да үзгәрә бара. Берәүләр өчен йорт — аларның ныклы ныгытмасы, икенчеләргә — вакытлыча төн уздыру урыны, өченчеләр өчен — теләсә нинди тормыш сынауларында иң зур таяныч.

Без барыбыз да яхшы беләбез: йорт диварлары кешене әйләндереп алып кына калмыйлар, аны яклыйлар да. Ә нәрсәдән һәм ничек итеп?

Дивар, тәрәзә һәм ишекләр кебек йортның төп яклау элементларының вазифасы — суыкны, эссене, тавышны һәм җилне үткәрмәү, ә кояш яктысын һәм саф һаваны кертү. Аларга коммуналь инженерлык корылмалары (суүткәргеч, үзәктән җылыту, канализация) ярдәм итә.

Хәзерге заман торагы

Хәзерге заман торагы — эшли торган кеше йорты ул, ярдәмче бина да, төн уздыру урыны да түгел. Кеше ихтыяҗларын канәгатьләндерү — йокы, ял, ризык кабул итү, гигиена, уен, хәрәкәт — кешенең гармонияле үсеше өчен шартлар тудыра. Алар кайбер нормаларга туры килергә тиеш.

Үзебез өчен шәхсән яисә әйләнә-тирәдәге кешеләр өчен яраклы торакның ни икәнен без интуиция белән аңлыйбыз кебек. Үтә күренмәле диварлар яки тәрәзәсез йорт кемне дә булса канәгатьләндерер микән.

Хәзерге заман торагы кешене нәрсәләр белән тәэмин итә? «Торак уңайлыклары» төшенчәсе нәрсәләрне үз эченә ала?

Төрле илләрдә торакка төрлечә карыйлар. Америкалылар үз йортлары (коттедж) белән яшәргә омтылалар, һәм бу — аларның кабул ителерлек яшәү стандарты. Безнең илдә берничә дистә еллар элек коммуналь фатир нормаль яшәү шарты булып саналды, шәһәр халкының күбесе шулай яшәде дә. Соңрак, илдә муллык арта төшкәч, бөтен уңайлыклары булган аерым фатирны торак стандарты итеп саный башладылар.

Безнең торак сайлавыбыз, әлбәттә, әлеге вакытка җәмгыять нинди мөмкинлекләр тудыра алуга бәйле. Безнең әби һәм бабайлар аерым фатир турында түгел, ә баш өстендә түбә булу хакында хыялланганнар. Ә аларның оныклары Европа дәрәҗәсендәге йорт яисә фатир хакында уйлыйлар. Чор үзгәрә, карашлар да алышына.

Кешеләр зәвыклары, идеаллары, кызыксынулары, гадәтләре буенча аерылып тора. Берәүләр шәһәр үзәгендә яшәргә, фатирларының биек, бүлмәләр һәм санузелның аерым булуын телиләр, икенчеләре шәһәр читендәге яшел урынга тартыла һәм кайбер уңайлыкларның булмавына да риза. Торак алыштырганда, мәсәлән, беренче һәм соңгы катлар башкаларыннан кайтышрак дип санала.

Барлык илләрдә ниндидер уртача стандартлар бар һәм алар торак төзегәндә исәпкә алына: торак биналарның зурлыгы һәм аларның вазифасы.

Кешенең тавышка түзеп торучанлыгы шулай ук иленә карап аерыла. Италиялеләр, мәсәлән, тавыш яратсалар, немецлар тынычлык яклы.

Биналардагы температура да иленә карап төрләнә. Иң җиләс йокы бүлмәләре — инглизләрдә, ә иң җылысы — русларда. Америкалылар йортында бүлмәләр гаять җылы, чөнки архитекторлар, төзелешне проектлаштырганда, хатын-кызга йөз тоталар. Алар, мәгълүм булганча, өйдә җиңелрәк һәм ачыграк киемнән йөриләр. Эшләми торган хатын-кызлар, ягъни хуҗабикәләр, өйдә башкалардан күбрәк утыра. Вакытын башлыча өйдә уздырганга, хатын-кыз торакның сыйфатына карата да ирләрдән таләпчәнрәк.

Әниләр һәм әбиләр өйдә ризык әзерли, кер юа, бүлмәләрне чистарта, балалар тәрбияли, аларга дәрес әзерләргә

булыша һ. б. Сезнең бу хакта кайчан да булса уйланганыгыз бармы? Әни һәм әтинең өйдәге мәшәкатьләрен чагыштырыгыз: кемнең эше күбрәк?

Безнең күршеләр

Бер үк подъездда, бер үк йортта яшәгән күршеләр берберсе белән төрле дәрәҗәдә танышлар. Берәүләр сәлам бирешү, баш кагу яисә һава торышы турында сөйләшүләр белән чикләнә, ә икенчеләре күршеләре, хәтта аларның туганнары, якыннары һәм дуслары турында да бөтенесен белеп тора.

Күбесе кешеләрнең характерына, аларның шәхси үзенчәлекләренә (берәүләр аралашучан, икенчеләре үз эченә бикләнгән), социаль хәленә, гаиләсенең иминлегенә, торак йортның архитектурасына (шыплап тулган 12—16 катлы йортлар, ишегаллары булмау), шулай ук әлеге йортта күпме кеше яшәвенә бәйле. Әгәр элек кешеләр 20—30 ар ел бер йорттан китә алмый яшәсә, хәзер алар бик мобиль һәм яңа фатирларга еш рак күченәләр. Элек йортлар зур түгел, подъездларда кеше аз булып, барысы да бер-берсен танып белә иде.

Күршеләр белән мөнәсәбәтләрне берничә дәрәҗәгә бүлеп була.

1. Якынча танышлык дәрәҗәсе:

а) күршеләр бер-берсен беләләр, ләкин бик төгәл танып бетермиләр. Урамда очрашканда, күршеләрен танымаулары да мөмкин;

б) очрашканда гади генә исәнләшү яисә баш кагу белән чикләнәләр;

в) бер-берсе турында шәхси һәм һөнәри мәгълүматлары (яше, кайда туган, кайда кем булып эшли) юк яисә бик аз;

г) хезмәттәшлек һәм үзара ярдәм күренми, хәтта мөмкин яисә кирәк булган очракта да үтенеч белән мөрәҗәгать итешмиләр;

д) күрше фатир ишек артында ниләр эшләнүен бөтенләй белмиләр, кагыйдә буларак, кунакка йөрешмиләр, очраклы рәвештә булса гына.

2. Өстән-өстән танышлык дәрәҗәсе:

а) күршеләр бер-берсен җитәрлек кадәр төгәл беләләр, үтеп йөрүчеләр төркемендә танып калырга мөмкиннәр;

б) очрашканда гади генә сәламләшү белән чикләнмиләр, гомуми әһәмияткә ия проблемалар хакында (һава торышы, балалар тәрбияләү, территорияне төзекләндерү) фикер алышалар; сәламләшү эмоциональ символлар: елмаю, игелек теләүче караш белән тулылана;

в) бер-берсе турында шәхси һәм һөнәри мәгълүматка ия булу (ягъни алар кемнең, кайда, ничек эшләгәнен, якынча яшьләрен, үзләре генәме, туганнары беләнме яшәүләрен белешәләр; күрше балаларының һәм әти-әниләренең исемнәрен беләләр);

г) хезмәттәшлек һәм үзара ярдәм: бала авырган очракта ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр (телефон белешмәсен эзлиләр), хуҗалык ихтыяҗларын уртаклашалар (инструмент, изолента һ. б. сорап торалар), бурычка акча, ипи алып торалар, күрше балаларын карашалар;

д) аралашу: күршегә бер минутка гына баланы чакыру өчен яисә нәрсә дә булса сорарга кереп чыгалар, ләкин кунакка йөрешмиләр әле;

е) күршеләр фатир эчендәге хәлләрне шактый яхшы беләләр.

3. Аралашу танышлыгы дәрәҗәсе:

а) күршеләр исемнәрен белеп һәм исәнләшеп кенә калмыйлар, телевизор карарга, шахмат уйнарга керәләр, гомуми темаларга сөйләшү генә түгел, интим, шәхси мәгълүмат та алмашалар, бер-берсенә ышануның тирәнрәк булуын күрсәтәләр;

б) тормыш өчен мөһим мәсьәләләр буенча киңәшәләр, бер-берсенең биографиясен, язмышын беләләр, кайбер уртак акцияләр үткәрәләр, мәсәлән, торак-эксплуатация идарәсенә кумәк шикаять язалар;

в) сүз бирешеп зур сумма акча алып торалар, бер-берсе өчен ни дә булса сатып алуны сорыйлар. Монда «син — миңа, мин — сиңа» принцибы буенча шәхесара һәм эшлекле мөнәсәбәтләр нигезе салына.

4. Тирән танышлык дәрәҗәсе:

а) бер-берсенең эшләрендә ышаныч күрсәтеп, балалар һәм зурлар чынлап торып дуслашалар;

б) кайсы дуска өстенлек бирү дәрәҗәсен үлчәсәң, бергә яшәгән дуслар беренче планда була;

в) күршегә якынрак булу өчен, бергә эшләргә яисә эшне алыштырырга омтылалар;

г) гаиләләре белән бергә ял итәләр, дөньяга уртак караш, үз-үзеңне тоту стереотиплары формалаша.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, хәзерге шәһәрдә якынча һәм өстән-өстән танышу аеруча таралган.

Бүген кешеләр бәйсез булырга һәм аерым яшәргә тырышалар. Хәтта моны (бәлки) эшләргә кирәкмәгәндә дә. Безгә тик яхшы таныш кешеләр, туганнар һәм дуслар белән аралашу гына җиңел.

Яшәү районы

Шәһәр кешесенең иң якын яшәү тирәлеге — аның йорты гына түгел, янындагы урамнар да. Алар барысы бергә **торак районы** дип атала.

Шәһәр районнары берничә төрле була: мәдәни истәлекләр, театрлар һәм музейларга бай икән — *тарихи*; заводлар һәм предприятиеләр театр һәм ял паркларыннан күбрәк икән — *сәнәгать*; яки сәнәгать тә, театр, музей, университет һәм фәнни-тикшерену институтлары да юк икән — *«йокы»* районнары. Соңгысында, торак йортлар бик күп булса да, рестораннар аз, спорт корылмалары җитми. Кагыйдә буларак, мондый районнар шәһәрләрнең читләрендә урнаша.

Үзәк районнарны тагын *иске* районнар дип тә йөртәләр, ә шәһәр читендә *яңа* районнар урнаша. Эре шәһәрнең үзәге күпчелек өчен эшлекле һәм интеллектуаль тормышны гәүдәләндерә. Монда үзәк хакимият органнары, ведомство учреждениеләре, конторалар, университет һәм институтлар, уникаль мәдәни һәйкәлләр урнаша.

Шәһәр үзәге белән чагыштырганда «йокы» районнарында яшәүчеләрнең тормыш шартлары әллә ни отышлы түгел. Үзәктән еракта булу өстәмә уңайсызлыклар тудыра.

Музейга, театрга яисә күргәзмәгә җыенганда кеше тагын бер уйлап куя әле: барыргамы-бармаскамы?

Ләкин кеше кайда гына яшәсә дә үз районына ияләшә һәм яңа урынга бик авырлык белән күченә. Күпләрдә җирле ватанпәрвәрлек хисе формалаша. Уртача һәм эре шәһәрләрдә бер район яшүсмерләре икенче райондагы яшьтәшләрен «үз» территорияләренә кертмиләр. Алар арасында конфликт килеп чыгарга мөмкин. Россия киносында бу темага фильмнар юк, ә Америка фильмнары шәһәрдәге яшүсмерләр төркемнәренең ничек үлгәнче сугышулары, территорияне һәм йогынты даирәсен бүлешүләре хакында еш сөйлиләр. Сез бер генә булса да шундый фильмны искә төшерә аласызмы?

Кеше үз районында озаграк яшәгән саен, тору урынына ияләшү көчәя бара.

Торак районының характеры ничек кабул ителә һәм кешегә ничек тәэсир итә соң? Яңа урынга күченгәндә, тору урынын үзгәрткәндә безнең төрле уңайлыкларны: кинотеатр һәм кибетләр, тротуарлар, скверлар һәм керү юллары булу, җәмәгать транспорты маршрутларының уңайлылыгы, торак районының эшкә, шәһәр үзәгенә, туганнарга, дусларга якынлыгын гына бәяләп калмавыбыз сер түгел. Шәһәр районының йөзе шулай ук мөһим: шәһәр йортлары ничек күренә, парклар, сквер һәм урман бармы. Боларның барысын да үлчәп, без ияләшкән урынны алыштырыргамы яисә яхшырак вариант эзләргәме икәнлекне хәл итәбез.

Йортларның, кибетләрнең, ишегалларының һәм урамнарның уңайлылыгы — тору урыны белән канәгать калуның, аңа ияләшүнең мөһим факторы. Төзелешнең бертөрлелеге, соры, күңелсез биналар (кызганычка, яңа торак районнарында алар еш күзәтелә) бу хисләрне йомшартырга мөмкин. Әгәр йорт башка йортлардан нәрсәсе белән булса да аерылып тормаса, кешегә аны «үз йортым» дию авыр.

Кешеләргә спорт һәм балалар мәйданчыклары, стадионнар, йөгерү өчен урманда очраклы сукмаклар, футбол кыры, кортлар булу да уңай тәэсир итә. Хәтта гади генә

аллеялар да кичке сәфәр өчен уңайлы булырга мөмкин. Балалар һәм яшүсмерләрнең еш кына төзелешләрдә яисә ташландык йортларда уйнавын күрергә була. Моңа ни этәрә соң? Үзең генә калырга яки батырлыгыңны сынарга теләү генә түгелдер, мөгаен, хәрәкәтле уеннар өчен башка мөмкинлекләр булмау да шуңа китерәдер.

Яшүсмерләр төркемнәрен, театр һәм музейлардан бигрәк, подъездларда һәм баскычларда ешрак очратырга була. Ишегалларында, койма буйларында стихияле аралашу урыннары барлыкка килә.

Шулай итеп, торак районнарының төзексезлеге яшьләрнең бер өлеше арасында хокук бозуларның таралуына сәбәп булырга мөмкин. Бу буш вакытны эчтәлекле уткәрү өчен мөмкинлекләр җитмәүдән килеп чыга һәм еш кына мәдәни омтылышларны, стимулларны бастыруга гына түгел, аларның башкалары, аерым алганда, җәмгыятькә каршылары белән кысрыклап чыгарылуына китерә.

Йомгак ясыйбыз

Шәһәрдә һәм авылда торак бик мөһим роль уйный.
Кеше өч территориядә яши:
— иҗтимагый;
— өй;
— шәхси.

Иҗтимагый территория — барча кешегә керергә рөхсәт ителгән урын; өйнеке — бу кеше турыдан-туры яшәгән урын; ә шәхси — күзгә күренми торган чикләре булган өлкә, ул кешене чолгап алган, анда берәү дә керергә тиеш түгел. Һәр территориянең үз үзенчәлекләре бар.

Белемегезне тикшерегез

1. «Иҗтимагый территория», «өй территориясе», «шәхси пространство» дигән төшенчәләрнең мәгънәсен аңлатыгыз.

2. Түбәндәгеләр нинди территориягә керә:
а) мәктәп;
б) фатирда алгы бүлмә;
в) тулай торак бүлмәсе;
г) кинотеатр;
д) автобус;
е) өйдәге эш кабинеты;
ж) өйдәге балалар бүлмәсе;
з) урам?

3. «Мин үземне... уңай хис итәм» дигән фразаны тулыландырыгыз.

4. «Минем йортым — минем ныгытмам», «Өйдә диварлар да ярдәм итә», «Йорт хуҗаны бизәми, ә хуҗа — йортны», «Йортта ничек, үзеңә дә шулай» дигән элеккеге әйтем һәм мәкальләрне аңлатыгыз.

5. Үз йортыгызда нәрсәне яхшыртырга телисез? Сез нинди йортта яшәргә теләр идегез?

6. «Якынча танышлык», «өстән-өстән танышлык», «якын танышлык», «күрше хакы — Тәңре хакы» төшенчәләренең һәм әйтемнәрнең мәгънәсен аңлатыгыз.

7. Шәһәрдә һәм авылда күрше булу нәрсәсе белән аерыла? Ә кай яклары белән охшаш?

8. «Яшәү районы» нәрсә ул?

9. Яшәүчеләр өчен тагын да уңайлы булсын өчен, сезнең районда нәрсәне үзгәртергә кирәк?

Практикум

1. Әкиятләр һәм матур әдәбияттан йортлар һәм шәһәрләрнең артык күп кешеле булуына мисаллар китерегез.

2. Сез яшәгән район шәһәрнең кайсы өлешенә (тарихи, үзәк яисә яңа төзелеш) каравын ачыклагыз. Сез ни өчен шулай уйлыйсыз? Аңлатып бирегез.

3. Сез яшәгән район сәнәгать зонасына керәме яки юкмы икәнлеген белегез.

4. «Минем районның истәлекле урыннары» темасына зур булмаган инша языгыз.

5. «Районда мин яраткан урыннар» маршрутын төзегез.

6. Кешеләр белән үзара мөнәсәбәт кагыйдәләрен языгыз.

Россия Федерациясе Дәүләт гербы

Россия Федерациясе Дәүләт гербы — илнең рәсми дәүләт символы ул.

Россия Федерациясе Дәүләт гербы дүртпочмаклы, аскы почмаклары түгәрәкләнгән, тәмамланган урынында очланган, каурыйларын кабартып, канатларын югары күтәргән ике башлы алтын бөркет төшерелгән кызыл геральдик калканнан гыйбарәт. Бөркеткә ике кече таҗ кидерелгән һәм алар өстендә — тасма белән тоташкан бер зур таҗ. Бөркетнең уң аягында — скипетр, ә сулында — держава (монах хакимияте символы буларак, өстенә тәре куелган алтын шар). Бөркетнең күкрәгендә, кызыл калканда — җиргә егылган һәм ат таптаган кара аждаһага көмеш сөңгесе белән кадаучы зәңгәр плащлы, көмеш атка атланган көмеш җайдак.

Государственный гимн Российской Федерации

(слова С. В. Михалкова, музыка А. В. Александрова)

Россия — священная наша держава,
Россия — любимая наша страна.
Могучая воля, великая слава —
Твое достоянье на все времена!

Припев:
Славься, Отечество наше свободное,
Братских народов союз вековой,
Предками данная мудрость народная!
Славься, страна! Мы гордимся тобой!

От южных морей до полярного края
Раскинулись наши леса и поля.
Одна ты на свете! Одна ты такая —
Хранимая Богом родная земля!

Припев.

Широкий простор для мечты и для жизни
Грядущие нам открывают года.
Нам силу дает наша верность Отчизне.
Так было, так есть и так будет всегда!

Припев.

Учебное издание

Кравченко Альберт Иванович
Певцова Елена Александровна

ОБЩЕСТВОЗНАНИЕ
Учебник для 7 класса татарской средней
общеобразовательной школы

Казань. Издательство «Магариф». 2007
На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Кравченко Альберт Иванович
Певцова Елена Александровна

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ
Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
7 нче сыйныфы өчен дәреслек

Редакторы *Л. Г. Шәрифуллина*
Бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Ф. К. Гомәрова*
Корректорлары *С. З. Гыймалетдинова, Р. Ә. Фәйзуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 15.11.2007. Форматы $60x90^{1}/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Петербург» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 14,0. Тиражы 8550 д. Заказ С-1420.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20 а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
E-mail: magarif@ mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.